Какое бы то ни было прямое или косвенное ограничение прав или, наоборот, установление прямых или косвенных преимуществ граждан в зависимости от их расовой и национальной принадлежности, равно как всякая проповедь расовой или национальной исключительности или ненависти и пренебрежения – караются законом.

**Статья 91.** В целях обеспечения за гражданами свободы совести церковь и мечеть в Татарской АССР отделена от государства и школа от церкви и мечети.
Свобода отправления религиозных культов и свобода антирелигиозной пропаганды признается за всеми гражданами.

**Статья 92.** В соответствии с интересами трудящихся и в целях укрепления социалистического строя гражданам Татарской АССР гарантируются законом:
а) свобода слова;
б) свобода печати;



КОНСТИТУЦИЯ (Основной закон)
Татарской Автономной Советской Социалистической Республики (1937 г.)

в) свобода собраний и митингов;
г) свобода уличных шествий и демонстраций.
Эти права граждан обеспечиваются предоставлением трудящимся и их организациям типографий, запасов бумаги, общественных зданий, улиц, средств связи и других материальных условий, необходимых для их осуществления.

**Статья 93.** В соответствии с интересами трудящихся и в целях развития организационной самодеятельности и политической активности народных масс гражданам Татарской АССР обеспечивается право объединения в общественные организации; профессиональные союзы, кооперативные объединения, организации молодежи, спортивные и оборонные организации, культурные, технические и научные общества, а наиболее активные и сознательные граждане из рядов рабочего класса и других слоев трудящихся объединяются во Всесоюзную коммунистическую партию (большевиков), являющуюся передовым отрядом трудящихся в их борьбе за укрепление и развитие социалистического строя и представляющую руководящее ядро всех организаций трудящихся, как общественных, так и государственных.

**Статья 94.** Гражданам Татарской АССР обеспечивается неприкосновенность личности. Никто не может быть подвергнут аресту иначе как по постановлению суда или с санкции прокурора.

**Статья 95.** Неприкосновенность жилища граждан и тайна переписки охраняются законом.

**Статья 96.** Татарская АССР предоставляет право убежища иностранным гражданам, преследуемым за защиту интересов трудящихся, или научную деятельность, или национально-освободительную борьбу.

**Статья 97.** Каждый гражданин Татарской АССР обязан соблюдать Конституции Союза Советских Социалистических Республик, Российской Советской Федеративной Социалистической Республики и Татарской Автономной Советской Социалистической Республики, исполнять законы, блюсти дисциплину труда, честно относиться к общественному долгу, уважать правила социалистического общежития.

**Статья 98.** Каждый гражданин Татарской АССР обязан беречь и укреплять общественную, социалистическую собственность как священную и неприкосновенную основу советского строя, как источник богатства и могущества родины, как источник зажиточной и культурной жизни всех трудящихся.
Лица, покушающиеся на общественную, социалистическую собственность, являются врагами народа.

**Статья 99.** Всеобщая воинская обязанность является законом.
Воинская служба в Рабоче-Крестьянской Красной Армии представляет почетную обязанность граждан Татарской АССР.

**Статья 100.** Защита отечества есть священный долг каждого гражданина Татарской АССР. Измена родине: нарушение присяги, переход на сторону врага, нанесение ущерба военной мощи государства, шпионаж – караются по всей строгости закона, как самое тяжкое злодеяние.

## ГЛАВА IX.
## ИЗБИРАТЕЛЬНАЯ СИСТЕМА

**Статья 101.** Выборы депутатов во все Советы депутатов трудящихся: Верховный Совет Татарской АССР, районные, городские, поселковые и сельские Советы депутатов трудящихся, – производятся избирателями на основе всеобщего, равного и прямого избирательного права при тайном голосовании.

**Статья 102.** Выборы депутатов являются всеобщими: все граждане Татарской АССР, достигшие 18 лет, независимо от расовой и национальной принадлежности, вероисповедания, образовательного ценза, оседлости, социального происхождения, имущественного положения и прошлой деятельности, имеют право участвовать в выборах депутатов и быть избранными, за исключением умалишенных и лиц, осужденных судом с лишением избирательных прав.

**Статья 103.** Выборы депутатов являются равными: каждый гражданин имеет один голос; все граждане участвуют в выборах на равных основаниях.

**Статья 104.** Женщины пользуются правом избирать и быть избранными наравне с мужчинами.

**Статья 105.** Граждане, состоящие в рядах Красной Армии, пользуются правом избирать и быть избранными наравне со всеми гражданами.

**Статья 106.** Выборы депутатов являются прямыми: выборы во все Советы депутатов трудящихся, начиная от сельского и городского Совета депутатов трудящихся вплоть до Верховного Совета Татарской АССР, производятся гражданами непосредственно путем прямых выборов.

**Статья 107.** Голосование при выборах депутатов является тайным.

**Статья 108.** Выборы в Советы депутатов трудящихся Татарской АССР производятся по избирательным округам по следующим нормам:
районного Совета, в зависимости от размеров района, – один депутат не менее, чем от 500, и не более, чем от 1.500 населения; городского Совета и районного Совета в городах, в зависимости от размеров города или городского района, – один депутат не менее, чем от 100, и не более, чем от 1.000 населения;
сельского Совета, в зависимости от размеров района деятельности сельского Совета, – один депутат не менее, чем от 100, и не более, чем от 250 населения.
Избирательные нормы для каждого районного, городского, поселкового и сельского Совета депутатов трудящихся устанавливаются «Положением о выборах в Советы депутатов трудящихся Татарской АССР» в пределах избирательных норм, указанных в настоящей статье.

**Статья 109.** Кандидаты при выборах выставляются по избирательным округам.
Право выставления кандидатов обеспечивается за общественными организациями и обществами трудящихся: коммунистическими партийными организациями, профессиональными союзами, кооперативами, организациями молодежи, культурными обществами.





**Статья 110.** Каждый депутат обязан отчитываться перед избирателями в своей работе и в работе Совета депутатов трудящихся и может быть в любое время отозван по решению большинства избирателей в установленном законом порядке.

## ГЛАВА X.
## ГЕРБ, ФЛАГ, СТОЛИЦА

**Статья 111.** Государственным гербом Татарской Автономной Советской Социалистической Республики является государственный герб РСФСР, который состоит из изображения золотых серпа и молота, помещенных крест на крест, рукоятками книзу, на красном фоне в лучах солнца и в обрамлении колосьев, с надписью «РСФСР» и «Пролетарии всех стран, соединяйтесь!» на русском и татарском языках, с добавлением под надписью «РСФСР» буквами меньшего размера надписи «Татарская АССР» на русском и татарском языках.

**Статья 112.** Государственным флагом Татарской Автономной Советской Социалистической Республики является государственный флаг РСФСР, состоящий из красного полотнища, в левом углу которого, у древка наверху, помещены золотые буквы «РСФСР» на русском и татарском языках, с добавлением под надписью «РСФСР» буквами меньшего размера надписи «Татарская АССР» на русском и татарском языках.

**Статья 113.** Столицею Татарской АССР является город Казань.

## ГЛАВА XI
## ПОРЯДОК ИЗМЕНЕНИЯ КОНСТИТУЦИИ

**Статья 114.** Изменение Конституции Татарской АССР производится лишь по решению Верховного Совета Татарской АССР, принятому большинством не менее двух третей голосов Верховного Совета Татарской АССР, с утверждением Верховного Совета РСФСР.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯСЕ • КОНСТИТУЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН •

20

# ТАТАРСТАН АВТОНОМИЯЛЕ СОВЕТ СОЦИАЛИСТИК РЕСПУБЛИКАСЫ

# КОНСТИТУЦИЯСЕ

## Төп законы

**1978 елның 31 маенда**
**Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы**
**9 чакырылыш Верховный Советының IX сессиясендә кабул ителде**

**1978 ел**

# ТАТАРСТАН АВТОНОМИЯЛЕ СОВЕТ СОЦИАЛИСТИК РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯСЕ (ТӨП ЗАКОНЫ)

**Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы халкы, фәнни коммунизм идеяләрен кулланып, үзен бөтен совет халкының аерылгысыз өлеше дип аңлап, ССР Союзы Конституциясенә һәм РСФСР Конституциясенә туры китереп, шушы Конституцияне кабул итә һәм игълан итә.**

## I. ТАТАРСТАН АССРНЫҢ ҖӘМГЫЯТЬ СТРОЕ ҺӘМ ПОЛИТИКАСЫ НИГЕЗЛӘРЕ

### 1 БҮЛЕК. ПОЛИТИК СИСТЕМА

**1 статья.** Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы – эшчеләр, крестьяннар һәм интеллигенциянең, республикадагы барлык милләт хезмәт ияләренең ихтыярын һәм интересларын чагылдыручы гомумхалык социалистик дәүләте.

**2 статья.** Татарстан АССРда бөтен власть халык кулында. Халык дәүләт властен Татарстан АССРның политик нигезен тәшкил итүче халык депутатлары Советлары аркылы тормышка ашыра.
Дәүләтнең башка барлык органнары халык депутатлары Советлары контролендә һәм аларга отчет бирәләр.

**3 статья.** Совет дәүләтенең оештырылуы һәм эшчәнлеге демократик централизм принцибы – дәүләт властеның түбәннән югарыга кадәр барлык органнарының сайланып куелуы, аларның халыкка отчет бирүе, югарыгы органнар карарларының түбәнге органнар өчен мәҗбүри булуы нигезендә тормышка ашырыла. Демократик централизм бердәм җитәкчелекне урыннардагы инициатива һәм иҗат активлыгы белән, һәр дәүләт органының һәм хезмәт урынындагы кешенең тапшырылган эш өчен җаваплылыгы белән бергә бәйли.

**4 статья.** Совет дәүләте, аның барлык органнары социалистик законлылык нигезендә эшлиләр, хокук тәртибен, җәмгыять интересларын, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен саклауны тәэмин итәләр.
Дәүләт һәм җәмәгать оешмалары, хезмәт урынындагы кешеләр СССР Конституциясен, РСФСР Конституциясен, Татарстан АССР Конституциясен һәм совет законнарын үтәргә бурычлы.

**5 статья.** Дәүләт тормышының иң мөһим мәсьәләләре бөтенхалык тикшерүенә чыгарыла, шулай ук бөтен халыкның тавыш бирүенә (референдумга) куела.

**6 статья.** Совет җәмгыятенең җитәкче һәм юнәлеш бирүче көче, аның политик системасының, дәүләт һәм җәмәгать оешмаларының үзәге – Советлар Союзы Коммунистлар партиясе. КПСС халык өчен яши һәм халыкка хезмәт итә.
Марксизм-ленинизм тәгълиматы белән коралланган Коммунистлар партиясе җәмгыять





үсешенең төп перспективасын, СССРның эчке һәм тышкы политикасы линиясен билгели, совет халкының бөек иҗади эшчәнлегенә җитәкчелек итә, аның коммунизмның җиңүе өчен көрәшенә планлы, фәнни нигезләнгән характер бирә.
Партиянең барлык оешмалары СССР Конституциясе рамкаларында эш итәләр.

**7 статья.** Профессиональ союзлар, Бөтенсоюз Ленинчыл Коммунистик Яшьләр Союзы, кооператив һәм башка җәмәгать оешмалары үзләренең устав бурычлары нигезендә дәүләт һәм җәмәгать эшләрен идарә итүдә, политик, хуҗалык һәм социаль-культура мәсьәләләрен хәл итүдә катнашалар.

**8 статья.** Хезмәт коллективлары дәүләт һәм җәмәгать эшләрен тикшерүдә һәм хәл итүдә, җитештерүне һәм социаль үсешне планлаштыруда, кадрлар хәзерләүдә һәм урнаштыруда, предприятиеләрне һәм учреждениеләрне идарә итү, хезмәт һәм көнкүреш шартларын яхшырту, җитештерүне үстерүгә, шулай ук социаль-культура чараларына һәм материаль кызыксындыруга билгеләнгән средстволардан файдалану мәсьәләләрен тикшерү һәм хәл итүдә катнашалар.
Хезмәт коллективлары социалистик ярышны үстерәләр, алдынгы эш методларын таратуга, хезмәт дисциплинасын ныгытуга булышлык итәләр, үз членнарын коммунистик әхлак рухында тәрбиялиләр, аларның политик аңлылыгын, культурасын һәм профессиональ квалификациясен күтәрү турында кайгыртталар.

**9 статья.** Совет җәмгыятенең политик системасын үстерүнең төп юнәлеше социалистик демократияне тагын да киңәйтүдән – дәүләт һәм җәмгыять эшләрен идарә итүдә гражданнарның һаман киңрәк катнашуыннан, дәүләт аппаратын камилләштерүдән, җәмәгать оешмаларының активлыгын күтәрүдән, халык контролен көчәйтүдән, дәүләт һәм җәмгыять тормышының хокук нигезләрен ныгытудан, ачык эш итүне киңәйтүдән, җәмәгать фикерен даими исәпкә алудан гыйбарәт.

### 2 БҮЛЕК. ЭКОНОМИК СИСТЕМА

**10 статья.** Татарстан АССРның экономик системасы нигезен җитештерү средстволарына дәүләт (гомумхалык) һәм колхоз-кооператив милке формасындагы социалистик милек тәшкил итә.
Профсоюз һәм башка җәмәгать оешмаларының устав бурычларын тормышка ашыру өчен кирәкле мөлкәте шулай ук социалистик милек була.
Дәүләт социалистик милекне саклый һәм аның арта баруы өчен шартлар тудыра.
Социалистик милекне үзенә байлык җыю һәм башка төрле комсызлык максатларында файдаланырга беркемнең дә хакы юк.

**11 статья.** Дәүләт милке – бөтен совет халкының уртак байлыгы, социалистик милекнең төп формасы.
Җир, җир асты байлыклары, сулар, урманнар фәкать дәүләт милке генә була. Промышленностьта, төзелештә һәм авыл хуҗалыгында төп җитештерү средстволары, транспорт һәм элемтә средстволары, банклар, дәүләт тарафыннан оештырылган сәүдә, коммуналь һәм башка предприятиеләр мөлкәте, шәһәрләрдәге төп торак фонды, шулай ук дәүләт бурычларын тормышка ашыру өчен кирәкле башка мөлкәт дәүләт кулында.

**12 статья.** Колхозларның һәм башка кооператив оешмаларның, аларның берләшмәләренең җитештерү средстволары һәм аларга устав бурычларын тормышка ашыру өчен кирәкле башка мөлкәт алар милке була.
Колхозлар били торган җир аларга түләүсез һәм срокcыз файдалануга беркетелә.
Дәүләт колхоз-кооператив милкен үстерүгә һәм аның дәүләт милке белән якыная баруына булышлык итә.
Колхозлар, җирдән бүтән файдаланучылар кебек үк, җирне нәтиҗәле файдаланырга, аңа сакчыл карарга, аның уңдырышын күтәрергә бурычлылар.

**13 статья.** Татарстан АССР гражданнарының шәхси милке нигезен хезмәт доходлары тәшкил итә. Шәхси милектә көнкүреш, шәхси куллану, уңайлык һәм ярдәмче йорт хуҗалыгы әйберләре, торак йорт һәм хезмәт белән табылган саклык кыйммәтләр булырга мөмкин. Гражданнарның шәхси милке һәм аңа мирас хокукы дәүләт тарафыннан саклана.
Гражданнар файдалануында ярдәмче хуҗалык алып бару (шул исәптән терлек һәм кош асрау) өчен, җиләк-җимеш һәм яшелчә бакчачылыгы өчен, шулай ук индивидуаль торак төзелеше өчен законда билгеләнгән тәртиптә бирелә торган җир участоклары булырга мөмкин. Гражданнар үзләренә бирелгән җир участокларыннан рациональ файдаланырга тиешләр. Дәүләт һәм колхозлар ярдәмче хуҗалык алып баруда гражданнарга булышлык күрсәтәләр.
Гражданнарның шәхси милкендәге яки файдалануындагы мөлкәт эшләмичә генә доход алу өчен хезмәт итмәскә, җәмгыять интересларына зыянга файдаланылмаска тиеш.

**14 статья.** Совет кешеләренең эксплуатациядән азат хезмәте – җәмәгать байлыгын үстерү, халыкның һәм һәр совет кешесенең тормыш дәрәҗәсен күтәрү чыганагы.
Социализмның «һәркемнән – сәләтенчә, һәркемгә – хезмәтенчә» дигән принцибы нигезендә дәүләт хезмәт һәм куллану үлчәменә контрольлек итә. Ул налог салынырга тиешле доходларга налог күләмен билгели.
Кешенең җәмгыятьтәге урынын иҗтимагый файдалы хезмәт һәм аның нәтиҗәләре билгели. Дәүләт, материаль һәм мораль стимулларны бергә бәйләп, новаторлыкны, эшкә иҗади мөнәсәбәтне хуплап, хезмәтне һәр совет кешесенең беренче тормыш ихтыяҗына әверелдерүгә булышлык итә.

**15 статья.** Социализмда иҗтимагый җитештерүнең югары максаты –кешеләрнең үсә барган материаль һәм рухи ихтыяҗларын тулырак канәгатьләндерү.
Дәүләт, хезмәт ияләренең иҗат активлыгына, социалистик ярышка, фән-техника прогрессы казанышларына таянып, экономикага җитәкчелек формаларын һәм методларын камилләштереп, хезмәт җитештерүчәнлегенең үсүен, җитештерүнең нәтиҗәлелеген һәм эшнең сыйфатын күтәрүне, халык хуҗалыгының динамикалы, планлы һәм пропорциональ үсешен тәэмин итә.

**16 статья.** Татарстан АССР экономикасы – РСФСР экономикасының, СССР территориясендә иҗтимагый җитештерү, бүлү һәм алмашуның барлык буыннарын эченә алган бердәм халык хуҗалыгы комплексының состав өлеше.
Экономикага җитәкчелек экономик һәм социаль үсешнең дәүләт планнары нигезендә, тармак һәм территориаль принципларны исәпкә алып, үзәкләштерелгән идарә итүне предприятиеләрнең, берләшмәләрнең һәм башка оешмаларның хуҗалык мөстәкыйльлеге һәм инициативасы белән бергә бәйләү юлы белән тормышка ашырыла. Шуның белән бергә хуҗалык исәбе, табыш, үзкыйммәт һәм башка экономик этәргечләр һәм стимуллар актив файдаланыла.





**17 статья.** Татарстан АССРда закон нигезендә кустарь-һөнәрчелек, авыл хуҗалыгы, халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү сферасында индивидуаль хезмәт эшчәнлегенә, шулай ук гражданнарның һәм аларның семья члennнарының фәкать шәхси хезмәтенә генә корылган башка төрле эшчәнлеккә юл куела. Дәүләт, индивидуаль хезмәт эшчәнлеген җайга салып, аның җәмгыять интересларында файдаланылуын тәэмин итә.

**18 статья.** Хәзерге һәм киләчәк буыннар интересларында Татарстан АССРда җирне һәм җир асты байлыкларын, су ресурсларын, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясын саклау һәм фәнни нигездә рациональ файдалану өчен, һава һәм суны чиста тоту, табигый байлыкларны кабат җитештерүне тәэмин итү һәм кешене чолгап алган мохитне яхшырту өчен кирәкле чаралар күрелә.

## 3 БҮЛЕК.
## СОЦИАЛЬ ҮСЕШ ҺӘМ КУЛЬТУРА

**19 статья.** Татарстан АССРның социаль нигезен эшчеләрнең, крестьяннарның һәм интеллигенциянең какшамас союзы тәшкил итә.
Дәүләт җәмгыятьнең социаль бертөрлелеге көчәюгә — сыйнфый аермаларның, шәһәр белән авыл, акыл хезмәте белән физик хезмәт арасындагы җитди аермаларның бетә баруына, СССРдагы барлык милләтләр һәм халыкларның һәрьяклап үсүенә һәм үзара якынаюына булышлык итә.

**20 статья.** «Һәркемнең ирекле үсеше — барлык кешеләрнең ирекле үсеш шарты» дигән коммунистик идеал нигезендә дәүләт гражданнарның иҗади көчләрен, сәләтләрен һәм талантларын кулланулары өчен, шәхеснең һәрьяклап үсеше өчен реаль мөмкинлекләрне киңәйтүне үзенең максаты итеп куя.

**21 статья.** Дәүләт хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау, аны фәнни оештыру турында, халык хуҗалыгының барлык тармакларында җитештерү процессларын комплекслы механикалаштыру һәм автоматлаштыру нигезендә авыр физик хезмәтне киметү, ә киләчәктә аны бөтенләй бетерү турында кайгырта.

**22 статья.** Татарстан АССРда авыл хуҗалыгы хезмәтен индустриаль хезмәтнең бер төренә әйләндерү, авыл җирләрендә халык мәгарифе, культура, сәламәтлек саклау учреждениеләре, сәүдә һәм җәмәгать туклануы, көнкүреш хезмәте күрсәтү һәм коммуналь хуҗалык челтәрен киңәйтү, авылларны төзек поселокларга әйләндерү программасы эзлекле рәвештә тормышка ашырыла.

**23 статья.** Хезмәт җитештерүчәнлегенең үсүе нигезендә дәүләт хезмәткә түләү дәрәҗәсен, хезмәт ияләренең реаль доходларын күтәрү курсын тайпылышсыз рәвештә тормышка ашыра.
Совет кешеләренең ихтыяҗларын тулырак канәгатьләндерү максатында җәмәгать куллану фондлары төзелә. Җәмәгать оешмаларының һәм хезмәт коллективларының киң катнашында дәүләт бу фондларның арта баруын һәм гадел бүленүен тәэмин итә.

**24 статья.** Татарстан АССРда дәүләтнең сәламәтлек саклау, социаль тәэминат, сәүдә һәм җәмәгать туклануы, көнкүреш хезмәте күрсәтү һәм коммуналь хуҗалык системалары эшли һәм үсә.

Дәүләт кооператив һәм башка җәмәгать оешмаларының халыкка хезмәт күрсәтүнең барлык сфераларындагы эшчәнлеген хуплый. Ул массовый физик культураны һәм спортны үстерүгә булышлык итә.

**25 статья.** Татарстан АССРда бердәм халык мәгарифе системасы яши һәм камилләшә. Ул гражданнарга гомуми белем бирүне һәм аларны профессиональ хәзерләүне тәэмин итә, яшьләрне коммунистик тәрбияләүгә, рухи һәм физик яктан үстерүгә хезмәт итә, аларны хезмәткә һәм җәмәгать эшчәнлегенә хәзерли.

**26 статья.** Җәмгыять ихтыяҗлары нигезендә дәүләт фәннең планлы үсешен һәм фәнни кадрлар хәзерләүне тәэмин итә, фәнни тикшеренү нәтиҗәләрен халык хуҗалыгына һәм тормышның башка сфераларына кертүне оештыра.

**27 статья.** Дәүләт совет кешеләрен әхлакый һәм эстетик тәрбияләү, аларның культура дәрәҗәсен күтәрү өчен рухи байлыкларны саклау, арттыра бару һәм алардан киң файдалану турында кайгырта.
Татарстан АССРда профессиональ сәнгать һәм халык художество иҗатының үсеше һәрьяклап хуплана.

# II.
# ДӘҮЛӘТ ҺӘМ ШӘХЕС

## 4 БҮЛЕК.
## ТАТАРСТАН АССР ГРАЖДАНЛЫГЫ. ГРАЖДАННАРНЫҢ ТИГЕЗ ХОКУКЛЫЛЫГЫ

**28 статья.** СССРда билгеләнгән бердәм союз гражданлыгы нигезендә Татарстан АССРның һәр гражданы РСФСР һәм СССР гражданы була.
Совет гражданлыгы алу һәм аны югалту нигезләре һәм тәртибе СССР гражданлыгы турындагы Закон белән билгеләнә.
РСФСР һәм башка союздаш республикалар гражданнары Татарстан АССР территориясендә Татарстан АССР гражданнары белән бертигез хокуклардан файдаланалар.
Татарстан АССР гражданнары чит илләрдә Совет дәүләтенең саклавы һәм яклавыннан файдаланалар.

**29 статья.** Татарстан АССР гражданнары, чыгышлары, социаль һәм мөлкәт хәлләре нинди булуга, нинди расадан һәм милләттән булуларына, җенесләре, белемнәре, телләре, дингә мөнәсәбәтләре, шөгыльләренең төре һәм характеры нинди булуга, кайда яшәүләренә һәм башка хәлләргә карамастан, закон каршында тигез.
Татарстан АССР гражданнарының тигез хокуклылыгы экономик, политик, социаль һәм культура тормышының барлык өлкәләрендә тәэмин ителә.

**30 статья.** Татарстан АССРда хатын-кызлар һәм ирләр тигез хокукларга ия.
Бу хокукларны тормышка ашыру белем һәм профессиональ хәзерлек алуда, хезмәттә, хезмәт өчен түләүдә һәм эштә күтәрелүдә, иҗтимагый-политик һәм культура эшчәнлегендә хатын-кызларга ирләр белән бертигез мөмкинлекләр бирү белән, шулай ук хатын-кызларның хезмәтен һәм сәламәтлеген саклау буенча махсус чаралар белән; хатыннарга хезмәтне ана булу белән бергә бәйләргә мөмкинлек бирә торган шартлар тудыру белән; аналарны һәм балаларны хокукый яклау, аларга материаль һәм мораль булышлык күрсәтү, шул исәптән йөкле хатыннарга һәм аналарга түләүле отпуск һәм башка льготалар бирү, кече яшьтәге балалары булган хатыннарның эш вакытын киметә бару белән тәэмин ителә.

**31 статья.** Татарстан АССРның төрле расадан һәм милләттән булган гражданнары тигез хокукларга ия.
Бу хокукларны тормышка ашыру СССРдагы барлык милләтләр һәм халыкларны һәрьяклап үстерү һәм үзара якынайту политикасы белән, гражданнарны совет патриотизмы һәм социалистик интернационализм рухында тәрбияләү белән, туган телне һәм СССРдагы башка халыклар телләрен куллану мөмкинлеге белән тәэмин ителә.
Нинди расадан һәм милләттән булуларына карап, гражданнарның хокукларын турыдан-туры яки читләтеп нинди дә булса чикләү, аларга турыдан-туры яки читләтеп өстенлекләр билгеләү, шулай ук берәр расага яки милләткә өстенлек бирүгә, дошманлык күрсәтүгә яки аны кимсетүгә һәртөрле өндәү закон нигезендә җәзалана.

**32 статья.** Чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган кешеләргә Татарстан АССРда законда каралган хокуклар һәм ирекләр, шул исәптән аларга шәхси, мөлкәт, семья һәм башка хокукларын яклау өчен судка һәм башка дәүләт органнарына мөрәҗәгать итү хокукы гарантияләнә.
Татарстан АССР территориясендәге чит ил гражданнары гражданлыгы булмаган кешеләр СССР Конституциясен, РСФСР Конституциясен, Татарстан АССР Конституциясен ихтирам итәргә һәм совет законнарын үтәргә бурычлы.

## 5 БҮЛЕК.
## ТАТАРСТАН АССР ГРАЖДАННАРЫНЫҢ ТӨП ХОКУКЛАРЫ, ИРЕКЛӘРЕ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

**33 статья.** Татарстан АССР гражданнары СССР Конституциясендә, РСФСР Конституциясендә, Татарстан АССР Конституциясендә һәм совет законнарында игълан ителгән һәм гарантияләнә торган социаль-экономик, политик һәм шәхси хокукларга һәм ирекләргә тулысынча ия. Социалистик строй, социаль-экономик һәм культура үсеше программалары үтәлә баруга карап, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен киңәйтүне, аларның тормыш шартларын өзлексез яхшыртуны тәэмин итә.
Гражданнарның хокуклардан һәм ирекләрдән файдалануы җәмгыять һәм дәүләт интересларына, башка гражданнарның хокукларына зыян китермәскә тиеш.

**34 статья.** Татарстан АССР гражданнары хезмәткә хокуклы, ягъни хезмәтнең күләменә һәм сыйфатына карап түләнә торган һәм дәүләт тарафыннан билгеләнгән минималь күләмнән ким түләнми торган гарантияле эш алуга, шул исәптән булдыклылыгына, сәләтенә, профессиональ хәзерлегенә, белеменә карап һәм җәмгыять ихтыяҗларын исәпкә алып, профессия, шөгыль һәм эш төре сайлауга хокуклы.
Бу хокук социалистик хуҗалык системасы белән, җитештерүче көчләрнең туктаусыз үсүе белән, түләүсез профессиональ белем бирү, хезмәт квалификациясен күтәрү һәм яңа белгечлекләргә өйрәтү белән, профессиональ ориентация һәм хезмәткә урнаштыру системаларын үстерү белән тәэмин ителә.

**35 статья.** Татарстан АССР гражданнары ял итүгә хокуклы.
Бу хокук эшчеләр һәм хезмәткәрләр өчен 41 сәгатьтән артык булмаган эш атнасы билгеләү белән, күп кенә профессия һәм производстволар өчен кыскартылган эш көне белән, төнге эш вакытының кыскарак булуы белән; ел саен түләүле отпусклар, атна саен ял көннәре бирү белән; шулай ук культура-агарту һәм савыктыру учреждениеләре челтәрен киңәйтү, массовый спорт, физик культура һәм туризмны үстерү белән; тору урынында ял итү өчен уңай мөмкинлекләр һәм буш вакытны рациональ файдалану өчен башка шартлар тудыру белән тәэмин ителә.
Колхозчыларның эш һәм ял вакыты озынлыгы колхозлар тарафыннан билгеләнә.

**36 статья.** Татарстан АССР гражданнары сәламәтлекләрен саклауга хокуклы.
Бу хокук дәүләтнең сәламәтлек саклау учреждениеләре тарафыннан түләүсез күрсәтелә торган квалификацияле медицина ярдәме белән; гражданнарны дәвалау һәм аларның сәламәтлеген ныгыту учреждениеләре челтәрен киңәйтү белән; куркынычсызлык техникасын һәм производство санитариясен үстерү һәм камилләштерү белән; киң профилактика чаралары үткәрү белән; әйләнә-тирә мохитне савыктыру чаралары белән; яшь буынның сәламәтлеге турында аеруча кайгырту, шул исәптән балаларның укуга һәм хезмәттә тәрбияләнүгә бәйле булмаган хезмәтен тыю белән; авыруларны булдырмауга һәм киметүгә, гражданнарның озын гомерле актив тормышын тәэмин итүгә юнәлдерелгән фәнни-тикшеренү эшләрен җәелдерү белән тәэмин ителә.

**37 статья.** Татарстан АССР гражданнары картлыкта, авырганда хезмәткә яраклылыгын тулысынча яки өлешчә югалтканда, шулай ук караучысын югалтканда материаль тәэмин ителүгә хокуклы.
Бу хокук эшчеләр, хезмәткәрләр һәм колхозчылар өчен социаль страхование белән, хезмәткә яраклылыгын вакытлыча югалтканда түләнә торган пособиеләр белән; яшь буенча, инвалидлык буенча һәм караучысын югалткан очракта дәүләт һәм колхозлар исәбенә пенсияләр түләү белән; хезмәткә яраклылыгын өлешчә югалткан гражданнарны эшкә урнаштыру белән; карт гражданнар һәм инвалидлар турында кайгырту белән; социаль тәэминатның башка формалары белән гарантияләнә.

**38 статья.** Татарстан АССР гражданнары торакка хокуклы.
Бу хокук дәүләт һәм җәмәгать торак фондын үстерү һәм саклау, кооператив һәм индивидуаль торак төзелешенә булышлык күрсәтү, уңайлы торак төзү программасы тормышка ашырылуга карап бирелә торган торак мәйданын җәмәгатьчелек контролендә гадел бүлү белән, шулай ук квартира һәм коммуналь хезмәт күрсәтү хакының түбән булуы белән тәэмин ителә. Татарстан АССР гражданнары үзләренә бирелгән торакка сакчыл карарга тиешләр.

**39 статья.** Татарстан АССР гражданнары белем алуга хокуклы.
Бу хокук барлык төр белем алуның түләүсез булуы белән, яшьләргә гомуми мәҗбүри урта белем бирүне тормышка ашыру юлы белән, укытуны тормыш белән, производство белән бәйләү нигезендә профессиональ-техник, махсус урта һәм югары белем бирүне киң җәелдерү белән; читтән торып һәм кичке укуны үстерү белән; укучыларга һәм студентларга дәүләт стипендияләре һәм льготалар бирү белән; мәктәптә ана телендә уку мөмкинлеге белән; үзлегеңнән белем алу өчен шартлар тудыру белән тәэмин ителә.

**40 статья.** Татарстан АССР гражданнары культура казанышларыннан файдалануга хокуклы.
Бу хокук илебез һәм дөнья культурасының дәүләт һәм җәмәгать фондларындагы





хәзинәләреннән һәркемнең файдалана алуы белән, культура-агарту учреждениеләрен үстерү һәм республика территориясендә тигез урнаштыру белән, телевидение һәм радионы, китап чыгару эшен һәм вакытлы матбугатны, түләүсез китапханәләр челтәрен үстерү, чит ил дәүләтләре белән культура алмашуны киңәйтү белән тәэмин ителә.

**41 статья.** Коммунистик төзелеш максатларына туры китереп, Татарстан АССР гражданнарына фәнни, техник һәм художество иҗаты иреге гарантияләнә. Ул фәнни тикшеренүләрне, уйлап табу һәм рационализаторлык эшчәнлеген киң җәелдерү белән, әдәбият һәм сәнгатьне үстерү белән тәэмин ителә. Моның өчен дәүләт кирәкле материаль шартлар тудыра, ирекле җәмгыятьләргә һәм иҗат союзларына булышлык күрсәтә, уйлап табуларны һәм рационализаторлык тәкъдимнәрен халык хуҗалыгына һәм тормышның башка сфераларына кертүне оештыра.
Авторлар, уйлап табучылар һәм рационализаторларның хокуклары дәүләт тарафыннан саклана.

**42 статья.** Татарстан АССР гражданнары дәүләт һәм җәмәгать эшләрен идарә итүдә, гомумдәүләт һәм җирле әһәмияте булган законнарны һәм карарларны тикшерү һәм кабул итүдә катнашырга хокуклы.
Бу хокук халык депутатлары Советларына һәм дәүләтнең сайлана торган башка органнарына сайлау һәм сайлану, бөтенхалык тикшерүендә һәм тавыш бирүендә, халык контролендә, дәүләт органнары һәм җәмәгать оешмалары, җәмәгать үзешчәнлеге органнары эшендә хезмәт коллективларындагы һәм тору урыннарындагы җыелышларда катнашу мөмкинлеге белән тәэмин ителә.

**43 статья.** Татарстан АССРның һәр гражданы дәүләт органнарына һәм җәмәгать оешмаларына аларның эшчәнлеген яхшырту турында тәкъдимнәр кертергә, эштәге кимчелекләрне тәнкыйтьләргә хокуклы.
Хезмәт урынындагы кешеләр гражданнарның тәкъдимнәрен һәм гаризаларын билгеләнгән срокларда карарга, аларга җавап бирергә һәм тиешле чаралар күрергә бурычлы.
Тәнкыйть өчен эзәрлекләү тыела. Тәнкыйть өчен эзәрлекләүче кешеләр җавапка тартыла.

**44 статья.** Халык интересларына туры китереп һәм социалистик стройны ныгыту һәм үстерү максатларында Татарстан АССР гражданнарына сүз, матбугат, җыелышлар, митинглар, урам шествиеләре һәм демонстрацияләр иреге гарантияләнә.
Бу политик ирекләрне тормышка ашыру хезмәт ияләренә һәм аларның оешмаларына җәмәгать бинаралары, урам һәм мәйданнар бирү белән, киң күләмдә информация тарату белән, матбугат, телевидение һәм радионы файдалану мөмкинлеге белән тәэмин ителә.

**45 статья.** Коммунистик төзелеш максатларына туры китереп, Татарстан АССР гражданнары политик активлыкларын һәм үзешчәнлекләрен үстерүгә, күп төрле интересларын канәгатьләндерүгә булышлык итә торган җәмәгать оешмаларына берләшергә хокуклы.
Җәмәгать оешмаларына үзләренең устав бурычларын уңышлы үтәү өчен шартлар гарантияләнә.

**46 статья.** Татарстан АССР гражданнарына вөҗдан иреге, ягъни теләсә нинди дин тоту яки бернинди дә дин тотмау, дини культларны үтәү яки атеистик пропаганда алып бару хокукы гарантияләнә. Дингә ышануларга бәйле рәвештә дошманлык һәм нәфрәт тудыру тыела.
Татарстан АССРда мәчет һәм чиркәү дәүләттән, мәктәп мәчет һәм чиркәүдән аерылган.

**47 статья.** Семья дәүләт тарафыннан яклана.
Никах хатын-кыз белән ир-атның ирекле ризалыгына нигезләнә; ир һәм хатын семья мөнәсәбәтләрендә тулысынча тигез хокуклы.
Дәүләт семья турында балалар учреждениеләренең киң челтәрен булдыру һәм үстерү, көнкүреш хезмәте күрсәтүне һәм җәмәгать туклануын оештыру һәм камилләштерү, бала тугач пособиеләр түләү, күп балалы семьяларга пособиеләр түләү һәм ярдәм күрсәтү юлы белән кайгырта.

**48 статья.** Татарстан АССР гражданнарына шәхес иминлеге гарантияләнә. Суд карарыннан яки прокурор санкциясеннән башка беркем дә кулга алмый.

**49 статья.** Татарстан АССР гражданнарына торак иминлеге гарантияләнә.
Торакка анда яшәүчеләр ризалыгыннан башка законсыз нигездә керергә беркемнең дә хакы юк.

**50 статья.** Гражданнарның шәхси тормышы, язышу, телефоннан сөйләшү һәм телеграф аша хәбәрләшү сере закон белән саклана.

**51 статья.** Гражданнарның шәхесен ихтирам итү, хокукларын һәм ирекләрен саклау – барлык дәүләт органнары, җәмәгать оешмалары һәм хезмәт урыныңдагы кешеләрнең бурычы.
Татарстан АССР гражданнары үзләренең намусына һәм кешелек дәрәҗәсенә, тормышына һәм сәламәтлегенә, шәхси ирегенә һәм мөлкәтенә кул сузулардан суд ярдәмендә сакланырга хокуклы.

**52 статья.** Татарстан АССР гражданнары хезмәт урыныңдагы кешеләрне, дәүләт һәм җәмәгать органнарының эшенә карата жалоба бирергә хокуклы. Жалобалар законда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда каралырга тиеш.
Хезмәт урыныңдагы кешеләрнең законны бозып, вәкаләтләрен арттырып эшләнгән, гражданнарның хокукларын кыса торган эшләре турында билгеләнгән тәртиптә судка жалоба бирелергә мөмкин.
Татарстан АССР гражданнары дәүләт һәм җәмәгать оешмаларының, шулай ук хезмәт урыныңдагы кешеләрнең хезмәт вазифаларын үтәгәндә законсыз эш итүләре нәтиҗәсендә килгән зыянны түләтергә хокуклы.

**53 статья.** Хокукларны һәм ирекләрне тормышка ашыру гражданнарның үз бурычларын үтәвеннән аерылгысыз.
Татарстан АССР гражданы СССР Конституциясен, РСФСР Конституциясен, Татарстан АССР Конституциясен һәм совет законнарын үтәргә, социалистик тормыш кагыйдәләрен ихтирам итәргә, совет гражданы дигән югары исемгә лаек булырга бурычлы.

**54 статья.** Иҗтимагый файдалы эшчәнлекнең үзе сайлаган өлкәсендә намуслы хезмәт итү, хезмәт дисциплинасын саклау – Татарстан АССРның хезмәткә яраклы һәр гражданының бурычы һәм намус эше. Иҗтимагый файдалы хезмәттән тайпылу социалистик җәмгыять принциплары белән сыешмый.

**55 статья.** Татарстан АССР гражданы социалистик милекне сакларга һәм ныгытырга бурычлы. Дәүләт һәм җәмәгать мөлкәтен урларга һәм әрәм-шәрәм итүгә каршы көрәшү, халык байлыгына сакчыл карау – Татарстан АССР гражданының бурычы.
Социалистик милеккә кул сузучы кешеләр закон нигезендә җәзага тартылалар.





**56 статья.** Татарстан АССР гражданы Совет дәүләте интересларын сакларга, аның куәтен һәм авторитетын ныгытуга булышлык итәргә бурычлы.
Социалистик Ватанны саклау – Татарстан АССРның һәр гражданының изге бурычы. Ватанга хыянәт итү – халык алдында иң зур җинаять.

**57 статья.** СССР Коралды Көчләре сафында хәрби хезмәт – Татарстан АССР гражданнарының мактаулы бурычы.

**58 статья.** Башка гражданнарның милли дәрәҗәсен ихтирам итү, күп милләтле Совет дәүләтендәге милләтләр һәм халыклар дуслыгын ныгыту –Татарстан АССРның һәр гражданының бурычы.

**59 статья.** Татарстан АССР гражданы башка кешеләрнең хокукларын һәм законлы интересларын ихтирам итәргә, җәмгыятькә каршы эшләргә карата килешмәүчән булырга, җәмәгать тәртибен саклауга барлык чаралар белән булышлык итәргә бурычлы.

**60 статья.** Татарстан АССР гражданнары балаларны тәрбияләү турында кайгыртырга, аларны иҗтимагый-файдалы хезмәткә хәзерләргә, социалистик җәмгыятьнең лаеклы әгъзалары итеп үстерергә бурычлы. Балалар ата-ана турында кайгыртырга һәм аларга ярдәм итәргә бурычлы.

**61 статья.** Татарстан АССР гражданнары табигатьне, аның байлыкларын сакларга бурычлы.

**62 статья.** Тарихи истәлекләрне һәм башка культура байлыкларын саклау турында кайгырту – Татарстан АССР гражданнарының бурычы һәм вазифасы.

**63 статья.** Башка илләр халыклары белән дуслык һәм хезмәттәшлекне үстерүгә, гомуми тынычлыкны саклауга һәм ныгытуга булышу – Татарстан АССР гражданының интернациональ бурычы.

## III.
## ТАТАРСТАН АССРНЫҢ МИЛЛИ-ДӘҮЛӘТ ҺӘМ АДМИНИСТРАТИВ-ТЕРРИТОРИАЛЬ ТӨЗЕЛЕШЕ

### 6 БҮЛЕК.
### ТАТАРСТАН АССР – РСФСР СОСТАВЫНДАГЫ АВТОНОМИЯЛЕ РЕСПУБЛИКА

**64 статья.** Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы – Россия Совет Федератив Социалистик Республикасы составындагы совет социалистик дәүләте.
ССР Союзы һәм РСФСР хокуклары чикләреннән тыш, Татарстан АССР үз карамагындагы мәсьәләләрне мөстәкыйль рәвештә хәл итә.

**65 статья.** Татарстан АССР территориясе аның ризалыгыннан башка үзгәртелә алмый.

**66 статья.** Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы карамагына дәүләт власте һәм идарәсенең югары органнары йөзендә түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан АССР Конституциясен кабул итү һәм аңа үзгәрешләр кертү;
2) Татарстан АССР Конституциясенең үтәлешенә контрольлек итү;
3) Татарстан АССР законнарын чыгару;
4) дәүләт тәртибен, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен саклау;
5) ССР Союзы һәм РСФСР законнарына туры китереп, дәүләт власте һәм идарәсенең республика һәм җирле органнарының оештырылу һәм эшчәнлек тәртибен билгеләү;
6) бердәм социаль-экономик политика үткәрү, Татарстан АССР экономикасына җитәкчелек итү; фән-техника прогрессын тәэмин итү һәм табигый ресурслардан рациональ файдалану һәм аларны саклау чараларын тормышка ашыру;
7) Татарстан АССРның экономик һәм социаль үсешенең дәүләт планнарын, Татарстан АССРның дәүләт бюджетын эшләү һәм раслау, аларның үтәлеше турындагы отчетларны раслау, районнарның һәм республика буйсынуындагы шәһәрләрнең бюджетларын тормышка ашыруга җитәкчелек итү;
8) ССР Союзы һәм РСФСР законнарына туры китереп, Татарстан АССР дәүләт бюджетына керә торган доходларны билгеләү;
9) халык хуҗалыгының республика буйсынуындагы тармакларына, республика һәм җирле буйсынудагы берләшмәләргә һәм предприятиеләргә җитәкчелек итү;
10) ССР Союзы һәм РСФСР законнарына туры китереп, җирдән, җир асты байлыкларыннан, урманнардан һәм сулардан файдалануга контрольлек итү; әйләнә-тирә мохитне саклау;
11) торак һәм коммуналь хуҗалыкка, сәүдә һәм җәмәгать туклануына, халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтүгә, торак төзелешенә, шәһәрләрне һәм башка торак пунктларны төзекләндерү эшенә, юл төзелешенә һәм транспортка җитәкчелек итү;
12) Татарстан АССРның халык мәгарифенә, культура һәм фән оешмаларына һәм учреждениеләренә, сәламәтлек саклауга, физик культурага һәм спортка, социаль тәэминатка җитәкчелек итү; тарих һәм культура истәлекләрен саклау;
13) республика күләмендәге башка мәсьәләләрне хәл итү.

**67 статья.** Татарстан АССР РСФСР һәм ССР Союзы дәүләт власте һәм идарәсенең югары органнары аша РСФСР һәм ССР Союзы карамагындагы мәсьәләләрне хәл итүдә катнаша.
Татарстан АССР үз территориясендә комплекслы экономик һәм социаль үсешне тәэмин итә, шул территориядә ССР Союзы һәм РСФСР вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга булышлык итә, СССР һәм РСФСР дәүләт власте һәм идарәсенең югары органнары карарларын тормышка ашыра.
Татарстан АССР үз карамагындагы мәсьәләләр буенча союз һәм республика (РСФСР) буйсынуындагы предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар эшен координацияли һәм аңа контрольлек итә.

**68 статья.** СССР Конституциясенә һәм РСФСР Конституциясенә туры китереп, социалистик Ватанны саклау дәүләтнең иң мөһим функцияләренә керә һәм бөтен халык эше булып тора.
Совет халкының тыныч хезмәтенең социалистик казанышларын, дәүләтнең суверенитетын һәм территориаль бөтенлеген саклау максатында СССР Кораллы Көчләре булдырылды һәм гомуми хәрби хезмәт билгеләнде.
Татарстан АССР илнең иминлеген һәм оборона сәләтен тәэмин итүдә, СССР Кораллы Көчләрен бөтен кирәкле нәрсә белән тәэмин итүдә катнаша.





Дәүләт органнарының, җәмәгать оешмаларының, хезмәт урынындагы кешеләрнең һәм гражданнарның ил иминлеген тәэмин итү һәм аның оборона сәләтен ныгыту бурычлары ССР Союзы законнары белән билгеләнә.

**69 статья.** Татарстан АССРда сугышны пропагандалау тыела.

**70 статья.** Татарстан АССР территориясендә СССР һәм РСФСР законнары мәҗбүри.

## 7 БҮЛЕК.
## ТАТАРСТАН АССРНЫҢ АДМИНИСТРАТИВ-ТЕРРИТОРИАЛЬ ТӨЗЕЛЕШЕ

**71 статья.** Татарстан АССР, РСФСР законнарына туры китереп, үзенең районнарга бүленешен билгели һәм республиканың административ-территориаль төзелешенең башка мәсьәләләрен хәл итә.

**72 статья.** Татарстан АССР Әгерҗе, Азнакай, Аксубай, Актаныш, Алексеевск, Әлки, Әлмәт, Апас, Арча, Баулы, Балтач, Бөгелмә, Буа, Югары Ослан, Биектау, Чүпрәле, Алабуга, Зәй, Зеленодольск, Кама Тамагы, Куйбышев, Кукмара, Лаеш, Лениногорск, Мамадыш, Минзәлә, Мөслим, Түбән Кама, Октябрь, Питрәч, Балык Бистәсе, Саба, Сарман, Тәтеш, Тукай, Чирмешән, Чистай районнарыннан; республика буйсынуындагы Казан, Әлмәт, Бөгелмә, Алабуга, Зәй, Зеленодольск, Лениногорск, Яр Чаллы, Түбән Кама, Чистай шәһәрләреннән тора.

# IV.
# ТАТАРСТАН АССРНЫҢ ХАЛЫК ДЕПУТАТЛАРЫ СОВЕТЛАРЫ ҺӘМ АЛАРНЫ САЙЛАУ ТӘРТИБЕ

## 8 БҮЛЕК.
## ХАЛЫК ДЕПУТАТЛАРЫ СОВЕТЛАРЫ СИСТЕМАСЫ ҺӘМ АЛАРНЫҢ ЭШ ПРИНЦИПЛАРЫ

**73 статья.** Халык депутатлары Советлары – Татарстан АССР Верховный Советы, халык депутатларының район, шәһәр, шәһәрдәге район, поселок һәм авыл Советлары – дәүләт власте органнарының бердәм системасын тәшкил итәләр.

**74 статья.** Татарстан АССР Верховный Советының вәкаләт срогы – биш ел.
Халык депутатлары җирле Советларының вәкаләт срогы – ике ел ярым.
Халык депутатлары Советларына сайлаулар тиешле Советларның вәкаләт срогы бетәргә кимендә ике ай кала билгеләнә.

**75 статья.** Халык депутатларының тиешле Советлары карамагындагы бик әһәмиятле мәсьәләләр аларның сессияләрендә карала һәм хәл ителә.
Халык депутатлары Советлары даими комиссияләр сайлыйлар, башкаручы һәм идарә итүче, шулай ук үзләренә отчет бирүче башка органнарны оештыралар.

**76 статья.** Халык депутатлары Советлары предприятиеләрдә, колхозларда, учреждениеләрдә һәм оешмаларда хезмәт ияләренең җәмәгать контролен дәүләт контроле белән бергә бәйли торган халык контроле органнары оештыралар.
Халык контроле органнары дәүләт планнарының һәм заданиеләренең үтәлешенә контрольлек итәләр; дәүләт дисциплинасын бозуларга, урынчылык, эшкә ведомствочыл караш күренешләренә, хуҗасызлык һәм әрәм-шәрәм итүләргә, волокита һәм бюрократизмга каршы көрәш алып баралар; дәүләт аппараты эшен камилләштерүгә булышлык итәләр.

**77 статья.** Халык депутатлары Советлары турыдан-туры һәм үзләре оештырган органнар аша дәүләт, хуҗалык һәм социаль-культура төзелешенең барлык тармакларына җитәкчелек итәләр, карарлар чыгаралар, аларның үтәлүен тәэмин итәләр, карарларның тормышка ашырылуына контрольлек итәләр.

**78 статья.** Халык депутатлары Советларының эшчәнлеге мәсьәләләрне коллектив, иркле, эшлекле тикшерү һәм хәл итү, ачык эш итү нигезендә, башкаручы һәм идарә итүче органнарның, Советлар оештырган башка органнарның Советлар һәм халык алдында регуляр рәвештә отчет бирүе, Советлар эшенә гражданнарны киң катнаштыру нигезендә тормышка ашырыла.
Халык депутатлары Советлары һәм алар оештырган органнар үзләренең эше һәм кабул иткән карарлары турында халыкка системалы рәвештә белдереп торалар.

## 9 БҮЛЕК.
## САЙЛАУ СИСТЕМАСЫ

**79 статья.** Халык депутатларының барлык Советларына депутатлар сайлау гомуми, тигез һәм туры сайлау хокукы нигезендә яшерен тавыш бирү тәртибендә үткәрелә.

**80 статья.** Депутатлар сайлау гомуми: Татарстан АССРның 18 яшькә җиткән барлык гражданнары сайларга һәм сайланырга хокуклы, закон белән билгеләнгән тәртиптә акылдан язган дип танылган кешеләр генә сайлый һәм сайлана алмый.

**81 статья.** Депутатлар сайлау тигез: һәр сайлаучы бер тавышка ия; сайлауларда барлык сайлаучылар бертигез нигезләрдә катнаша.

**82 статья.** Депутатлар сайлау туры: халык депутатларының барлык Советларына депутатлар гражданнар тарафыннан турыдан-туры сайлана.

**83 статья.** Депутатлар сайлаганда тавыш бирү яшерен: сайлаучыларның үз ихтыярын гамәлгә ашыруына контрольлек итүгә юл куелмый.

**84 статья.** Депутатлыкка кандидатлар күрсәтү хокукы Советлар Союзы Коммунистлар партиясе, профессиональ союзлар, Бөтенсоюз Ленинчыл Коммунистик Яшьләр Союзы оешмаларына, кооператив һәм башка җәмәгать оешмаларына, хезмәт коллективларына, шулай ук хәрби частьлардагы хәрби хезмәткәрләр җыелышларына бирелә.
Татарстан АССР гражданнарына һәм җәмәгать оешмаларына депутатлыкка кандидатларның политик, эшлеклелек һәм шәхси сыйфатлары турында иркен һәм һәрьяклап фикер алышу, шулай ук җыелышларда, матбугатта, телевидение, радио аша агитация алып бару хокукы гарантияләнә.
Халык депутатлары Советларына сайлаулар үткәрүгә бәйле расходлар дәүләт исәбенә тотыла.





**85 статья.** Халык депутатлары Советларына депутатлар сайлау сайлау округлары буенча үткәрелә.
Татарстан АССР гражданы, кагыйдә буларак, халык депутатларының икедән артык Советына сайлана алмый.
Советларга сайлаулар үткәрүне җәмәгать оешмалары, хезмәт коллективлары һәм хәрби частьлардагы хәрби хезмәткәрләр җыелышлары вәкилләреннән төзелгән сайлау комиссияләре тәэмин итә.
Халык депутатлары Советларына сайлаулар үткәрү тәртибе ССР Союзы, РСФСР һәм Татарстан АССР законнары белән билгеләнә.

**86 статья.** Сайлаучылар үз депутатларына наказлар бирәләр.
Халык депутатларының тиешле Советлары сайлаучыларның наказларын карыйлар, экономик һәм социаль үсеш планнарын эшләгәндә һәм бюджет төзегәндә аларны исәпкә алалар, наказларны үтәүне оештыралар һәм аларның гамәлгә ашырылуы турында гражданнарга белдереп торалар.

## 10 БҮЛЕК.
## ХАЛЫК ДЕПУТАТЫ

**87 статья.** Депутатлар халык депутатлары Советларында халыкның тулы хокуклы вәкилләре булалар.
Депутатлар, Советларның эшендә катнашып, дәүләт, хуҗалык һәм социаль-культура төзелеше мәсьәләләрен хәл итәләр, Советларның карарларын тормышка ашыруны оештыралар, дәүләт органнары, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар эшенә контрольне тормышка ашыралар.
Депутат үзенең эшчәнлегендә гомумдәүләт интересларыннан чыгып эш итә, сайлау округындагы халыкның ихтыяҗларын исәпкә ала, сайлаучыларның наказларын тормышка ашыруга ирешә.

**88 статья.** Депутат үз вәкаләтләрен производство яки хезмәт эшчәнлегеннән аерылмыйча гамәлгә ашыра.
Депутат Советның сессияләре вакытында, шулай ук законда каралган башка очракларда депутатлык вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен, даими эш урынында уртача эш хакы саклanган хәлдә, производство яки хезмәт вазифаларын үтәүдән азат ителә.

**89 статья.** Депутат тиешле дәүләт органнарына һәм хезмәт урынындагы кешеләргә запрос ясарга хокуклы.Алар запроска Совет сессиясендә җавап бирергә бурычлы.
Депутат барлык дәүләт һәм җәмәгать органнарына, предприятиеләргә, учреждениеләргә, оешмаларга депутатлык эшчәнлеге мәсьәләләре белән мөрәҗәгать итәргә һәм үзе куйган мәсьәләләрне карауда катнашырга хокуклы. Тиешле дәүләт һәм җәмәгать органнарының, предприятие, учреждение һәм оешмаларның җитәкчеләре депутатны кичекмәстән кабул итәргә һәм аның тәкъдимнәрен билгеләнгән срокларда карарга бурычлы.

**90 статья.** Депутатка үзенең хокукларын һәм вазифаларын тоткарлыксыз һәм нәтиҗәле рәвештә тормышка ашыру өчен шартлар тәэмин ителә.
Депутатларның кагылгысызлыгы, шулай ук депутатлык эшчәнлегенең башка гарантияләре депутатлар статусы турындагы Закон белән һәм ССР Союзының, РСФСР һәм Татарстан АССРның башка закон актлары белән билгеләнә.

**91 статья.** Депутат үз эше һәм Совет эше турында сайлаучылар алдында, шулай ук үзен депутатлыкка кандидат итеп күрсәткән коллективлар һәм җәмәгать оешмалары алдында отчет бирергә бурычлы.
Сайлаучыларның ышанычын акламаган депутат законда билгеләнгән тәртиптә сайлаучыларның күпчелеге карары белән теләсә кайчан кире чакырып алынырга мөмкин.

# V. ТАТАРСТАН АССР ДӘҮЛӘТ ВЛАСТЕ ҺӘМ ИДАРӘСЕНЕҢ ЮГАРЫ ОРГАННАРЫ

## 11 БҮЛЕК. ТАТАРСТАН АССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ

**92 статья.** Татарстан АССР дәүләт властеның югары органы – Татарстан АССР Верховный Советы.
Татарстан АССР Верховный Советы СССР Конституциясе, РСФСР Конституциясе һәм шушы Конституция белән Татарстан АССР карамагына кертелгән барлык мәсьәләләрне хәл итәргә хокуклы.
Татарстан АССР Конституциясен кабул итү, аңа үзгәрешләр кертү; Татарстан АССРның экономик һәм социаль үсешенең дәүләт планнарын, Татарстан АССР дәүләт бюджетын һәм аларның үтәлеше турындагы отчетларны раслау; Татарстан АССР Верховный Советына отчет бирүче органнарны оештыру бары тик Татарстан АССР Верховный Советы тарафыннан гына тормышка ашырыла.
Татарстан АССР законнары Татарстан АССР Верховный Советы тарафыннан кабул ителә.

**93 статья.** Татарстан АССР Верховный Советы халык саны бертигез булган сайлау округлары буенча сайлана торган 250 депутаттан тора.
Татарстан АССР Верховный Советы үзе сайлый торган Мандат комиссиясе тәкъдиме белән депутатларның вәкаләтләрен тану турында, ә сайлау турындагы законнар бозылган очракта аерым депутатларның сайлануын дөрес түгел дип табу турында карар чыгара.

**94 статья.** Татарстан АССР Верховный Советы Татарстан АССР Верховный Советы Председателен һәм аның ике урынбасарын сайлый.
Татарстан АССР Верховный Советы Председателе Татарстан АССР Верховный Советы утырышларына җитәкчелек итә һәм аның эчке эш тәртибен идарә итә.

**95 статья.** Татарстан АССР Верховный Советы сессияләре елга ике тапкыр чакырыла.
Чираттан тыш сессияләр Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы тарафыннан аның инициативасы белән яки Татарстан АССР Верховный Советы депутатларының





кимендә өчтән бере тәкъдиме буенча чакырыла.
Татарстан АССР Верховный Советы сессиясе аның утырышларыннан, шулай ук алар арасындагы чорда Татарстан АССР Верховный Советының даими яки башка комиссияләре утырышларыннан тора.

**96 статья.** Татарстан АССР Верховный Советында закон чыгару инициативасы хокукы Татарстан АССР Верховный Советы Президиумына, Татарстан АССР Министрлар Советына, Татарстан АССР Верховный Советының даими һәм башка комиссияләренә, Татарстан АССР Верховный Советы депутатларына, Татарстан АССР Верховный Судына, Татарстан АССР Прокурорына бирелә.
Шулай ук җәмәгать оешмалары үзләренең республика органнары һәм аларга туры килә торган органнар йөзендә закон чыгару инициативасы хокукына ия булалар.

**97 статья.** Татарстан АССР Верховный Советы каравына кертелгән закон проектлары һәм башка мәсьәләләр аның утырышларында тикшерелә. Кирәк булганда, закон проекты яки тиешле мәсьәлә башлангыч яки өстәмә рәвештә карау өчен бер яки берничә комиссиягә тапшырылырга мөмкин.
Татарстан АССР законнары, Татарстан АССР Верховный Советының карарлары һәм башка актлары Татарстан АССР Верховный Советындагы барлык депутатларның күпчелеге тарафыннан кабул ителә.
Татарстан АССР законнары проектлары һәм автономияле республика дәүләт тормышының башка мөһим мәсьәләләре Татарстан АССР Верховный Советы яки Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы карары белән халык тикшерүенә куелырга мөмкин.

**98 статья.** Татарстан АССР законнары, Татарстан АССР Верховный Советының карарлары һәм башка актлары Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе һәм Секретаре имзалары белән татар һәм рус телләрендә игълан ителә.

**99 статья.** Татарстан АССР Верховный Советы депутаты Татарстан АССР Министрлар Советына, министрларга һәм Татарстан АССР Верховный Советы оештырган башка органнарның җитәкчеләренә, шулай ук Татарстан АССР территориясендә урнашкан союз һәм республика (РСФСР) буйсынуындагы предприятие, учреждение һәм оешмаларның җитәкчеләренә Татарстан АССР карамагындагы мәсьәләләр буенча запрос белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Татарстан АССР Министрлар Советы яки запрос ясалган хезмәт урынындагы кеше Татарстан АССР Верховный Советының шул сессиясендә телдән яки язма рәвештә җавап бирергә бурычлы.

**100 статья.** Татарстан АССР Верховный Советы депутаты Татарстан АССР Верховный Советы ризалыгыннан башка, ә аның сессияләре арасындагы чорда Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы ризалыгыннан башка җинаять җаваплылыгына тартыла алмый, кулга алынмый яки суд тәртибендә бирелә торган башка административ җәза чараларына тартыла алмый.

**101 статья.** Татарстан АССР Верховный Советы Татарстан АССР Верховный Советының даими эшләүче, үзенең бөтен эшендә аңа отчет бирүче һәм аның сессияләре арасындагы чорда шушы Конституциядә каралган чикләрдә Татарстан АССР дәүләт властеның югары органы функцияләрен тормышка ашыручы органын – Татарстан АССР Верховный Советы Президиумын сайлый.

**102 статья.** Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы депутатлар арасыннан Верховный Совет Президиумы Председателе, Председательнең ике урынбасары, Президиумның Секретаре һәм Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының унбер члены составында сайлана.

**103 статья.** Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы:

1) Татарстан АССР Верховный Советына һәм халык депутатларының җирле Советларына сайлауларны билгели;
2) Татарстан АССР Верховный Советы сессияләрен чакыра;
3) Татарстан АССР Верховный Советының даими комиссияләре эшчәнлеген координацияли;
4) Татарстан АССР Конституциясенең үтәлешенә контрольлек итә;
5) Татарстан АССР законнарына аңлатмалар бирә;
6) халык депутатларының җирле Советлары эшчәнлегенә җитәкчелекне тормышка ашыра;
7) район буйсынуындагы шәһәрләр, шәһәрләрдә районнар оештыра, аларга исемнәр бирә һәм исемнәрен үзгәртә, шулай ук башка торак пунктларның исемнәрен үзгәртә һәм бу мәсьәләләр буенча чыгарылган карарларны РСФСР Верховный Советы Президиумы раславына кертә;
8) авыл Советларын оештыра һәм бетерә, торак пунктларны эшчеләр, курорт һәм дача поселоклары категориясенә кертә, шулай ук РСФСР законнарына туры китереп, республиканың административ-территориаль төзелешенең башка мәсьәләләрен хәл итә;
9) Татарстан АССР Министрлар Советы карарлары һәм боерыклары, халык депутатларының район һәм шәһәр (республика буйсынуындагы шәһәрләр) Советлары карарлары законга туры килмәгәндә, аларны юкка чыгара;
10) Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Почет грамотасы белән бүләкли; Татарстан АССРның мактаулы исемнәрен билгели һәм бирә;
11) Татарстан АССР Конституциясе һәм законнары белән билгеләнгән башка вәкаләтләрне тормышка ашыра.

**104 статья.** Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Верховный Совет сессияләре арасындагы чорда түбәндәгеләрне эшли һәм соңыннан чираттагы сессия раславына кертә:

1) кирәк булган хәлләрдә Татарстан АССРның гамәлдәге закон актларына үзгәрешләр кертә;
2) закон белән билгеләнгән тәртиптә районнар һәм республика буйсынуындагы шәһәрләр оештыра, аларга исемнәр бирә һәм исемнәрен үзгәртә;
3) Татарстан АССР Министрлар Советы тәкъдиме белән Татарстан АССР министрлыкларын һәм дәүләт комитетларын, дәүләт идарәсенең Татарстан АССР Верховный Советы тарафыннан оештырыла торган башка органнарын оештыра һәм бетерә;
4) Татарстан АССР Министрлар Советы Председателе тәкъдиме белән Татарстан АССР Министрлар Советы составына керә торган аерым кешеләрне хезмәт вазифаларыннан азат итә һәм билгели.

**105 статья.** Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Указлар чыгара һәм карарлар кабул итә.

**106 статья.** Татарстан АССР Верховный Советының вәкаләтләре беткәннән соң, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Татарстан АССРның яңа сайланган Верховный Советы тарафыннан яңа Президиум төзелгәнгә кадәр үзенең вәкаләтләрен саклый.
Татарстан АССРның яңа сайланган Верховный Советы, сайлаулар үткәч ике айдан да соңга калмыйча, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының элекке составы тарафыннан чакырыла.





**107 статья.** Татарстан АССР Верховный Советы карамагындагы мәсьәләләрне алдан карау һәм хәзерләү өчен, шулай ук Татарстан АССР законнарын һәм Татарстан АССР Верховный Советының һәм аның Президиумының башка карарларын тормышка ашыруга булышлык итү өчен, дәүләт органнары һәм оешмаларының эшчәнлегенә контрольлек итү өчен Татарстан АССР Верховный Советы депутатлар арасыннан даими комиссияләр сайлый.
Татарстан АССР Верховный Советы, кирәк тапканда, теләсә нинди мәсьәлә буенча тикшерү, ревизия комиссияләре һәм башка комиссияләр оештыра.
Барлык дәүләт һәм җәмәгать органнары, оешмалар һәм хезмәт урыныдагы кешеләр Татарстан АССР Верховный Советы комиссияләренең таләпләрен үтәргә, аларга кирәкле материаллар һәм документлар бирергә бурычлы.
Комиссияләрнең рекомендацияләре дәүләт һәм җәмәгать органнары, учреждениеләре һәм оешмалары тарафыннан каралуы мәҗбүри. Карау нәтиҗәләре яки күрелгән чаралар турында комиссияләргә билгеләнгән срокта хәбәр ителергә тиеш.

**108 статья.** Татарстан АССР Верховный Советы үзенә отчет бирүче барлык дәүләт органнары эшчәнлегенә контрольлек итә.
Татарстан АССР Верховный Советы Татарстан АССР халык контроле органнары системасына җитәкчелек итә торган Татарстан АССР Халык контроле комитетын оештыра.

**109 статья.** Татарстан АССР Верховный Советы һәм аның органнарының эш тәртибе Татарстан АССР Верховный Советы Регламенты һәм Татарстан АССР Конституциясе нигезендә чыгарыла торган башка законнар белән билгеләнә.

## 12 БҮЛЕК.
## ТАТАРСТАН АССР МИНИСТРЛАР СОВЕТЫ

**110 статья.** Татарстан АССР Министрлар Советы – Татарстан АССР Хөкүмәте – Татарстан АССР дәүләт властеның башкаручы һәм идарә итүче югары органы.

**111 статья.** Татарстан АССР Министрлар Советы Татарстан АССР Верховный Советы тарафыннан Татарстан АССР Министрлар Советы Председателе, Председательнең Беренче урынбасары һәм урынбасарлары, министрлар, дәүләт комитетлары председательләре һәм дәүләт идарәсенең республика Верховный Советы оештыра торган башка органнары җитәкчеләре составында төзелә.
Татарстан АССР Верховный Советы Татарстан АССР Министрлар Советы Председателе тәкъдиме белән Татарстан АССР Хөкүмәте составына Татарстан АССРның башка органнары һәм оешмалары җитәкчеләрен кертә ала.
Татарстан АССР Министрлар Советы Татарстан АССРның яңа сайланган Верховный Советы алдында аның беренче сессиясендә үз вәкаләтләрен өстеннән төшерә.

**112 статья.** Татарстан АССР Министрлар Советы Татарстан АССР Верховный Советы алдында җаваплы һәм аңа отчет бирә, ә Татарстан АССР Верховный Советы сессияләре арасындагы чорда Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы алдында җаваплы һәм аңа отчет бирә.

Татарстан АССР Министрлар Советы үзенең эше турында Татарстан АССР Верховный Советына регуляр рәвештә отчет бирә.

**113 статья.** Татарстан АССР Министрлар Советы дәүләт идарәсенең Татарстан АССР карамагында булган һәм Конституция нигезендә Татарстан АССР Верховный Советы һәм Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы компетенциясенә кермәгән барлык мәсьәләләрен хәл итәргә хокуклы.
Татарстан АССР Министрлар Советы үз вәкаләтләре чикләрендә:

1) халык хуҗалыгына һәм социаль-культура төзелешенә җитәкчелекне тәэмин итә; халыкның тормыш дәрәҗәсен һәм культурасын үстерүне тәэмин итү, фән һәм техниканы үстерү, табигать ресурсларыннан рациональ файдалану һәм аларны саклау чараларын эшли һәм тормышка ашыра; акча һәм кредит системасын ныгыту, дәүләт страхованиесен һәм бердәм учет һәм статистика системасын оештыру чараларын тормышка ашыруга булыша; бәяләр, хезмәткә түләү һәм социаль тәэминат өлкәсендә бердәм политика үткәрүдә катнаша; промышленность, төзелеш, авыл хуҗалыгы предприятиеләрен һәм берләшмәләрен, транспорт һәм элемтә предприятиеләрен, шулай ук республика һәм җирле буйсынудагы башка оешмалар һәм учреждениеләрне идарә итүне оештыра;
2) Татарстан АССРның экономик һәм социаль үсешенең агымдагы һәм перспектив дәүләт планнарын, Татарстан АССРның дәүләт бюджетын эшли һәм Татарстан АССР Верховный Советына кертә; дәүләт планнарын һәм бюджетны гамәлгә ашыру чараларын күрә; планнарның һәм бюджетның үтәлеше турында Татарстан АССР Верховный Советына отчетлар бирә;
3) автономияле республика, район һәм шәһәрләрнең комплекслы экономик һәм социаль үсешен тәэмин итә; Татарстан АССР карамагындагы мәсьәләләр буенча союз һәм республика (РСФСР) буйсынуындагы предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар эшчәнлеген координацияли һәм аңа контрольлек итә;
4) дәүләт интересларын яклау, социалистик милекне һәм җәмәгать тәртибен саклау, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын тормышка ашыра;
5) СССР Конституциясе билгеләгән чикләрдә дәүләт иминлеген һәм илнең оборона сәләтен тәэмин итү чараларын күрә;
6) кирәк булганда Татарстан АССР Министрлар Советы каршында хуҗалык һәм социаль-культура төзелеше эшләре буенча комитетлар, идарәләр һәм башка ведомстволар төзи;
7) халык депутатларының җирле Советлары башкарма комитетлары эшенә җитәкчелекне тормышка ашыра.

**114 статья.** Халык хуҗалыгына җитәкчелекне тәэмин итүгә бәйле мәсьәләләрне һәм дәүләт идарәсенең башка мәсьәләләрен хәл итү өчен Татарстан АССР Министрлар Советының даими органы сыйфатында Татарстан АССР Министрлар Советы Председателе, Татарстан АССР Министрлар Советы Председателенең Беренче урынбасары һәм урынбасарлары, шулай ук Татарстан АССР Министрлар Советы турындагы Закон нигезендә Хөкүмәтнең башка членнары составында Татарстан АССР Министрлар Советы Президиумы эшли.

**115 статья.** Татарстан АССР Министрлар Советы СССР, РСФСР һәм Татарстан АССРның закон актлары, СССР Министрлар Советы һәм РСФСР Министрлар Советы карарлары һәм боерыклары нигезендә һәм аларны үтәү йөзеннән карарлар һәм боерыклар чыгара, аларның үтәлешен оештыра һәм тикшерә. Татарстан АССР Министрлар Советы карарларын һәм боерыкларын үтәү Татарстан АССРның бөтен территориясендә мәҗбүри.





**116 статья.** Татарстан АССР Министрлар Советы үз компетенциясе чикләрендә халык депутатларының район һәм шәһәр (республика буйсынуындагы шәһәр) Советлары башкарма комитетларының карарларын һәм боерыкларын юкка чыгарырга хокуклы.
Татарстан АССР Министрлар Советы Татарстан АССР министрлыклары, дәүләт комитетлары, үз карамагындагы башка органнарның актларын юкка чыгарырга хокуклы.

**117 статья.** Татарстан АССР Министрлар Советы Татарстан министрлыклары, дәүләт комитетлары, үз карамагындагы башка органнарның эшен берләштерә һәм аңа юнәлеш бирә.
Татарстан АССР министрлыклары, дәүләт комитетлары һәм дәүләт идарәсенең башка органнары Татарстан АССР Министрлар Советына, шулай ук РСФСРның тиешле министрлыклары һәм дәүләт комитетларына буйсынган хәлдә үзләренә тапшырылган идарә тармакларына җитәкчелек итәләр яки тармакара идарәне тормышка ашыралар.
Татарстан АССР министрлыклары, дәүләт комитетлары һәм дәүләт идарәсенең башка органнары үзләренә тапшырылган идарә сфераларының торышы һәм үсеше өчен җаваплы; үзләренең компетенцияләре чикләрендә СССР, РСФСР һәм Татарстан АССР законнары СССР Верховный Советы һәм аның Президиумының, РСФСР Верховный Советы һәм аның Президиумының, Татарстан АССР Верховный Советы һәм аның Президиумының башка карарлары, СССР Министрлар Советы, РСФСР Министрлар Советы һәм Татарстан АССР Министрлар Советы карарлары һәм боерыклары, СССР һәм РСФСРның тиешле министрлыклары һәм дәүләт комитетлары актлары нигезендә һәм аларны үтәү йөзеннән актлар чыгаралар, аларның үтәлешен оештыралар һәм тикшерәләр.

**118 статья.** Татарстан АССР Министрлар Советы һәм аның Президиумының компетенциясе, аларның эш тәртибе, Татарстан АССР Министрлар Советының дәүләтнең башка органнары белән мөнәсәбәтләре, шулай ук Татарстан АССРның министрлыклары, дәүләт комитетлары һәм дәүләт идарәсенең башка органнары исемлеге Конституция нигезендә Татарстан АССР Министрлар Советы турындагы Закон белән билгеләнә.

# VI.
# ТАТАРСТАН АССРДА ДӘҮЛӘТ ВЛАСТЕ ҺӘМ ИДАРӘСЕНЕҢ ҖИРЛЕ ОРГАННАРЫ

## 13 БҮЛЕК.
## ХАЛЫК ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ ҖИРЛЕ СОВЕТЛАРЫ

**119 статья.** Районнарда, шәһәрләрдә, шәһәрләрдәге районнарда, поселокларда, авыл торак пунктларында дәүләт власте органнары – халык депутатларының тиешле Советлары.

**120 статья.** Халык депутатларының җирле Советлары җирле әһәмияте булган барлык мәсьәләләрне гомумдәүләт интереслары һәм Совет территориясендә яшәүче гражданнар интереслары нигезендә хәл итәләр, югарыгы дәүләт органнарының карарларын тормышка ашыралар, халык депутатларының түбәнге Советлары эшенә җитәкчелек итәләр, республика (АССР, РСФСР) һәм гомумсоюз күләмендә әһәмиятле мәсьәләләрне тикшерүдә катнашалар, алар буенча үзләренең тәкъдимнәрен кертәләр.

Халык депутатларының җирле Советлары үз территорияләрендә дәүләт, хуҗалык һәм социаль-культура төзелешенә җитәкчелек итәләр; экономик һәм социаль үсеш планнарын, җирле бюджетны һәм аларның үтәлеше турындагы отчетларны раслыйлар; үзләренә буйсынган дәүләт органнарына, предприятие, учреждение һәм оешмаларга җитәкчелекне тормышка ашыралар; законнарның үтәлешен, дәүләт һәм җәмәгать тәртибен, гражданнарның хокукларын саклауны тәэмин итәләр; илнең оборона сәләтен ныгытуга булышлык итәләр.

**121 статья.** Халык депутатларының җирле Советлары үз вәкаләтләре чикләрендә үз территорияләрендә комплекслы экономик һәм социаль үсешне тәэмин итәләр; шул территориядә урнашкан һәм югарыгы органнарга буйсынучы предприятие, учреждение һәм оешмаларның законнарны үтәвенә контрольлек итәләр, аларның җирдән файдалану, табигатьне саклау, төзелеш, хезмәт ресурсларыннан файдалану, халык кулланусы товарлары җитештерү, халыкка социаль-культура, көнкүреш хезмәте һәм башка төрле хезмәт күрсәтү өлкәсендәге эшен координацияләләр һәм аңа контрольлек итәләр.

**122 статья.** Халык депутатларының җирле Советлары ССР Союзы, РСФСР һәм Татарстан АССР законнары нигезендә үзләренә бирелгән вәкаләтләр чикләрендә карарлар кабул итәләр. Җирле Советларның карарларын үтәү шул Совет территориясендә урнашкан барлык предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар өчен, шулай ук хезмәт урынындагы кешеләр һәм гражданнар өчен мәҗбүри.

**123 статья.** Халык депутатларының район, шәһәр һәм шәһәрләрдәге район Советлары сессияләре аларның башкарма комитетлары тарафыннан елга кимендә дүрт тапкыр чакырыла. Халык депутатларының поселок һәм авыл Советлары сессияләре аларның башкарма комитетлары тарафыннан елга кимендә алты тапкыр чакырыла.
Халык депутатларының җирле Советлары сессияләрдә ССР Союзы, РСФСР һәм Татарстан АССР законнары белән алар карамагына кертелгән теләсә нинди мәсьәләне карарга һәм хәл итәргә хокуклы. Сессияләрдә генә хәл ителә торган мәсьәләләр исемлеге халык депутатларының җирле Советлары турындагы законнар белән билгеләнә.

**124 статья.** Халык депутатларының җирле Советлары җирле Советлар карамагындагы мәсьәләләрне башлангыч тәртиптә карау һәм хәзерләү өчен, шулай ук Советларның карарларын тормышка ашыруга булышлык итү, дәүләт органнары, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар эшенә контрольлек итү өчен депутатлар арасыннан даими комиссияләр сайлыйлар.
Җирле Советлар даими комиссияләре рекомендацияләренең тиешле дәүләт һәм җәмәгать органнары, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар тарафыннан каралуы мәҗбүри. Карау нәтиҗәләре яки күрелгән чаралар турында билгеләнгән срокта комиссияләргә хәбәр ителергә тиеш.

**125 статья.** Халык депутатларының җирле Советлары, түбәнге Советлар эшенә җитәкчелек итү белән бергә, түбәнге Советларның актлары законга туры килмәгән очракта бу актларны юкка чыгарырга хокуклы.

**126 статья.** Халык депутатларының җирле Советлары үзләренең эшен җәмәгать оешмалары һәм хезмәт коллективлары белән тыгыз элемтәдә алып баралар, иң мөһим мәсьәләләрне гражданнар тикшерүенә чыгаралар, аларны даими комиссияләр, башкарма комитетлар һәм





Советларга отчет бирә торган башка органнар эшенә тарталар, җирле иректә җәмгыятьләр эшенә булышалар һәм халыкның җәмәгать үзешчәнлеген үстерәләр.

## 14 БҮЛЕК.
## ХАЛЫК ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ ҖИРЛЕ СОВЕТЛАРЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЛАРЫ

**127 статья.** Халык депутатларының җирле Советларының башкаручы һәм идарә итүче органнары – шул Советларның депутатлары арасыннан председатель, председательнең урынбасарлары, секретарь һәм членнар составында сайлана торган башкарма комитетлар.
Башкарма комитетлар үзләрен сайлаган Советлар алдында, шулай ук хезмәт коллективлары һәм тору урыннарында гражданнарның җыелышларында елга кимендә бер тапкыр отчет бирәләр.

**128 статья.** Халык депутатларының җирле Советлары башкарма комитетлары үзләрен сайлаган Советка да, югары башкаручы һәм идарә итүче органга да турыдан-туры отчет бирәләр.

**129 статья.** Халык депутатларының җирле Советлары башкарма комитетлары үзләрен сайлаган Советлар һәм дәүләт власте һәм идарәсенең югары органнары карарлары нигезендә тиешле Советлар территориясендә дәүләт, хуҗалык һәм социаль-культура төзелешенә җитәкчелек итәләр.
Халык депутатларының җирле Советлары башкарма комитетлары, Советлар сессияләрдә генә хәл ителергә тиешле мәсьәләләрдән тыш, Советлар карамагындагы барлык мәсьәләләрне хәл итәргә хокуклы.
Башкарма комитетлар Советларның сессияләрен чакыралар, Советларның даими комиссияләре эшен координацияләләр; депутатларга вәкаләтләрен тормышка ашыруда булышлык күрсәтәләр; Советлар һәм дәүләтнең югарыгы органнары карарларын, шулай ук сайлаучыларның наказларын үтәүне оештыралар; үзләренә буйсынган идарә органнарына җитәкчелек итәләр.

**130 статья.** Халык депутатларының җирле Советлары башкарма комитетлары үз компетенцияләре чикләрендә карарлар кабул итәләр һәм боерыклар чыгаралар.

**131 статья.** Халык депутатлары Советларының башкарма комитетлары халык депутатларының түбәнге Советлары башкарма комитетларының карарларын һәм боерыкларын юкка чыгарырга хокуклы.

**132 статья.** Халык депутатлары җирле Советларының вәкаләтләре беткәннән соң, аларның башкарма комитетлары яңа чакырылыш халык депутатлары Советлары тарафыннан башкарма комитетлар сайлаганга кадәр үзләренең вәкаләтләрен саклыйлар.

**133 статья.** Башкарма комитетларның бүлекләре һәм идарәләре халык депутатларының район, шәһәр, шәһәрләрдәге район халык депутатлары Советлары тарафыннан оештырылалар һәм үзләренең эшләрендә Советларга һәм аларның башкарма комитетларына, шулай ук дәүләт идарәсенең тиешле югарыгы органнарына да буйсыналар.
Халык депутатлары җирле Советлары башкарма комитетларының бүлекләре һәм идарәләре исемлеге һәм аларны оештыру тәртибе ССР Союзы, РСФСР һәм Татарстан АССР законнары белән билгеләнә.

# VII.
# ТАТАРСТАН АССРНЫҢ ЭКОНОМИК ҺӘМ СОЦИАЛЬ ҮСЕШЕНЕҢ ДӘҮЛӘТ ПЛАНЫ. ТАТАРСТАН АССРНЫҢ ДӘҮЛӘТ БЮДЖЕТЫ

**134 статья.** Татарстан АССРның экономик һәм социаль үсеше дәүләт планы – РСФСРның экономик һәм социаль үсеше дәүләт планының состав өлеше.
Татарстан АССРның экономик һәм социаль үсешенең агымдагы һәм перспектив дәүләт планнары, РСФСРны экономик һәм социаль үстерүнең төп бурычларына һәм юнәлешләренә туры китереп, республика территориясендә комплекслы экономик һәм социаль үсешне тәэмин итү максатын күздә тота.

**135 статья.** Татарстан АССРның экономик һәм социаль үсешенең дәүләт планы Татарстан АССР Министрлар Советы тарафыннан, РСФСРның экономик һәм социаль үсеше дәүләт планыннан чыгып, Татарстан АССР министрлыклары, дәүләт комитетлары һәм дәүләт идарәсенең башка органнары, халык депутатларының җирле Советлары план проектлары нигезендә эшләнә.
Татарстан АССРның экономик һәм социаль үсешенең дәүләт планына Татарстан АССР территориясендә булган союз һәм республика (РСФСР) буйсынуындагы предприятие, учреждение һәм оешмалар планнарының төп күрсәткечләре кертелә.
Экономик һәм социаль үсеш планнары предприятие, учреждение һәм оешмалар коллективлары, шулай ук җәмәгать оешмалары тәкъдимнәрен исәпкә алып эшләнә.

**136 статья.** Татарстан АССР Министрлар Советы Татарстан АССРның экономик һәм социаль үсеше дәүләт планын Татарстан АССР Верховный Советы каравына кертә.
Татарстан АССР Верховный Советы Татарстан АССР Министрлар Советы доклады һәм Татарстан АССР Верховный Советының План-бюджет һәм башка даими комиссияләренең заключениеләре буенча Татарстан АССРның экономик һәм социаль үсешенең дәүләт планын тикшерә һәм раслый.

**137 статья.** Татарстан АССРның дәүләт бюджеты РСФСРның бердәм дәүләт бюджетының состав өлеше булып тора һәм Татарстан АССРның республика бюджетын һәм җирле бюджетларны берләштерә.

**138 статья.** Татарстан АССРның дәүләт бюджеты РСФСР һәм Татарстан АССРның экономик һәм социаль үсеше дәүләт планнары, РСФСР дәүләт бюджеты нигезендә Татарстан АССР Министрлар Советы тарафыннан эшләнә һәм Татарстан АССР Министрлар Советы доклады, Татарстан АССР Верховный Советының План-бюджет һәм башка даими комиссияләренең заключениеләре буенча Татарстан АССР Верховный Советы тарафыннан расланa.

**139 статья.** Татарстан АССР экономик һәм социаль үсеше дәүләт планнарының һәм Татарстан АССР дәүләт бюджетының үтәлеше турындагы отчетлар Татарстан АССР Верховный Советы тарафыннан карала һәм раслана. План һәм бюджет үтәлешенең гомуми күрсәткечләре бөтенхалык игътибарына игълан ителә.





# VIII.
# СУД ЭШЛӘРЕ, АРБИТРАЖ ҺӘМ ПРОКУРОР НАДЗОРЫ

## 15 БҮЛЕК.
## СУД ҺӘМ АРБИТРАЖ

**140 статья.** Татарстан АССРда суд эшләре фәкать суд тарафыннан гына тормышка ашырыла.
Татарстан АССР судларына Татарстан АССР Верховный Суды һәм район (шәһәр) халык судлары керә.
Татарстан АССР судларының оештырылуы һәм эш тәртибе ССР Союзы, РСФСР законнары һәм шушы Конституция белән билгеләнә.

**141 статья.** Татарстан АССРның барлык судлары судьяларның һәм халык утырышчыларының сайланып куелуы нигезендә оештырыла.
Район (шәһәр) халык судларының халык судьялары район (шәһәр) гражданнары тарафыннан гомуми, тигез һәм туры сайлау хокукы нигезендә яшерен тавыш бирү юлы белән бишеллык срокка сайланалар. Район (шәһәр) халык судларының халык утырышчылары гражданнарның эш яки тору урыннарында үткәрелә торган җыелышларда ачык тавыш бирү юлы белән ике ел ярым срокка сайланалар.
Судьялар һәм халык утырышчылары сайлаучылар яки үзләрен сайлаган органнар алдында җаваплы, аларга отчет бирәләр һәм закон белән билгеләнгән тәртиптә алар тарафыннан кире чакырып алынырга мөмкин.

**142 статья.** Татарстан АССР Верховный Суды – Татарстан АССРның югары суд органы, һәм ул республиканың район (шәһәр) халык судларының суд эшчәнлегенә надзорны тормышка ашыра.
Татарстан АССР Верховный Суды Татарстан АССР Верховный Советы тарафыннан Председатель, аның урынбасарлары, членнар һәм халык утырышчылары составында бишеллык срокка сайлана.

**143 статья.** Барлык судларда гражданлык һәм җинаять эшләрен карау коллегиаль рәвештә тормышка ашырыла; беренче инстанция судында халык утырышчылары катнашында алып барыла. Суд эшләрен караганда халык утырышчылары судьяга бирелгән барлык хокуклардан файдаланалар.

**144 статья.** Судьялар һәм халык утырышчылары бәйсез һәм законга гына буйсыналар.

**145 статья.** Татарстан АССРда суд эшләре гражданнарның закон һәм суд алдында тигез булуы нигезендә тормышка ашырыла.

**146 статья.** Барлык судларда эшләр ачык рәвештә карала. Закон белән билгеләнгән очракларда гына, суд эшләрен алып баруның кагыйдәләрен саклап, эшләрне ябык суд утырышында карауга юл куела.

**147 статья.** Гаепләнүчегә яклану хокукы тәэмин ителә.

**148 статья.** Татарстан АССРда суд эше татар яки рус телендә, яки шул урындагы күпчелек халык сөйләшә торган телдә алып барыла. Эштә катнашучы һәм суд эше алып барыла торган телне белмәүче кешеләргә тәрҗемәче аркылы эшнең материаллары белән тулысынча танышу, суд эшләрендә катнашу хокукы һәм судта ана телендә сөйләү хокукы тәэмин ителә.

**149 статья.** Суд хөкеме карарыннан башка һәм законга туры килмәгәндә беркем дә җинаять эшләүдә гаепле дип танылa алмый, шулай ук җинаять җәзасына тартыла алмый.

**150 статья.** Гражданнар һәм оешмаларга юридик ярдәм күрсәтү өчен адвокатлар коллегиясе эшли. Законда каралган очракларда гражданнарга юридик ярдәм түләүсез күрсәтелә.
Адвокатураның оештырылуы һәм эш тәртибе ССР Союзы һәм РСФСР законнары белән билгеләнә.

**151 статья.** Судта гражданлык һәм җинаять эшләрен караганда җәмәгать оешмалары һәм хезмәт коллективлары вәкилләре катнаша ала.

**152 статья.** Предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар арасындагы хуҗалык бәхәсләрен хәл итү дәүләт арбитражы органнары тарафыннан үз компетенцияләре чикләрендә тормышка ашырыла.

## 16 БҮЛЕК.
## ПРОКУРАТУРА

**153 статья.** Татарстан АССР территориясендә барлык министрлыклар, дәүләт комитетлары һәм ведомстволар, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар, халык депутатлары җирле Советларының башкаручы һәм идарә итүче органнары, колхозлар, кооператив һәм башка җәмәгать оешмалары, хезмәт урынындагы кешеләр, шулай ук гражданнар тарафыннан законнарның төгәл һәм бердәй үтәлүенә югары надзор СССР Генеральный прокуроры, аңа буйсынучы РСФСР Прокуроры, Татарстан АССР Прокуроры һәм түбәнге прокурорлар тарафыннан тормышка ашырыла.

**154 статья.** Татарстан АССР Прокуроры СССР Генеральный прокуроры тарафыннан билгеләнә.
Район һәм шәһәр прокурорлары РСФСР Прокуроры тарафыннан билгеләнә һәм СССР Генеральный прокуроры тарафыннан раслана.

**155 статья.** Татарстан АССР Прокурорының һәм барлык түбәнге прокурорларның вәкаләт срогы – биш ел.

**156 статья.** Прокуратура органнары үз вәкаләтләрен, СССР Генеральный прокурорына гына буйсынган хәлдә, нинди дә булса җирле органнарга бәйсез рәвештә тормышка ашыралар.





## IX.
## ТАТАРСТАН АССРНЫҢ ГЕРБЫ, ФЛАГЫ ҺӘМ БАШКАЛАСЫ

**157 статья.** Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының Дәүләт гербы РСФСРның Дәүләт гербыннан гыйбарәт. Ул рус телендә «РСФСР» һәм рус һәм татар телләрендә «Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!» дигән язулы кызыл фонда кояш нурлары эчендә башаклар белән әйләндереп алынган урак һәм чүкеч сурәтеннән гыйбарәт. «РСФСР» дигән язу астында ваграк хәрефләр белән «Татарстан АССР» дип язылган. Гербның югары ягында – биш почмаклы йолдыз.

**158 статья.** Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының Дәүләт флагы РСФСРның Дәүләт флагыннан гыйбарәт. Ул – сап янында флагның бөтен киңлегенә сузылган һәм флаг озынлыгының сигездән бер өлешен алып торган сыек зәңгәр полосалы турыпочмаклы кызыл тукымадан гыйбарәт. Кызыл тукыманың югарыгы сул почмагында алтын урак һәм чүкеч һәм алар өстендә алтын кайма белән әйләндереп алынган бишпочмаклы кызыл йолдыз сурәте төшерелгән. Сурәт астында алтын хәрефләр белән «Татарская АССР» дип язылган. Флаг киңлегенең озынлыгына нисбәте – 1:2.

**159 статья.** Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының башкаласы – Казан шәһәре.

## X.
## ТАТАРСТАН АССР КОНСТИТУЦИЯСЕНЕҢ ГАМӘЛДӘ БУЛУЫ ҺӘМ АНЫ ҮЗГӘРТҮ ТӘРТИБЕ

**160 статья.** Татарстан АССР дәүләт органнарының барлык законнары һәм башка актлары Татарстан АССР Конституциясе нигезендә һәм аңа туры китереп чыгарылалар.

**161 статья.** Татарстан АССР Конституциясен үзгәртү Татарстан АССР Верховный Советының Татарстан АССР Верховный Советындагы барлык депутатларның өчтән ике өлешеннән ким булмаган күпчелеге тарафыннан кабул ителгән карары белән эшләнә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯСЕ • КОНСТИТУЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН •

20

# КОНСТИТУЦИЯ

## Основной закон

## ТАТАРСКОЙ АВТОНОМНОЙ СОВЕТСКОЙ СОЦИАЛИСТИЧЕСКОЙ РЕСПУБЛИКИ

**Принята 31 мая 1978 г.**
**на IX сессии Верховного Совета**
**Татарской Автономной**
**Советской Социалистической Республики**
**девятого созыва.**

**1978 г.**

# КОНСТИТУЦИЯ
# Основной закон Татарской Автономной Советской Социалистической Республики

**Народ Татарской Автономной Советской Социалистической Республики, руководствуясь идеями научного коммунизма, сознавая себя неотъемлемой частью всего советского народа, в соответствии с Конституцией Союза ССР и Конституцией РСФСР принимает и провозглашает настоящую Конституцию.**

## I. ОСНОВЫ ОБЩЕСТВЕННОГО СТРОЯ И ПОЛИТИКИ ТАТАРСКОЙ АССР

### ГЛАВА 1. ПОЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА

**Статья 1.** Татарская Автономная Советская Социалистическая Республика есть социалистическое общенародное государство, выражающее волю и интересы рабочих, крестьян и интеллигенции, трудящихся республики всех национальностей.

**Статья 2.** Вся власть в Татарской АССР принадлежит народу.
Народ осуществляет государственную власть через Советы народных депутатов, составляющие политическую основу Татарской АССР.
Все другие государственные органы подконтрольны и подотчетны Советам народных депутатов.

**Статья 3.** Организация и деятельность Советского государства строятся в соответствии с принципом демократического централизма: выборностью всех органов государственной власти снизу доверху, подотчетностью их народу, обязательностью решений вышестоящих органов для нижестоящих. Демократический централизм сочетает единое руководство с инициативой и творческой активностью на местах, с ответственностью каждого государственного органа и должностного лица за порученное дело.

**Статья 4.** Советское государство, все его органы действуют на основе социалистической законности, обеспечивают охрану правопорядка, интересов общества, прав и свобод граждан.
Государственные и общественные организации, должностные лица обязаны соблюдать Конституцию СССР, Конституцию РСФСР, Конституцию Татарской АССР и советские законы.

**Статья 5.** Наиболее важные вопросы государственной жизни выносятся на всенародное обсуждение, а также ставятся на всенародное голосование референдум.
Статья 6. Руководящей и направляющей силой советского общества, ядром его политической системы, государственных и общественных организаций является Коммунистическая партия Советского Союза. КПСС существует для народа и служит народу.
Вооруженная марксистско-ленинским учением, Коммунистическая партия определяет генеральную перспективу развития общества, линию внутренней и внешней политики СССР,





руководит великой созидательной деятельностью советского народа, придает планомерный, научно обоснованный характер его борьбе за победу коммунизма.
Все партийные организации действуют в рамках Конституции СССР.

**Статья 7.** Профессиональные союзы, Всесоюзный Ленинский Коммунистический Союз Молодежи, кооперативные и другие общественные организации в соответствии со своими уставными задачами участвуют в управлении государственными и общественными делами, в решении политических, хозяйственных и социально-культурных вопросов.

**Статья 8.** Трудовые коллективы участвуют в обсуждении и решении государственных и общественных дел, в планировании производства и социального развития, в подготовке и расстановке кадров, в обсуждении и решении вопросов управления предприятиями и учреждениями, улучшения условий труда и быта, использования средств, предназначенных для развития производства, а также на социально-культурные мероприятия и материальное поощрение.
Трудовые коллективы развивают социалистическое соревнование, способствуют распространению передовых методов работы, укреплению трудовой дисциплины, воспитывают своих членов в духе коммунистической нравственности, заботятся о повышении их политической сознательности, культуры и профессиональной квалификации.

**Статья 9.** Основным направлением развития политической системы советского общества является дальнейшее развертывание социалистической демократии: все более широкое участие граждан в управлении делами государства и общества, совершенствование государственного аппарата, повышение активности общественных организаций, усиление народного контроля, укрепление правовой основы государственной и общественной жизни, расширение гласности, постоянный учет общественного мнения.

### ГЛАВА 2. ЭКОНОМИЧЕСКАЯ СИСТЕМА

**Статья 10.** Основу экономической системы Татарской АССР составляет социалистическая собственность на средства производства в форме государственной общенародной и колхозно-кооперативной собственности.
Социалистической собственностью является также имущество профсоюзных и иных общественных организаций, необходимое им для осуществления уставных задач.
Государство охраняет социалистическую собственность и создает условия для ее приумножения.
Никто не вправе использовать социалистическую собственность в целях личной наживы и в других корыстных целях.

**Статья 11.** Государственная собственность – общее достояние всего советского народа, основная форма социалистической собственности.
В исключительной собственности государства находятся: земля, ее недра, воды, леса. Государству принадлежат основные средства производства в промышленности, строительстве и сельском хозяйстве, средства транспорта и связи, банки, имущество организованных государством торговых, коммунальных и иных предприятий, основной городской жилищный фонд, а также другое имущество, необходимое для осуществления задач государства.

**Статья 12.** Собственностью колхозов и других кооперативных организаций, их объединений являются средства производства и иное имущество, необходимое им для осуществления уставных задач.
Земля, занимаемая колхозами, закрепляется за ними в бесплатное и бессрочное пользование.
Государство содействует развитию колхозно-кооперативной собственности и ее сближению с государственной.
Колхозы, как и другие землепользователи, обязаны эффективно использовать землю, бережно относиться к ней, повышать ее плодородие.

**Статья 13.** Основу личной собственности граждан Татарской АССР составляют трудовые доходы. В личной собственности могут находиться предметы обихода, личного потребления, удобства и подсобного домашнего хозяйства, жилой дом и трудовые сбережения. Личная собственность граждан и право ее наследования охраняются государством.
В пользовании граждан могут находиться участки земли, предоставляемые в установленном законом порядке для ведения подсобного хозяйства включая содержание скота и птицы, садоводства и огородничества, а также для индивидуального жилищного строительства. Граждане обязаны рационально использовать предоставленные им земельные участки. Государство и колхозы оказывают содействие гражданам в ведении подсобного хозяйства.
Имущество, находящееся в личной собственности или в пользовании граждан, не должно служить для извлечения нетрудовых доходов, использоваться в ущерб интересам общества.

**Статья 14.** Источником роста общественного богатства, благосостояния народа и каждого советского человека является свободный от эксплуатации труд советских людей.
В соответствии с принципом социализма «От каждого – по способностям, каждому – по труду» государство осуществляет контроль за мерой труда и потребления. Оно определяет размер налога на доходы, подлежащие налогообложению.
Общественно полезный труд и его результаты определяют положение человека в обществе.
Государство, сочетая материальные и моральные стимулы, поощряя новаторство, творческое отношение к работе, способствует превращению труда в первую жизненную потребность каждого советского человека.

**Статья 15.** Высшая цель общественного производства при социализме - наиболее полное удовлетворение растущих материальных и духовных потребностей людей.
Опираясь на творческую активность трудящихся, социалистическое соревнование, достижения научно-технического прогресса, совершенствуя формы и методы руководства экономикой, государство обеспечивает рост производительности труда, повышение эффективности производства и качества работы, динамичное, планомерное и пропорциональное развитие народного хозяйства.

**Статья 16.** Экономика Татарской АССР является составной частью экономики РСФСР, единого народнохозяйственного комплекса, охватывающего все звенья общественного производства, распределения и обмена на территории СССР.
Руководство экономикой осуществляется на основе государственных планов экономического и социального развития, с учетом отраслевого и территориального принципов, при сочетании централизованного управления с хозяйственной самостоятельностью и инициативой предприятий, объединений и других организаций. При этом активно используются хозяйственный расчет, прибыль, себестоимость, другие экономические рычаги и стимулы.





**Статья 17.** В Татарской АССР в соответствии с законом допускаются индивидуальная трудовая деятельность в сфере кустарно-ремесленных промыслов, сельского хозяйства, бытового обслуживания населения, а также другие виды деятельности, основанные исключительно на личном труде граждан и членов их семей. Государство регулирует индивидуальную трудовую деятельность, обеспечивая ее использование в интересах общества.

**Статья 18.** В интересах настоящего и будущих поколений в Татарской АССР принимаются необходимые меры для охраны и научно обоснованного, рационального использования земли и ее недр, водных ресурсов, растительного и животного мира, для сохранения в чистоте воздуха и воды, обеспечения воспроизводства природных богатств и улучшения окружающей человека среды.

## ГЛАВА 3.
## СОЦИАЛЬНОЕ РАЗВИТИЕ И КУЛЬТУРА

**Статья 19.** Социальную основу Татарской АССР составляет нерушимый союз рабочих, крестьян и интеллигенции.
Государство способствует усилению социальной однородности общества - стиранию классовых различий, существенных различий между городом и деревней, умственным и физическим трудом, всестороннему развитию и сближению всех наций и народностей СССР.

**Статья 20.** В соответствии с коммунистическим идеалом «Свободное развитие каждого есть условие свободного развития всех» государство ставит своей целью расширение реальных возможностей для применения гражданами своих творческих сил, способностей и дарований, для всестороннего развития личности.

**Статья 21.** Государство заботится об улучшении условий и охране труда, его научной организации, о сокращении, а в дальнейшем и полном вытеснении тяжелого физического труда на основе комплексной механизации и автоматизации производственных процессов во всех отраслях народного хозяйства.

**Статья 22.** В Татарской АССР последовательно претворяется в жизнь программа превращения сельскохозяйственного труда в разновидность индустриального; расширения в сельской местности сети учреждений народного образования, культуры, здравоохранения, торговли и общественного питания, бытового обслуживания и коммунального хозяйства; преобразования сел и деревень в благоустроенные поселки.

**Статья 23.** На основе роста производительности труда государство неуклонно осуществляет курс на повышение уровня оплаты труда, реальных доходов трудящихся.
В целях более полного удовлетворения потребностей советских людей создаются общественные фонды потребления. Государство при широком участии общественных организаций и трудовых коллективов обеспечивает рост и справедливое распределение этих фондов.

**Статья 24.** В Татарской АССР действуют и развиваются государственные системы здравоохранения, социального обеспечения, торговли и общественного питания, бытового обслуживания и коммунального хозяйства.

Государство поощряет деятельность кооперативных и других общественных организаций во всех сферах обслуживания населения. Оно содействует развитию массовой физической культуры и спорта.

**Статья 25.** В Татарской АССР существует и совершенствуется единая система народного образования, которая обеспечивает общеобразовательную и профессиональную подготовку граждан, служит коммунистическому воспитанию, духовному и физическому развитию молодежи, готовит ее к труду и общественной деятельности.

**Статья 26.** В соответствии с потребностями общества государство обеспечивает планомерное развитие науки и подготовку научных кадров, организует внедрение результатов научных исследований в народное хозяйство и другие сферы жизни.

**Статья 27.** Государство заботится об охране, приумножении и широком использовании духовных ценностей для нравственного и эстетического воспитания советских людей, повышения их культурного уровня.
В Татарской АССР всемерно поощряется развитие профессионального искусства и народного художественного творчества.

# II.
# ГОСУДАРСТВО И ЛИЧНОСТЬ

## ГЛАВА 4.
## ГРАЖДАНСТВО ТАТАРСКОЙ АССР. РАВНОПРАВИЕ ГРАЖДАН

**Статья 28.** В соответствии с установленным в СССР единым союзным гражданством каждый гражданин Татарской АССР является гражданином РСФСР и СССР.
Основания и порядок приобретения и утраты советского гражданства определяются Законом о гражданстве СССР.
Граждане РСФСР и других союзных республик пользуются на территории Татарской АССР одинаковыми правами с гражданами Татарской АССР.
Граждане Татарской АССР за границей пользуются защитой и покровительством Советского государства.

**Статья 29.** Граждане Татарской АССР равны перед законом независимо от происхождения, социального и имущественного положения, расовой и национальной принадлежности, пола, образования, языка, отношения к религии, рода и характера занятий, места жительства и других обстоятельств.
Равноправие граждан Татарской АССР обеспечивается во всех областях экономической, политической, социальной и культурной жизни.

**Статья 30.** Женщина и мужчина имеют в Татарской АССР равные права.
Осуществление этих прав обеспечивается предоставлением женщинам равных с мужчинами возможностей в получении образования и профессиональной подготовки, в труде, вознаграждении за него и продвижении по работе, в общественно-политической и культурной деятельности, а также специальными мерами по охране труда и здоровья женщин; созданием условий, позволяющих женщинам сочетать труд с материнством; правовой защитой, материальной и моральной поддержкой материнства и детства, включая предоставление оплачиваемых отпусков и других льгот беременным женщинам и матерям, постепенное сокращение рабочего времени женщин, имеющих малолетних детей.



КОНСТИТУЦИЯ (Основной закон)
Татарской Автономной Советской Социалистической Республики (1978 г.)

**Статья 31.** Граждане Татарской АССР различных рас и национальностей имеют равные права.
Осуществление этих прав обеспечивается политикой всестороннего развития и сближения всех наций и народностей СССР, воспитанием граждан в духе советского патриотизма и социалистического интернационализма, возможностью пользоваться родным языком и языками других народов СССР.
Какое бы то ни было прямое или косвенное ограничение прав, установление прямых или косвенных преимуществ граждан по расовым и национальным признакам, равно как и всякая проповедь расовой или национальной исключительности, вражды или пренебрежения – наказываются по закону.

**Статья 32.** Иностранным гражданам и лицам без гражданства в Татарской АССР гарантируются предусмотренные законом права и свободы, в том числе право на обращение в суд и иные государственные органы для защиты принадлежащих им личных, имущественных, семейных и иных прав.
Находящиеся на территории Татарской АССР иностранные граждане и лица без гражданства обязаны уважать Конституцию СССР, Конституцию РСФСР, Конституцию Татарской АССР и соблюдать советские законы.

## ГЛАВА 5.
## ОСНОВНЫЕ ПРАВА, СВОБОДЫ И ОБЯЗАННОСТИ ГРАЖДАН ТАТАРСКОЙ АССР

**Статья 33.** Граждане Татарской АССР обладают всей полнотой социально-экономических, политических и личных прав и свобод, провозглашенных и гарантируемых Конституцией СССР, Конституцией РСФСР, Конституцией Татарской АССР и советскими законами. Социалистический строй обеспечивает расширение прав и свобод, непрерывное улучшение условий жизни граждан по мере выполнения программ социально-экономического и культурного развития.
Использование гражданами прав и свобод не должно наносить ущерб интересам общества и государства, правам других граждан.

**Статья 34.** Граждане Татарской АССР имеют право на труд, то есть на получение гарантированной работы с оплатой труда в соответствии с его количеством и качеством и не ниже установленного государством минимального размера, включая право на выбор профессии, рода занятий и работы в соответствии с призванием, способностями, профессиональной подготовкой, образованием и с учетом общественных потребностей.
Это право обеспечивается социалистической системой хозяйства, неуклонным ростом производительных сил, бесплатным профессиональным обучением, повышением трудовой квалификации и обучением новым специальностям, развитием систем профессиональной ориентации и трудоустройства.

**Статья 35.** Граждане Татарской АССР имеют право на отдых.
Это право обеспечивается установлением для рабочих и служащих рабочей недели, не превышающей 41 часа, сокращенным рабочим днем для ряда профессий и производств, сокращенной продолжительностью работы в ночное время, предоставлением ежегодных оплачиваемых отпусков, дней еженедельного отдыха, а также расширением сети культурно-просветительных и оздоровительных учреждений, развитием массового спорта, физической культуры и туризма; созданием благоприятных возможностей для отдыха по месту жительства и других условий рационального использования свободного времени.
Продолжительность рабочего времени и отдыха колхозников регулируется колхозами.

**Статья 36.** Граждане Татарской АССР имеют право на охрану здоровья.
Это право обеспечивается бесплатной квалифицированной медицинской помощью, оказываемой государственными учреждениями здравоохранения; расширением сети учреждений для лечения и укрепления здоровья граждан; развитием и совершенствованием техники безопасности и производственной санитарии; проведением широких профилактических мероприятий; мерами по оздоровлению окружающей среды; особой заботой о здоровье подрастающего поколения, включая запрещение детского труда, не связанного с обучением и трудовым воспитанием; развертыванием научных исследований, направленных на предупреждение и снижение заболеваемости, на обеспечение долголетней активной жизни граждан.

**Статья 37.** Граждане Татарской АССР имеют право на материальное обеспечение в старости, в случае болезни, полной или частичной утраты трудоспособности, а также потери кормильца.
Это право гарантируется социальным страхованием рабочих, служащих и колхозников, пособиями по временной нетрудоспособности; выплатой за счет государства и колхозов пенсий по возрасту, инвалидности и по случаю потери кормильца; трудоустройством граждан, частично утративших трудоспособность; заботой о престарелых гражданах и об инвалидах; другими формами социального обеспечения.

**Статья 38.** Граждане Татарской АССР имеют право на жилище.
Это право обеспечивается развитием и охраной государственного и общественного жилищного фонда, содействием кооперативному и индивидуальному жилищному строительству, справедливым распределением под общественным контролем жилой площади, предоставляемой по мере осуществления программы строительства благоустроенных жилищ, а также невысокой платой за квартиру и коммунальные услуги. Граждане Татарской АССР должны бережно относиться к предоставленному им жилищу.

**Статья 39.** Граждане Татарской АССР имеют право на образование.
Это право обеспечивается бесплатностью всех видов образования, осуществлением всеобщего обязательного среднего образования молодежи, широким развитием профессионально-технического, среднего специального и высшего образования на основе связи обучения с жизнью, с производством; развитием заочного и вечернего образования; предоставлением государственных стипендий и льгот учащимся и студентам; бесплатной выдачей школьных учебников; возможностью обучения в школе на родном языке; созданием условий для самообразования.

**Статья 40.** Граждане Татарской АССР имеют право на пользование достижениями культуры.
Это право обеспечивается общедоступностью ценностей отечественной и мировой культуры, находящихся в государственных и общественных фондах; развитием и равномерным





размещением культурно-просветительных учреждений на территории республики; развитием телевидения и радио, книгоиздательского дела и периодической печати, сети бесплатных библиотек; расширением культурного обмена с зарубежными государствами.

**Статья 41.** Гражданам Татарской АССР в соответствии с целями коммунистического строительства гарантируется свобода научного, технического и художественного творчества. Она обеспечивается широким развертыванием научных исследований, изобретательской и рационализаторской деятельности, развитием литературы и искусства. Государство создает необходимые для этого материальные условия, оказывает поддержку добровольным обществам и творческим союзам, организует внедрение изобретений и рационализаторских предложений в народное хозяйство и другие сферы жизни.
Права авторов, изобретателей и рационализаторов охраняются государством.

**Статья 42.** Граждане Татарской АССР имеют право участвовать в управлении государственными и общественными делами, в обсуждении и принятии законов и решений общегосударственного и местного значения.
Это право обеспечивается возможностью избирать и быть избранными в Советы народных депутатов и другие выборные государственные органы, принимать участие во всенародных обсуждениях и голосованиях, в народном контроле, в работе государственных органов, общественных организаций и органов общественной самодеятельности, в собраниях трудовых коллективов и по месту жительства.

**Статья 43.** Каждый гражданин Татарской АССР имеет право вносить в государственные органы и общественные организации предложения об улучшении их деятельности, критиковать недостатки в работе.
Должностные лица обязаны в установленные сроки рассматривать предложения и заявления граждан, давать на них ответы и принимать необходимые меры.
Преследование за критику запрещается. Лица, преследующие за критику, привлекаются к ответственности.

**Статьи 44.** В соответствии с интересами народа и в целях укрепления и развития социалистического строя гражданам Татарской АССР гарантируются свободы: слова, печати, собраний, митингов, уличных шествий и демонстраций.
Осуществление этих политических свобод обеспечивается предоставлением трудящимся и их организациям общественных зданий, улиц и площадей, широким распространением информации, возможностью использования печати, телевидения и радио.

**Статья 45.** В соответствии с целями коммунистического строительства граждане Татарской АССР имеют право объединяться в общественные организации, способствующие развитию политической активности и самодеятельности, удовлетворению их многообразных интересов.
Общественным организациям гарантируются условия для успешного выполнения ими своих уставных задач.

**Статья 46.** Гражданам Татарской АССР гарантируется свобода совести, то есть право исповедовать любую религию или не исповедовать никакой, отправлять религиозные культы или вести атеистическую пропаганду. Возбуждение вражды и ненависти в связи с религиозными верованиями запрещается.

Мечеть и церковь в Татарской АССР отделены от государства и школа – от мечети и церкви.

**Статья 47.** Семья находится под защитой государства.
Брак основывается на добровольном согласии женщины и мужчины; супруги полностью равноправны в семейных отношениях.
– отмечая несоответствие статуса автономной республики интересам дальнейшего политического, экономического, социального и духовного развития ее многонационального народа;
– реализуя неотъемлемое право татарской нации, всего народа республики на самоопределение;
– стремясь создать демократическое правовое государство,

**1.** ПРОВОЗГЛАШАЕТ государственный суверенитет Татарии и ПРЕОБРАЗУЕТ ее в Татарскую Советскую Социалистическую Республику – Республику Татарстан.

**2.** Земля, ее недра, природные богатства и другие ресурсы на территории Татарской ССР являются исключительной собственностью ее народа.

**3.** Татарская ССР гарантирует всем проживающим на ее территории гражданам независимо от их национальности, социального происхождения, вероисповедания, политических убеждений, других различий равные права и свободы человека. В Татарской ССР гарантируется равноправное функционирование татарского и русского языков в качестве государственных, сохранение и развитие языков других национальностей.

**4.** Впредь в качестве официального наименования государства в Конституции, других правовых нормативных актах, в государственной жизни употреблять «Татарская Советская Социалистическая Республика» («Татарская ССР», либо «Республика Татарстан»).
Высший орган государственной власти республики именовать «Верховный Совет Татарской Советской Социалистической Республики», а принимаемые им акты – актами Верховного Совета Татарской Советской Социалистической Республики.

**5.** Настоящая Декларация является основой для разработки Конституции Татарской ССР, развития законодательства Татарской ССР, участия Татарской ССР в подготовке и заключении Союзного договора, договоров с РСФСР и другими республиками, вынесения наиболее важных вопросов государственного строительства Татарской ССР и ее отношений с Союзом ССР, РСФСР и другими республиками на обсуждение ее народа.
Конституция и законы Татарской ССР обладают верховенством на всей территории Татарской ССР.

**6.** До принятия новой Конституции Татарской ССР, других законов и нормативных актов Татарской ССР на территории Татарской ССР продолжают действовать законы и подзаконные акты Татарской ССР, РСФСР и Союза ССР, не противоречащие Декларации о государственном суверенитете Татарской ССР.
Настоящая Декларация вступает в силу с момента ее принятия.

Председатель Верховного Совета
Татарской Советской Социалистической Республики М. ШАЙМИЕВ

г. Казань, 30 августа 1990 года
№ 334-XII

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯСЕ • КОНСТИТУЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН •

20

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯСЕ

**1992 елның 6 ноябрендә Татарстан Республикасы уникенче чакырылыш Югары Советының XII сессиясендә кабул ителде**

**1992 ел**

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯСЕ

**Бу Конституция Татарстан Республикасының дәүләт статусы турында халыкның тавыш бирүе (референдум) йомгаклары нигезендә кабул ителә һәм игълан ителә.**

# I. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ һӘМ ИҖТИМАГЫЙ ТӨЗЕЛЕШЕ НИГЕЗЛӘРЕ

## 1 БҮЛЕК. ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ СИСТЕМА

**1 статья.** Татарстан Республикасы – республиканың күпмилләтле барлык халкы ихтыярын һәм мәнфәгатен чагылдыручы суверен демократик дәүләт.
Дәүләт суверенитетын һәм вәкаләтләрен халык билгели.
Дәүләт суверенитеты – Татарстан Республикасының төп билгесе.

**2 статья.** Татарстан Республикасында бөтен хакимият халык кулында. Халык дәүләт хакимиятен шушы Конституция нигезендә турыдан-туры, шул исәптән референдум юлы белән дә, дәүләт органнары системасы аша да гамәлгә ашыра. Татарстан Республикасы Конституциясе Татарстан Республикасы Югары Советы тарафыннан яки референдум юлы белән кабул ителә.
Халык депутатлары Советлары, халыкның вәкиллекле органнары буларак, дәүләтнең сәяси нигезен тәшкил итә.
Аерым шәхес яки шәхесләр төркеме Татарстан Республикасында дәүләт хакимиятен гамәлгә ашыру хокукын үзләштерә алмый.

**3 статья.** Граждан белән дәүләт арасындагы мөнәсәбәтләр иң зур социаль хәзинә булган кеше хокуклары өстенлегенә, гражданнарның дәүләт эшләрен идарә итүдә катнашуына нигезләнә. Үзара мөнәсәбәтләрендә граждан һәм дәүләт бер-берсе алдында җаваплы.
Татарстан Республикасы сәяси, икътисади, социаль һәм мәдәни тормышның барлык өлкәләрендә гражданнарның тигез хокуклылыгын гарантияли.
Халыкның барлык катлауларының, барлык милләт гражданнарының бер-берсен хөрмәт итүе, ирекле һәм тигез хокуклы хезмәттәшлеге Татарстан Республикасының иҗтимагый нигезен тәшкил итә.

**4 статья.** Татарстан Республикасында дәүләт телләре – тигез хокуклы татар һәм рус телләре.

**5 статья.** Татарстан Республикасында дәүләт органнарының эшчәнлеге хокукый дәүләт принципларында: законнарның өстенлеге, аларның тайпылышсыз үтәлеше, закон чыгару, башкару һәм суд хакимиятләренең аерым-аерым булуы принципларында гамәлгә ашырыла.

**6 статья.** Сәяси партияләр, профессиональ союзлар, массакүләм хәрәкәтләр һәм башка





җәмәгать берләшмәләре дәүләт эшләрен идарә итүдә дәүләт хакимиятенең сайлаулы органнарындагы үз вәкилләре аша катнашырга хокуклы. Үзләренең программа һәм уставларында каралган вазифаларны үтәгәндә алар Татарстан Республикасы Конституциясе һәм законнары чикләрендә эш итә.
Татарстан Республикасының Конституция төзелешен һәм бөтенлеген көчләп үзгәртүне, аның иминлеген какшатуны, социаль, раса, милли һәм дини ызгыш кабызуны максат итеп куйган партия, оешма һәм хәрәкәтләр төзүгә, аларның эшчәнлегенә юл куелмый, бу максатта массакүләм информация чараларын, шулай ук башка чараларны файдалану тыела.

**7 статья.** Дәүләт үз эшчәнлеген социаль гаделлек принцибында оештыра, халыкның барлык катлауларына лаеклы тормыш дәрәҗәсе тәэмин итү өчен, җәмгыятьнең социаль-икътисади һәм мәдәни үсеше өчен кирәкле шартлар тудыра, экология хәвефсезлеген һәм табигатьтән акыллы файдалануны тәэмин итә.

**8 статья.** Дәүләтләр һәм халыклар арасындагы бәхәсләрне хәл итү чарасы буларак, көч куллануны һәм сугышны Татарстан Республикасы кире кага.
Татарстан Республикасы территориясе – күпләп юк итү коралыннан азат зона.
Татарстан Республикасында сугышны пропагандалау тыела.

## 2 БҮЛЕК. ИКЪТИСАДИ СИСТЕМА

**9 статья.** Җир, җир асты, су, урман һәм башка табигый байлыклар, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы, дәүләт бюджеты акчалары, дәүләт банклары активлары, Татарстан халыкларының мәдәни һәм тарихи хәзинәләре, шулай ук республиканың хуҗалык мөстәкыйльлеген, матди һәм рухи мәдәниятен саклауны тәэмин итә торган башка мөлкәтләр – бөтенхалык байлыгы.

**10 статья.** Татарстан Республикасы икътисадының нигезен иҗтимагый базар хуҗалыгы тәшкил итә, анда закон нигезендә хуҗалык эшчәнлеге ирекле һәм милекнең күптөрлелеге, аларны хокукый яклау өчен тигез шартлар тәэмин ителә.
Икътисади мөнәсәбәтләр граждан белән дәүләт, кулланучы белән җитештерүче, эш бирүче белән эш бирүче арасындагы социаль тиңлек нигезендә төзелә.
Дәүләт хуҗалык эшчәнлеген, җәмгыять мәнфәгатьләренә туры китереп, закон билгеләгән чикләрдә җайга сала.

**11 статья.** Татарстан Республикасында хуҗалык эшчәнлеге хосусый, дәүләт, коммуналь милек һәм җәмәгать берләшмәләре милке нигезендә гамәлгә ашырыла.
Җир участоклары, закон тыймаган теләсә кайсы өлкәдә файдаланыла торган башка объектлар хосусый милек була ала.
Татарстан Республикасында башка дәүләтләр, халыкара оешмалар, чит илләрнең юридик затлары һәм гражданнары, гражданлыксыз шәхесләре милкенә юл куела, шулай ук гражданнар, юридик затлар һәм дәүләтләр милкен берләштерү рөхсәт ителә.

**12 статья.** Милек кагылгысыз. Законлы милек хуҗасының хокукын чикләүгә юл куелмый.
Милек дәүләт һәм җәмәгать мәнфәгатьләренә, кеше хокукларына, ирегенә һәм абруена зыян китерү максатында файдаланылмаска тиеш.

Милекне тартып алу закон нигезендә реквизиция һәм конфискация тәртибендә генә рөхсәт ителә.

**13 статья.** Татарстан Республикасының һәм аның гражданнарының Татарстан Республикасы территориясеннән читтәге милке дәүләт тарафыннан яклана.

**14 статья.** Башка дәүләтләр, юридик һәм физик затлар, шулай ук халыкара оешмалар милкенең хокук тәртибе Татарстан Республикасы законнары һәм халыкара килешүләр белән билгеләнә.

**15 статья.** Татарстан Республикасы икътисады базар хуҗалыгы принципларында эшли. Дәүләт республика икътисадын үстерүне, предприятие һәм оешмаларның хуҗалык эшчәнлегенә катнашмыйча, икътисади һәм социаль үсеш программалары, салым, кредит, инвестиция һәм амортизация сәясәте белән, халыкның тормыш дәрәҗәсен билгели торган товарларга һәм хезмәтләргә, шулай ук монополист предприятиеләр продукциясенә бәяләр билгеләү сәясәте белән җайга сала. Татарстан Республикасы законнарын һәм халыкара йөкләмәләрен бозмаган очракта икътисади мөстәкыйль предприятиеләр эшчәнлеген административ чикләүгә юл куелмый.
Көндәшлекне чикләүгә яки бетерүгә юнәлтелгән монополия эшчәнлеге тыела.

**16 статья.** Татарстан Республикасының башка дәүләтләр белән сәүдә-икътисади мөнәсәбәтләре килешүләр нигезендә оештырыла.

**17 статья.** Татарстан Республикасы кулланучы мәнфәгатьләрен яклый һәм аның хокукларын яклауга юнәлтелгән иҗтимагый эшчәнлекне хуплый. Кулланучылар товар җитештерүче һәм хезмәт күрсәтүче китергән зыянны закон билгеләгән тәртиптә түләттерергә хаклы.

**18 статья.** Татарстан Республикасы җир, җир асты байлыкларының, су, урман, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясының саклануын тәэмин итә, табигатьтән түләүле файдалану нигезендә табигый байлыкларны торгызу һәм арттыру, мохитне яхшырту чаралары күрә.
Җир участогы хуҗалары, җир биләүче һәм җирдән файдаланучылар, табигатьтән файдаланучы башкалар җирнең уңдырышлылыгын сакларга бурычлы.
Хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә мохиткә, гражданнарның сәламәтлеге һәм мөлкәтенә китерелгән зыян Татарстан Республикасы законнары нигезендә түләттерелергә тиеш. Татарстан Республикасы законнарын бозучы җир биләүче һәм җирдән файдаланучылар, табигатьтән файдаланучы башкалар эшчәнлеге республиканың дәүләт органнары тарафыннан туктатып торыла. Мохитне саклау законнарын бозуда гаепле физик һәм юридик затлар закон нигезендә җавапка тартыла.

# II.
# ШӘХЕС ҺӘМ ДӘҮЛӘТ

## 3 БҮЛЕК.
## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ГРАЖДАНЛЫГЫ. ГРАЖДАННАРНЫҢ ТИГЕЗ ХОКУКЛЫЛЫГЫ

**19 статья.** Татарстан Республикасының үз гражданлыгы бар. Татарстан Республикасы гражданлыгын алу яки аннан ваз кичү нигезләре һәм тәртибе Татарстан Республикасының





Гражданлык турындагы законы белән билгеләнә.
Татарстан Республикасы гражданнары Россия Федерациясе – Россия гражданлыгына ия.
Татарстан Республикасы гражданнары башка дәүләтләр гражданлыгын ала алалар, моны гамәлгә ашыру шартлары Татарстан Республикасының башка дәүләтләр белән төзегән килешү һәм шартнамәләре белән билгеләнә.
Татарстан Республикасы гражданнары ике гражданлыкны саклый яки аңардан баш тарта ала.
Һәр кеше гражданлыкны сайларга һәм аны үзгәртергә хокуклы. Гражданлыктан яки гражданлыкны үзгәртү хокукыннан мәхрүм итү тыела.

**20 статья.** Татарстан Республикасының барлык гражданнары тигез хокуклы һәм тигез бурычлы. Чыгышына, социаль һәм мөлкәти хәленә, нинди расадан һәм милләттән булуына, җенесенә, белеменә, теленә, сәяси карашына, дини мәсләгенә, шөгыленең төренә һәм үзенчәлегенә, торган урынына һәм башкаларга карамастан алар дәүләт тарафыннан яклануга тигез хокуклы.
Гражданнарга туган теленнән файдалану гарантияләнә.
Гражданнарның Конституциядә каралган хокуклары, ирек һәм бурычлары турыдан-туры Конституция нигезендә гамәлгә ашырыла.
Конституциядә каралган хокукларны, ирек һәм бурычларны гамәлгә ашыру, саклау һәм яклау тәртибе законнар белән билгеләнә.

**21 статья.** Татарстан Республикасының барлык гражданнарына гомумтанылган халыкара хокук нормалары, шулай ук Татарстан Республикасының халыкара килешүләре нигезендә Татарстан Республикасы Конституциясендә каралган хокуклар һәм ирек гарантияләнә.
Татарстан Республикасының читтә яшәүче һәр гражданына Татарстан Республикасының хокукый яклавы һәм ярдәме гарантияләнә.
Гражданнарның хокуклары һәм ирекләре закон һәм суд карары нигезендә генә чикләнә яки туктатып торыла ала.

**22 статья.** Гражданнарның хокукларын турыдан-туры яки башкача чикләгән яисә раса, милли һәм башка билгеләр буенча аларга өстенлекләр билгеләгән өчен закон нигезендә җәза бирелә.

**23 статья.** Чит ил гражданнары һәм гражданлыксыз шәхесләр, законда башкача каралмаган булса, Конституциядәге барлык хокуклардан һәм иректән Татарстан Республикасы гражданнары белән тигез файдалана.
Чит ил гражданнарының һәм гражданлыксыз шәхесләрнең хокукый хәле Татарстан Республикасы законнары һәм халыкара килешүләре белән җайга салына.
Татарстан Республикасы территориясендә чит ил гражданнары һәм гражданлыксыз шәхесләр Татарстан Республикасы Конституциясен һәм законнарын ихтирам итәргә һәм үтәргә бурычлы.

## 4 БҮЛЕК.
## КЕШЕ ҺӘМ ГРАЖДАННЫҢ ХОКУКЛАРЫ, ИРЕГЕ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

**24 статья.** Татарстан Республикасы гражданнары шушы Конституциядә каралган шәхси, сәяси, социаль-икътисади һәм мәдәни хокукларга һәм ирекkә тулысынча ия.

**25 статья.** Дәүләт кешенең тормышын, сәламәтлеген, шәхси иреген һәм иминлеген яклый.

**26 статья.** Татарстан Республикасы гражданнарына шәхес кагылгысызлыгы гарантияләнә. Беркем дә законсыз кулга алына һәм ирегеннән мәхрүм ителә алмый. Кулга яки сак астына алынган очракта граждан бу хакта кичекмәстән судка шикаять бирергә хаклы. Хокук бозган өчен җавапка тартылган граждан закон һәм хокукый процедура чикләрендә гаебе исбатланганга кадәр гаепсез дип санала.
Татарстан Республикасы гражданнарына яклану хокукы гарантияләнә.

**27 статья.** Татарстан Республикасы гражданнарына торак кагылгысызлыгы гарантияләнә. Законлы сәбәп булмаганда торакка керергә, анда яшәүчеләр ризалыгыннан башка тентү үткәрергә беркемнең дә хакы юк.

**28 статья.** Татарстан Республикасы гражданнарына хат алышу, телефоннан сөйләшү, телеграф һәм хәбәрләшүнең башка төрләрендә сер саклау тәэмин ителә.

**29 статья.** Татарстан Республикасы гражданнары, инануларына карап, теләсә кайсы динне тотарга ирекле яисә берсен дә тотмаска, дини яки атеистик эшчәнлек белән шөгыльләнергә хокуклы. Дини йолаларны үтәүдә һәркем ирекле.
Дини инануларга бәйле рәвештә дошманлык, нәфрәт һәм милли ызгыш уяту тыела.
Татарстан Республикасында диннәр һәм дини берләшмәләр дәүләттән аерылган.

**30 статья.** Гаилә, ана, ата һәм балалар дәүләт яклавында. Никах хатын-кыз белән ир- атның ирекле килешүенә нигезләнә; гаилә мөнәсәбәтләрендә хатын белән ир тигез хокуклы. Гражданнарның гаилә тормышы закон белән саклана.
Дәүләт гаилә турында кайгырта, ана белән баланың сәламәтлеген саклауга һәм балаларны тәрбияләүгә аерым игътибар бирә.
Татарстан Республикасы гражданнары үз балаларын тәрбияләү өчен җаваплы. Балигъ булган балалар ата-аналарын кайгыртырга һәм аларга ярдәм күрсәтергә бурычлы.

**31 статья.** Һәр граждан Татарстан Республикасы территориясендә ирекле күчеп йөрүгә, яшәү һәм тору урынын сайлауга хаклы. Бу хокукны закон гына чикли ала.

**32 статья.** Һәр кеше Татарстан Республикасы территориясеннән ирекле рәвештә китәргә һәм республикага әйләнеп кайтырга хокуклы.

**33 статья.** Шәхесне ихтирам итү, гражданнарның хокукларын һәм иреген саклау – барлык дәүләт органнарының, җәмәгать берләшмәләре һәм урындагы кешеләрнең бурычы.
Татарстан Республикасы гражданнары намусына һәм абруена, тормышына һәм сәламәтлегенә, шәхси ирегенә һәм мөлкәтенә кул сузудан суд аша якланырга хокуклы.

**34 статья.** Һәр граждан урындагы кешеләрнең, дәүләт органнары һәм җәмәгать оешмаларының гамәленә карата судка шикаять бирергә, шулай ук әхлакый һәм матди зыянны түләтергә хокуклы.

**35 статья.** Татарстан Республикасында һәркемгә сүз, матбугат, фикер һәм инану ирege, аларны тоткарлыксыз белдерү һәм тарату ирege гарантияләнә.





**36 статья.** Татарстан Республикасы гражданнары закон билгеләгән тәртиптә тыныч һәм коралсыз митинг, урамда оешып йөрү, демонстрация һәм пикетлар оештыруга хокуклы.

**37 статья.** Халык мәнфәгатьләренә туры китереп һәм иҗтимагый активлыкны күтәрү максатында Татарстан Республикасы гражданнары сәяси партияләргә, профессиональ союзлар, массакүләм хәрәкәтләргә һәм башка җәмәгать берләшмәләренә берләшергә, гамәлдәге законнар чикләрендә гражданлык инициативасы тәртибендәге чараларда катнашырга хокуклы. Дәүләт аларга устав бурычларын үтәүдә булыша.
Хакимиятнең вәкиллекле органнарында каршы фикерле азчылыкны тәшкил итүчеләрнең хокуклары, ирege һәм кешелек абруе закон белән гарантияләнә.
Эшчәнлекләре Конституциягә каршы килгәндә, сәяси партияләр, профессиональ союзлар, массакүләм хәрәкәтләр һәм башка җәмәгать берләшмәләре суд карары белән таратыла ала.

**38 статья.** Татарстан Республикасы гражданнары сәяси тормышта, дәүләт һәм җәмәгать эшләрен идарә итүдә, гомумреспублика һәм җирле әһәмияттәге законнарның һәм карарларның проектын тикшерүдә, референдумнарда катнашырга хокуклы.

**39 статья.** Закон нигезендә һәр гражданга дәүләт хезмәтенә керү өчен тигез хокук гарантияләнә.

**40 статья.** Татарстан Республикасының һәр гражданы дәүләтнең эчке һәм халыкара тормышының барлык өлкәләре, шул исәптән шәхеснең хокукый статусы мәсьәләләре турында дөрес мәгълүматны тоткарлыксыз алырга һәм таратырга хокуклы.
Дәүләт органнары, җәмәгать берләшмәләре һәм урындагы кешеләр гражданга аның хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы карарлар һәм башка материаллар белән танышу мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

**41 статья.** Татарстан Республикасы гражданнары милеккә һәм аны мирас итүгә хокуклы.

**42 статья.** Татарстан Республикасы гражданнары хезмәткә, ягъни һөнәрен һәм эш урынын сайлау, хезмәткә сәләтен файдалану ирегенә хокуклы. Хезмәт килешүе ирege гарантияләнә. Һәркем хәвефсезлек һәм гигиена таләпләренә туры килә торган хезмәт шартларына, хезмәтенә закон билгеләгән иң аз күләмнән дә ким булмаган түләүгә хокуклы.
Нинди милектән булуына карамастан, барлык предприятие, учреждение һәм оешмаларда эшләүчеләргә дәүләт эшкә алуның, эштән бушатуның һәм хезмәтне саклауның гадел шартларын, хезмәт хокукларын һәм мәнфәгать вәкиллеге ирегeн гарантияли.
Дәүләт балигъ булмаган, физик һәм психик кимчелекле кешеләрнең хезмәткә хокукларын гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыра, гарипләрне, мохтаҗ һәм даими эше булмаган гражданнарны социаль яклауны гарантияли, кирәк очракта аларны өйрәтүне һәм квалификацияләрен үзгәртүне оештыра.
Мәҗбүри хезмәткә суд карары белән, шулай ук Татарстан Республикасының халыкара килешүләрендә каралган очракларда гына юл куела.

**43 статья.** Татарстан Республикасы гражданнарына ялга һәм эштән буш вакытка хокук гарантияләнә. Бу хокук 40 сәгатьтән артык булмаган эш атнасы билгеләү, хезмәт ияләренә ел саен түләүле ял, атна саен ял көннәре бирү, буш вакытны файдалы үткәрү өчен шартлар тудыру белән тәэмин ителә.

**44 статья.** Татарстан Республикасының һәр гражданы сәламәтлеген саклауга, шул исәптән сәламәтлек саклауның дәүләт һәм башка учреждениеләре закон тәртибендә күрсәтә торган медицина ярдәменә хокуклы.
Дәүләт гражданнарның сәламәтлеген ныгытуга, физик культура һәм спортны үстерүгә ярдәм итүче эшчәнлекне хуплый.

**45 статья.** Татарстан Республикасы гражданнары чиста табигать мохитенә хокуклы.

**46 статья.** Татарстан Республикасы гражданнары картлыкта, авыргандa, хезмәткә сәләтен тулысынча яки өлешчә югалтканда, бала табып, аны закон билгеләгән яшькә җиткергәндә, туендыручысын югалтканда, шулай ук законда күздә тотылган башка нигезләрдә һәм күләмдә матди тәэмин ителүгә хокуклы.

**47 статья.** Татарстан Республикасы гражданнары торакка хокуклы. Бу хокук дәүләт һәм җәмәгать торак фондын үстерү, кооператив һәм шәхси торак төзелешенә булышу белән тәэмин ителә. Законда билгеләнгән очраклардан тыш, беркем дә торагыннан мәхрүм ителә алмый.

**48 статья.** Татарстан Республикасы гражданнары дәүләт уку йортларында түләүсез гомуми урта һәм махсус урта белем алырга, шулай ук мәктәптә туган телендә укырга хокуклы.
Татарстан Республикасы гражданнары дәүләт уку йортларында конкурс нигезендә түләүсез югары белем алырга хокуклы.

**49 статья.** Татарстан Республикасы гражданнары мәдәният казанышларыннан файдаланырга хокуклы, һәр кешегә фәндә, техникада һәм сәнгатьтә иҗат иреге гарантияләнә.
Автор, уйлап табучы һәм рационализатор хокуклары дәүләт тарафыннан саклана.

**50 статья.** Татарстан Республикасы гражданнары икътисади һәм социаль мәнфәгатьләрен яклау өчен, күмәк хезмәт бәхәсен хәл итүнең соңгы чарасы буларак, законда каралган эш ташлауга хокуклы.
Беркем дә эш ташлауда катнашырга мәҗбүр ителә алмый.
Кешеләрнең гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч тудырырлык эш ташлауга юл куелмый.

**51 статья.** Гражданнарның Конституция игълан иткән хокукларны һәм ирекне файдалануы дәүләт һәм җәмәгать иминлегенә, җәмәгать тәртибенә, халыкның сәламәтлегенә һәм әхлагына, башка кешеләрнең хокукларына һәм ирегенә зыян китермәскә тиеш.

**52 статья.** Татарстан Республикасы гражданнары Татарстан Республикасы Конституциясен һәм законнарын үтәргә бурычлы.

**53 статья.** Татарстан Республикасы гражданнары башка кешеләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен ихтирам итәргә бурычлы.
Башка гражданнарның намусын һәм милли горурлыгын ихтирам итү – Татарстан Республикасының һәр гражданы бурычы.

**54 статья.** Татарстан Республикасы гражданнары, закон тәртибендә салымнар түләп, дәүләт чыгымнарында катнашырга бурычлы.





**55 статья.** Табигатькә сакчыл мөнәсәбәт – Татарстан Республикасының һәр гражданы бурычы.

**56 статья.** Мәдәни хәзинәләрне, тарихи истәлекләрне саклау – Татарстан Республикасы гражданнарының бурычы.
Мәдәни истәлекләрне бозган һәм юкка чыгарган өчен Закон нигезендә җәза бирелә.

**57 статья.** Башка илләрнең халыклары белән дуслык һәм хезмәттәшлекне үстерүгә булышу, гомумтанылган халыкара хокук нормалары нигезендә бөтен дөньяда тынычлыкны саклау һәм ныгыту – Татарстан Республикасы гражданнарының бурычы.

**58 статья.** Татарстан Республикасы гражданнары закон нигезендә хәрби хезмәт үтәргә бурычлы. Хәрби хезмәт Татарстан Республикасы территориясендә яки Татарстан Республикасының килешү йөкләмәләре нигезендә аннан читтә үтелә.
Хәрби хезмәтне альтернатив вазифалар белән алыштыру, шулай ук хәрби хезмәттән азат итү закон белән билгеләнә.

# III. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШЕ

## 5 БҮЛЕК. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ – СУВЕРЕН ДӘҮЛӘТ

**59 статья.** Татарстан Республикасы үзенең дәүләти-хокукый статусын, сәяси, икътисади, социаль-мәдәни төзелеше мәсьәләләрен мөстәкыйль билгели һәм хәл итә. Татарстан Республикасы законнары, әгәр алар Татарстан Республикасының халыкара йөкләмәләренә каршы килмәсә, аның бөтен территориясендә өстенлеккә ия.

**60 статья.** Татарстан Республикасы территориясе кагылгысыз. Татарстан Республикасы белән башка дәүләтләр арасындагы чикләр үзара килешү нигезендә билгеләнә һәм үзгәртелә.

**61 статья.** Татарстан Республикасы – Россия Федерациясе – Россия белән вәкаләтләрен һәм ике якка да караган эшләрне тапшырышу турындагы Килешү нигезендә ассоциацияләшкән суверен дәүләт, халыкара хокук субъекты.

**62 статья.** Татарстан Республикасы башка дәүләтләр белән мөнәсәбәткә керә, халыкара килешүләр төзи, дипломатия, консуллык, сәүдә һәм башка вәкиллекләр алмаша, халыкара хокук принципларына нигезләнеп, халыкара оешмалар эшчәнлегендә катнаша.
Гомумтанылган халыкара хокук принциплары һәм нормалары Татарстан Республикасы законнарыннан өстенрәк санала.

## 6 БҮЛЕК.
## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АДМИНИСТРАТИВ-ТЕРРИТОРИЯ БҮЛЕНЕШЕ

**63 статья.** Татарстан Республикасы территориясе – районнарга һәм республика буйсынуындагы шәһәрләргә, районнар – шәһәрләргә, поселокларга һәм авыл Советларына, зур шәһәрләр районнарга бүленә.

# IV.
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ДӘҮЛӘТ ХАКИМИЯТЕН ОЕШТЫРУ

## 7 БҮЛЕК.
## ХАЛЫК ДЕПУТАТЛАРЫ СОВЕТЛАРЫНЫҢ ОЕШУ ҺӘМ ЭШ НИГЕЗЛӘРЕ

**64 статья.** Татарстан Республикасы Югары Советы, җирле Советлар – шәһәр, район, шәһәрдәге район, поселок һәм авыл Советлары – Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкиллекле органнарының бердәм системасын тәшкил итә.
Халык депутатлары Советлары үз вәкаләтендәге барлык мәсьәләләрне мөстәкыйль хәл итә.
Поселокларда, авыл Советларында, шул Советның карары яки җирле референдум нигезендә, Совет сайланмаска яисә бетерелергә мөмкин. Мондый очракта поселок, авыл Советының вәкаләтләрен җирле үзидарәнең башка органнары гамәлгә ашыра.

**65 статья.** Республика һәм аның аерым урыннары өчен әһәмиятле төп мәсьәләләр Татарстан Республикасы Югары Советы һәм халык депутатлары җирле Советлары сессияләрендә хәл ителә. Алар шулай ук республика күләмендәге һәм җирле референдумга куелырга мөмкин.

**66 статья.** Татарстан Республикасы Югары Советы, халык депутатларының район, шәһәр, шәһәрдәге район Советлары – Совет президиумын һәм рәисен, ә район буйсынуындагы шәһәр, поселок һәм авыл Советлары Совет рәисен сайлыйлар.
Халык депутатлары Советы комитетлар, даими һәм вакытлы комиссияләр, аңа буйсынган башка органнар оештыра, шулай ук аларның җитәкчеләрен сайлый яки раслый.
Халык депутатлары Советларының даими комиссияләре шул Совет депутатларыннан оештырыла. Дәүләт һәм җәмәгать органнары, оешмалар һәм урындагы кешеләр комиссия таләп иткән материалларны бирергә бурычлы. Комиссия тәкъдимнәре дәүләт һәм җәмәгать органнары, учреждение һәм оешмалар мәҗбүри тикшерергә тиеш. Тикшерү нәтиҗәләре һәм күрелгән чаралар турында комиссиягә ул билгеләгән вакытка хәбәр ителергә тиеш.
Район, шәһәр һәм башка административ-территория берәмлекләрендә башкару-боеру бурычларын шул берәмлекнең администрациясе үти.
Эшен канәгатьләнерлек башкармаган очракта теләсә кайсы урындагы кешене вазифасыннан вакытыннан элек азат итәргә мөмкин.
Халык депутатлары Советы сайлаган яисә билгеләгән урындагы кешеләр, судьялардан





тыш, бу урында рәттән ике сроктан да күбрәк эшли алмый. Алар өчен башка чикләүләр закон белән билгеләнә.

**67 статья.** Халык депутатлары Советының эшчәнлеге мәсьәләләрне күмәк, ирекле, эшлекле тикшерү һәм хәл итү нигезендә, хәбәрдарлык, җирле администрациянең һәм Совет оештырган органнарның аның каршында һәм халык алдында даими хисап тотуы, алар эшенә гражданнарны җәлеп итү нигезендә оештырыла.
Халык депутатлары Советлары, җирле администрация һәм аларның органнары эшне татар һәм рус телләрендә, ә кирәк очракта шушы территориядә яшәүче халыкның күпчелеге кулланган телдә алып баралар һәм кабул иткән актларны шул телләрдә бастырып чыгаралар.

## 8 БҮЛЕК.
## САЙЛАУ СИСТЕМАСЫ

**68 статья.** Халык депутатлары Советларының вәкаләт чоры – биш ел.
Татарстан Республикасы Югары Советына һәм халык депутатларының җирле Советларына сайлаулар дәүләт хакимиятенең шул органнарының вәкаләт чоры тәмамланырга дүрт айдан да соңламыйча билгеләнә. Халык депутатларын сайлау тәртибе Татарстан Республикасы законнарында күрсәтелә.

**69 статья.** Халык депутатларын сайлау гомуми, тигез һәм турыдан-туры сайлау хокукы нигезендә яшерен тавыш биреп, сайлау округлары буенча үткәрелә.

**70 статья.** Халык депутатларын сайлау округларыннан сайлау гомуми: Татарстан Республикасының 18 яше тулган гражданнары сайларга (актив сайлау хокукы) һәм сайланырга (пассив сайлау хокукы) хаклы.
Суд юридик хокуксыз дип тапкан, суд карары белән иректән мәхрүм итү урынында тотылган кешеләр, шулай ук психиатрия хастаханәсендә ятып дәваланучы психик авыру гражданнар сайлана алмый һәм сайлауда катнашмый.

**71 статья.** Татарстан Республикасы гражданы дәүләт хакимиятенең вәкиллекле органнарының икесеннән күбрәгендә бер үк вакытта депутат була алмый.
Татарстан Республикасы халык депутаты бүтән Советның депутаты була алмый.

**72 статья.** Татарстан Республикасы министрлары, дәүләт комитеты рәисләре һәм Министрлар Кабинетының Премьер-министрдан кала башка әгъзалары, шулай ук судьялар депутат була алмый.
Җирле администрация башлыгы урынбасарлары һәм администрациянең структура бүлекләре җитәкчеләре шушы җирле Советның депутаты була алмый.

**73 статья.** Халык депутатларын сайлау тигез: һәр сайлаучы бер тавышка ия. Сайлау округлары һәм вәкиллек нормалары депутатларны һәр Советка якынча бер үк сандагы сайлаучылар сайларлык итеп билгеләнә.

**74 статья.** Халык депутатларын сайлау турыдан-туры: дәүләт хакимиятенең вәкиллекле

барлык органнарына депутатларны гражданнар турыдан-туры сайлый.

**75 статья.** Сайлауда тавыш бирү яшерен: тавыш бирүченең ихтыяр белдерүен тикшерүгә юл куелмый.

**76 статья.** Халык депутатына кандидатлар күрсәтү хокукына сайлаучыларның эш (уку, хезмәт итү) һәм яшәү урыннарындагы җыелышлар, шулай ук закон тәртибендә теркәлгән партияләр, профессиональ союзлар һәм башка җәмәгать берләшмәләре ия.

**77 статья.** Сайлау бюллетененә теләсә ничә кандидат кертелергә мөмкин.

**78 статья.** Сайлауны оештыру һәм аңа йомгак ясауны сайлау комиссияләре башкара. Аларның бөтен эше ачык һәм хәбәрдар үткәрелә. Үзәк сайлау комиссиясен – Югары Совет, ә округ, территория, участок комиссияләрен халык депутатларының шул Советы оештыра.

**79 статья.** Татарстан Республикасы гражданнарына, сайлаучылар җыелышларына, партияләргә, башка җәмәгать берләшмәләренә халык депутатына кандидатларның сәяси, эш һәм шәхси сыйфатларын төрле яклап, ирекле тикшерү мөмкинлеге, шулай ук җыелышларда һәм массакүләм информация чараларында кандидатны яклап яки аңа каршы агитацияләү хокукы гарантияләнә.

**80 статья.** Татарстан Республикасы гражданнарына сайлау хокукларыннан файдаланырга комачаулык иткән, сайлау йомгакларын бозып күрсәткән һәм сайлау турында законнарны башкача бозган өчен юридик җаваплылык карала.

**81 статья.** Кандидатларны теркәүгә, сайлауны үткәрү һәм йомгак ясауга кагылган бәхәсләрне тиешле дәрәҗәдәге судлар закон билгеләгән срокта карый.
Татарстан Республикасы халык депутаты сайлануының законлылыгы турында бәхәс чыккан очракта, эш Татарстан Республикасы Югары суды каравына тапшырыла.
Судларның карары катгый.

## 9 БҮЛЕК.
## ХАЛЫК ДЕПУТАТЫ

**82 статья.** Депутатның вәкаләтләре халык депутатлары Советына сайланган көннән – Үзәк сайлау комиссиясе һәм тиешле территория сайлау комиссиясенең сайланган депутатларны теркәү турында беркетмәсе тарафыннан расланган көннән башлана.

**83 статья.** Депутат – халык депутатлары Советында халыкның тулы хокуклы вәкиле. Депутат республиканың, үзен сайлаган территория берәмлегенең мәнфәгатьләренә нигезләнеп эш итә.

**84 статья.** Халык депутаты үз вәкаләтләрен, кагыйдә буларак, эштән яки хезмәт вазифасыннан аерылмыйча башкара. Депутат Советның сессиясе чорына, шулай ук депутат вазифаларының законда каралган башка төрләрен үтәү өчен эштән яки хезмәт вазифасыннан азат ителә. Аның депутат эшчәнлеге белән бәйле чыгымнар шул бюджетта каралган акчадан түләнә.

**85 статья.** Совет эшендә катнашып, депутатлар дәүләт, хуҗалык, социаль-мәдәни төзелеш мәсьәләләрен хәл итәләр, дәүләт органнары, предприятие, учреждение һәм оешмалар эшенә контрольне гамәлгә ашыралар.
Депутат тиешле дәүләт органнарына һәм урындагы кешеләргә таләп (запрос) куярга хокуклы, алары исә Югары Совет утырышында, халык депутатларының җирле Советы сессиясендә таләпкә җавап бирергә бурычлы.
Депутатның Татарстан Республикасы территориясендә барлык дәүләт һәм җәмәгать органнарына, предприятие, учреждение, оешмаларга депутат эше мәсьәләләре белән мөрәҗәгать итәргә һәм куелган мәсьәләләрне тикшерүдә катнашырга хакы бар. Шул дәүләт һәм җәмәгать органнары, предприятие, учреждение һәм оешмалар җитәкчеләре депутатны кичектергесез кабул итәргә һәм тәкъдимнәрен билгеләнгән вакытка карарга бурычлы.

**86 статья.** Депутатка хокук һәм бурычларын каршылыксыз һәм нәтиҗәле гамәлгә ашыру өчен шартлар тудырыла.
Депутатның кагылгысызлыгы, депутат эшчәнлегенә гарантияләр шушы Конституция белән, Татарстан Республикасының халык депутатлары статусы турындагы законнары һәм башка закон актлары белән билгеләнә.

**87 статья.** Дәүләт хакимиятенең коллегиаль вәкиллекле органы әгъзасы буларак, депутатның Совет һәм аның органнары эшендә катнашырга тулы хакы бар, ул Совет алдындагы бурычларын үти.
Совет йөкләгән эшләрне, аның алдындагы бурычларын үтәмәгән, аның эш тәртибен, депутат әдәбе таләпләрен бозган өчен депутат Совет алдында җаваплылыкка ия була.

**88 статья.** Депутат сайлаучылары алдында җаваплы һәм алар алдында хисап тота.
Сайлаучылар ышанычын акламаган депутат законда каралган тәртиптә алар тарафыннан теләсә кайсы вакытта чакыртып алынырга мөмкин.

## 10 БҮЛЕК.
## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ СОВЕТЫ

**89 статья.** Татарстан Республикасы Югары Советы – Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең закон чыгару һәм контрольлек итүче даими эшли торган иң югары органы.
Татарстан Республикасы Югары Советы каравына түбәндәгеләр керә:
1) Татарстан Республикасы Конституциясен кабул итү һәм аңа үзгәрешләр кертү;
2) Татарстан Республикасы законнарын кабул итү һәм аларга үзгәрешләр кертү;
3) Татарстан Республикасының эчке һәм тышкы сәясәтен билгеләү;
4) милек мөнәсәбәтләрен, халык хуҗалыгын һәм социаль-мәдәни төзелешне идарә итүне, бюджет-финанс системасын, административ-сәяси эшчәнлекне, хезмәткә түләү һәм бәя билгеләүне, салым салуны, мохитне саклау һәм табигый байлыкларны файдалануны оештыру, шулай ук Татарстан Республикасы законнары белән җайга салынырга тиешле башка мөнәсәбәтләрне закон белән көйләү;
5) дәүләт хакимияте һәм идарәсенең республика һәм җирле органнарын оештыру һәм аларның эш тәртибен, җирле үзидарә нигезләрен билгеләү, дәүләт органнары һәм җәмәгать берләшмәләренең үзара мөнәсәбәтләре нигезләрен билгеләү;
6) Татарстан Республикасының административ-территория төзелеше мәсьәләләрен хәл

итү тәртибен ачыклау; яңа районнар һәм шәһәрләр оештыру, аларга исем бирү һәм исемнәрен үзгәртү;

7) Татарстан Республикасы чикләрен үзгәртүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итү;
8) Татарстан Республикасының икътисади һәм социаль үсешенең республика күләмендәге иң әһәмиятле программаларын раслау; Татарстан Республикасының дәүләт бюджетын һәм валюта фондларын раслау; программаларны һәм бюджетны үтәүнең барышына контрольлек итү; аларның үтәлеше турындагы хисапларны раслау;
9) Татарстан Республикасы банкларын оештыру, үзгәртү һәм ябу;
10) Татарстан Республикасының дәүләт бюджетын тәшкил иткән салымнарны һәм башка керемнәрне билгеләү;
11) Татарстан Республикасы халык депутатлары арасыннан:
Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисен, Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисе урынбасарларын һәм Секретарен сайлау;
12) Татарстан Республикасы Югары Советының Закон чыгару җыенын оештыру;
13) Татарстан Республикасы халык депутатларыннан Югары Советның даими комиссияләрен һәм Парламент контроле комитетын оештыру һәм сайлау;
14) Татарстан Республикасы Президенты тәкъдиме белән Премьер-министр кандидатурасын раслау; Президентның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты составы турындагы тәкъдимнәрен килештерү; Татарстан Республикасы министрлыкларын һәм дәүләт комитетларын оештыру һәм бетерү; Татарстан Республикасы Президенты тәкъдиме белән, шулай ук үз инициативасы белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына һәм аның әгъзаларына ышаныч мәсьәләсен хәл итү;
15) Милли банк рәисен раслау;
16) Татарстан Республикасы Конституция судын сайлау;
17) Татарстан Республикасы Югары судын, район (шәһәр) судлары судьяларын сайлау;
18) Татарстан Республикасының Югары арбитраж судын сайлау;
19) Татарстан Республикасы прокурорын, Татарстан Республикасы Тикшерү комитеты рәисен билгеләү;
20) Татарстан Республикасының гомуми вәкаләтле судлары хөкем иткән кешеләргә амнистия турында карар кабул итү;
21) халык депутатларының җирле Советлары эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итү;
22) республикакүләм халык тавыш бирүен (референдум) үткәрү турында карар кабул итү, Татарстан Республикасы Үзәк референдум комиссиясе составын раслау;
23) Татарстан Республикасы халык депутатларын һәм халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларын, Татарстан Республикасы Президентын сайлауны билгеләү;
24) Татарстан Республикасы халык депутатларын һәм Татарстан Республикасы Президентын сайлау буенча Үзәк сайлау комиссияләре составларын раслау;
25) Татарстан Республикасы гражданнарының Конституция хокукларын һәм иреген, Татарстан Республикасы территориясендә барлык милләт гражданнарының тигез хокукын тәэмин итүгә бәйле мәсьәләләрне карау, милли мәдәниятне, телне үстерү һәм тарихи истәлекләрне саклау мәсьәләләрен хәл итү;
26) Татарстан Республикасы законнарына аңлатма бирү;
27) Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләрен, Татарстан Республикасының мактаулы исемнәрен булдыру;
28) гадәттән тыш хәл кертүне раслау;





29) Татарстан Республикасының халыкара килешүләрен раслау һәм гамәлдән чыгару.
Татарстан Республикасы Югары Советы түбәндәгеләргә хокуклы:

Югары Советның Закон чыгару җыены актларын, Татарстан Республикасы Югары Советы Президиумы карарларын, Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисе боерыкларын гамәлдән чыгарырга;

Татарстан Республикасы Конституциясе һәм Татарстан Республикасы законнары йөкләгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашырырга, шулай ук гомумреспублика әһәмиятендәге башка мәсьәләләрне хәл итәргә.

Татарстан Республикасы Югары Советы үзе оештырган яки сайлаган органнарның, шулай ук үзе сайлаган яки билгеләгән урындагы кешеләрнең хисабын даими тыңлый.

**90 статья.** Татарстан Республикасы Югары Советы Татарстан Республикасы законнарын һәм карарлар кабул итә.

**91 статья.** Татарстан Республикасы Югары Советы сайлаучылар саны нигездә тигез булган сайлау округларында сайланган 250 халык депутатыннан тора.

Татарстан Республикасы Югары Советы 125 Татарстан Республикасы халык депутатыннан торган Татарстан Республикасы Югары Советының даими эшләүче закон чыгару һәм контроль органын – Закон чыгару җыенын оештыра.

Татарстан Республикасы Югары Советы Закон чыгару җыенының вәкаләте, аның оешу һәм эшчәнлек тәртибе Татарстан Республикасы Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Югары Советының Закон чыгару җыены турындагы законы белән билгеләнә.

**92 статья.** Татарстан Республикасы Югары Советы беренче утырышка Югары Советның билгеләнгән санлы составының кимендә өчтән ике өлеше сайланганнан соң ике айдан да соңга калмыйча чакырыла.

Татарстан Республикасы Югары Советының сайлаудан соң беренче утырышын Татарстан Республикасы халык депутатларын сайлау буенча Үзәк сайлау комиссиясе рәисе ача һәм алып бара, ә Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисе сайлангач, утырышны Рәис алып бара.

**93 статья.** Татарстан Республикасы Югары Советының эш тәртибе шушы Конституция һәм Югары Совет регламенты белән билгеләнә.

Татарстан Республикасы Югары Советының вәкаләтләр чоры гадәттән тыш хәл вакытында бетсә, Татарстан Республикасы Югары Советы, гадәттән тыш хәл кертелү турындагы мәсьәләне хәл итү белән бергә, үз вәкаләтләре чорын озайту турында да карар кабул итә.

**94 статья.** Татарстан Республикасы Югары Советында закон чыгару инициативасы хокукына Татарстан Республикасы халык депутатлары, Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Югары Советы Президиумы, даими комиссияләре һәм Парламент контроле комитеты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы Конституция суды, Югары суды һәм Югары арбитраж суды, Татарстан Республикасы прокуроры, шулай ук хезмәт мөнәсәбәтләре һәм хезмәт ияләрен социаль яклау мәсьәләләре буенча профессиональ союзларның республика советы ия.

**95 статья.** Татарстан Республикасы Югары Советы каравына кертелгән закон проектлары аның утырышларында тикшерелә.

Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Югары Советының билгеләнгән

санлы составының яртысыннан күбрәге яклап тавыш биргәндә, кабул ителгән дип санала.
Закон проектлары һәм дәүләт тормышының башка аеруча мөһим мәсьәләләре Татарстан Республикасы Югары Советының яки аның Президиумының карары белән халык тикшерүенә чыгарылырга мөмкин.

**96 статья.** Татарстан Республикасы законнары татар һәм рус телләрендә кабул ителә һәм бастырып чыгарыла.

**97 статья.** Татарстан Республикасы Югары Советы Президиумы Татарстан Конституциясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә үз каравына тапшырылган мәсьәләләрне мөстәкыйль хәл итә һәм Татарстан Республикасы Югары Советы эшен оештыруны тәэмин итә; Президиум Югары Советка хисап бирә.
Татарстан Республикасы Югары Советы Президиумына Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисе, Рәиснең урынбасарлары һәм Секретаре, Татарстан Республикасы Югары Советының даими комиссияләре, Парламент контроле комитеты рәисләре һәм Татарстан Республикасы Югары Советы сайлаган башка депутатлар керә.
Татарстан Республикасы Югары Советы Президиумын Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисе җитәкли.

**98 статья.** Татарстан Республикасы Югары Советы Президиумы:
1) Татарстан Республикасы Югары Советы сессияләрен чакыра һәм аның утырышларын әзерләүне оештыра;
2) Татарстан Республикасы Югары Советының даими һәм башка комиссияләре, Парламент контроле комитеты эшчәнлеген яраштыра;
3) Татарстан Республикасы халык депутатларына үз вәкаләтләрен үтәргә булыша һәм аларны кирәкле мәгълүмат белән тәэмин итә;
4) халыкның тавыш бирүен (референдумнарны), шулай ук Татарстан Республикасы закон проектларын һәм дәүләт тормышының аеруча мөһим башка мәсьәләләрен халык тикшерүенә әзерләүне һәм аны үткәрүне оештыра;
5) Татарстан Республикасы Югары Советы, Татарстан Республикасы Югары Советы Президиумы кабул иткән Татарстан Республикасы законнарын һәм башка актларны бастырып чыгара;
6) халык депутатларының җирле Советлары эшчәнлегенә юнәлеш бирә;
7) халык депутатларының район һәм шәһәр (республика буйсынуындагы шәһәр) Советларының законга туры килмәгән карарларын гамәлдән чыгара;
8) Татарстан Республикасының административ-территория төзелеше мәсьәләләре буенча карарлар кабул итә;
9) Татарстан Республикасы законнарында каралган башка мәсьәләләрне хәл итә.

**99 статья.** Татарстан Республикасы Югары Советы Президиумы карарлар кабул итә.

**100 статья.** Татарстан Республикасы Югары Советының вәкаләт срогы беткәннән соң, Татарстан Республикасы Югары Советы Югары Советның яңа Президиумын оештырганчы, Татарстан Республикасы Югары Советы Президиумы үз вәкаләтләрен саклый.

**101 статья.** Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисе – Татарстан Республикасы Югары Советының иң югары урындагы кешесе, республиканың башка органнары, шулай ук





башка дәүләтләр парламентлары белән мөнәсәбәтләрдә Югары Совет исеменнән эш итә һәм Югары Советның, аның Президиумының эшен оештыра:
1) Татарстан Республикасы Югары Советы карарга тиешле мәсьәләләрне әзерләүгә гомуми җитәкчелек итә, Татарстан Республикасы Югары Советы һәм Татарстан Республикасы Югары Советы Президиумы кабул иткән карарларга кул куя;
2) Татарстан Республикасы Югары Советына Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисе урынбасарлары һәм Секретаре вазифаларына сайлау өчен кандидатлар, Татарстан Республикасы Югары судының һәм Югары арбитраж судының шәхси составын, Конституция суды шәхси составының яртысын тәкъдим итә.

Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисе урынбасарлары, Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисе кушуы буенча, аның аерым вазифаларын үтиләр һәм, Рәис булмаган яки ул үз вазифасын үти алмаган очракта, аны алыштыралар.
Татарстан Республикасы Югары Советы Секретаре Югары Совет секретариаты аппараты белән җитәкчелек итә.

**102 статья.** Татарстан Республикасы Югары Советы закон проектларын эшләү, Татарстан Республикасы Югары Советы тикшерәчәк мәсьәләләрне алдан карау һәм әзерләү өчен, шулай ук Татарстан Республикасы законнарын һәм Татарстан Республикасы Югары Советы кабул иткән башка карарларны гамәлгә ашырырга булышлык итү, дәүләт органнары һәм оешмалары эшчәнлегенә контрольлек итү өчен халык депутатларыннан даими комиссияләр төзи.
Комиссияләрнең закон бозуларны бетерүгә юнәлтелгән карарларын үтәү мәҗбүри.
Татарстан Республикасы Югары Советы даими комиссияләренең вәкаләте, оешу һәм эш тәртибе закон белән билгеләнә.
Татарстан Республикасы Югары Советы, кирәк тапса, теләсә нинди мәсьәлә буенча тикшерү, ревизия комиссияләре һәм башка комиссияләр төзи.

**103 статья.** Татарстан Республикасы законнары, кагыйдә буларак, аларның проектлары Татарстан Республикасы Югары Советының тиешле даими комиссияләрендә алдан тикшерелгәннән соң кабул ителә.
Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы Конституция суды, Югары суды һәм Югары арбитраж суды составларына урындагы кешеләр, шулай ук Татарстан Республикасы прокуроры һәм Тикшерү комитеты рәисе кандидатлары Татарстан Республикасы Югары Советының тиешле даими комиссияләрендә алдан караганнан соң билгеләнә һәм сайлана.

**104 статья.** Татарстан Республикасы халык депутаты Татарстан Республикасы Югары Советы утырышларында Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисенә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Премьер-министрына, министрларына, Татарстан Республикасы Югары Советы төзегән яки сайлаган башка органнарның (судлардан кала) җитәкчеләренә таләп белән мөрәҗәгать итәргә хаклы. Таләп бирелгән орган яки урындагы кеше өч көннән дә соңга калмыйча җавап бирергә тиеш.
Татарстан Республикасы халык депутаты Татарстан Республикасы Югары Советы ризалыгыннан башка җинаять җаваплылыгына тартыла алмый, кулга алына алмый яки суд билгеләгән административ җәзага тартыла алмый.

**105 статья.** Татарстан Республикасы Югары Советы үзенә буйсынган барлык дәүләт органнарының эшен контрольдә тота.

# 11 БҮЛЕК.
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ

**106 статья.** Татарстан Республикасында дәүләт башлыгы – Президент.

**107 статья.** Татарстан Республикасы Президенты – Татарстан Республикасында шәхес хокуклары һәм ирегенең, республика суверенитетының, Татарстан Республикасы Конституциясен һәм законнарын, шулай ук Татарстан Республикасының халыкара килешүләрен үтәүнең гаранты.

**108 статья.** Татарстан Республикасы Президенты итеп республиканың утыз биштән яшьрәк, алтмыш биш яшьтән өлкәнрәк булмаган, сайлау хокукына ия булган, Татарстан Республикасы территориясендә ким дигәндә ун ел даими яшәүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт телләрен белүче гражданы сайлана ала. Бер үк кеше рәттән ике сроктан да артык Татарстан Республикасы Президенты була алмый.
Татарстан Республикасы Президенты Татарстан Республикасы гражданнары тарафыннан гомуми, тигез һәм турыдан-туры сайлау хокукы нигезендә яшерен тавыш бирү юлы белән биш елга сайлана. Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидатлар саны чикләнми. Сайлаучыларның яртысыннан күбрәге сайлауда катнашса, Татарстан Республикасы Президентын сайлау үткәрелгән дип санала. Тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның яртысыннан күбрәгенең тавышын алган кандидат сайланган дип исәпләнә.
Президент белән бер үк вакытта Татарстан Республикасы вице-президенты да сайлана.
Татарстан Республикасы Президентын һәм вице-президентын сайлау тәртибе Татарстан Республикасы Президентын сайлау турында Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнә.

**109 статья.** Татарстан Республикасы Президенты һәм вице-президенты башка урында эшли алмый, шулай ук Татарстан Республикасы һәм халык депутатлары җирле Советларының халык депутаты була алмый.

**110 статья.** Татарстан Республикасы Президенты үз вазифасын үтәүгә керешкәндә сайлау йомгаклары игълан ителгәннән соң бер ай эчендә Татарстан Республикасы халкына һәм Конституциясенә тугрылыгын белдереп ант итә. Антның текстын һәм аны кабул итү тәртибен Татарстан Республикасы Югары Советы раслый.

**111 статья.** Татарстан Республикасы Президенты:
1) Татарстан Республикасы гражданнарының хокукларын һәм иреген, Татарстан Республикасының дәүләт суверенитетын, республиканың иминлеген һәм территория бөтенлеген, аның территориясендә законлылыкны һәм хокук тәртибен тәэмин итә;
2) Татарстан Республикасының дәүләт идарәсе органнары системасына җитәкчелек итә һәм аларның Татарстан Республикасы Югары Советы белән бергәләшеп эшләвен тәэмин итә;
3) җирле администрацияләр эшчәнлегенә юнәлеш бирә, халык депутатларының тиешле Советлары ризалыгы белән район һәм республика буйсынуындагы шәһәр администрациясе башлыкларын билгели һәм эштән азат итә;
4) Татарстан Республикасы Югары Советына ел саен Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты проектын, республиканың эчке һәм тышкы хәле турында докладлар тәкъдим итә, Югары Советка республика тормышының мөһим мәсьәләләре турында мәгълүмат бирә, Татарстан Республикасы Югары Советы һәм аның Президиумы эшендә катнашырга хаклы;
5) Татарстан Республикасы Югары Советы раславына Татарстан Республикасы Премьер- министры урынына кандидат тәкъдим итә. Татарстан Республикасы Югары Советы белән килешеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетын оештыра, аның составына үзгәрешләр кертә, Татарстан Республикасы Премьер-министрын һәм Министрлар Кабинеты әгъзаларын эштән азат итә. Татарстан Республикасы Югары Советына Татарстан Республикасы министрлыкларын һәм дәүләт комитетларын оештыру һәм бетерү турында тәкъдим кертә;
6) Татарстан Республикасы Югары Советы раславына Татарстан Республикасы Милли банкы рәисе урынына кандидат тәкъдим итә;
7) Татарстан Республикасы Югары Советына Татарстан Республикасы Конституция судының шәхси составының яртысын тәкъдим итә;
8) Татарстан Республикасы Югары Советына Татарстан Республикасы прокуроры, Татарстан Республикасы Тикшерү комитеты рәисе урыннарына кандидатлар тәкъдим итә, шулай ук Татарстан Республикасы Югары Советына аларны эштән азат итү турында тәкъдим кертә;
9) халыкара мөнәсәбәтләрдә Татарстан Республикасы исеменнән эш итә. Татарстан Республикасының чит дәүләтләр һәм халыкара оешмалардагы вәкилләрен билгели һәм чакыртып кайтара; чит дәүләтләр белән килешүләр төзи; чит дәүләт вәкилләреннән ышаныч белдерү һәм чакыртып алдыру грамоталарын кабул итә;
10) закон нигезендә Татарстан Республикасы гражданлыгы һәм сәяси сыену урыны бирү мәсьәләләрен хәл итә;
11) Татарстан Республикасы законнарына кул куя; кабул ителеп, Президентка кул куярга кертелгән законны кабат тикшерү һәм тавышка кую өчен ике атнадан да соңламыйча, үзенең каршы фикерләре белән Татарстан Республикасы Югары Советына кайтарырга хокуклы. Әгәр Президент законны билгеләнгән вакытка кабат карау өчен кайтармаса яки Югары Совет үзенең билгеләнгән санлы составының кимендә өчтән икесенең тавышы белән элек кабул ителгән карарны расласа, Президент законга кул куярга тиеш;
12) Татарстан Республикасы Конституциясенә һәм Татарстан Республикасы Президенты Указларына каршы килгән очракта, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын һәм боерыкларын, районнар һәм республика буйсынуындагы шәһәрләр администрациясе башлыкларының актларын гамәлдән чыгарырга хокуклы;
13) Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләре белән бүләкли;
14) Татарстан Республикасының халыкара премияләрен булдыра һәм тапшыра;
15) Татарстан Республикасы судлары хөкем иткән кешеләрне ярлыкый;
16) гражданнарның иминлеген тәэмин итү мәнфәгатендә, Татарстан Республикасында яки аның аерым төбәкләрендә закон нигезендә гадәттән тыш хәл кертә, бер үк вакытта бу карарны Татарстан Республикасы Югары Советы раславына куя;
17) Татарстан Республикасы Конституциясе һәм законнары белән аңа йөкләнгән, шулай ук Татарстан Республикасының халыкара йөкләмәләрендә каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

**112 статья.** Татарстан Республикасы Президенты, үз вәкаләтләре чикләрендә, Конституциягә һәм законнарга нигезләнеп һәм аларны үтәү максатында, Татарстан Республикасының бөтен территориясендә үтәлүе мәҗбүри булган указлар һәм боерыклар чыгара.


Татарстан Республикасы
КОНСТИТУЦИЯСЕ (1992 ел)

Татарстан Республикасы Президенты үз бурычларын башкару өчен Президент аппараты оештыра.

**113 статья.** Татарстан Республикасы Президенты шәхесе кагылгысыз. Президентның намусы һәм абруе закон белән саклана.

**114 статья.** Татарстан Республикасы Президенты теләсә кайсы вакытта отставка сорый ала. Президентның отставкасын кабул итү мәсьәләсен Татарстан Республикасы Югары Советы хәл итә.

**115 статья.** Вакытлыча хезмәт вазифаларын башкармый торган очракта, Татарстан Республикасы Президенты үз бурычларын үтәүне Татарстан Республикасы вице-президентына тапшыра ала.
Татарстан Республикасы Президенты теге яки бу сәбәп белән үз вазифасын үти алмый башласа, яңа Президент сайланганчы аның вазифасын үтәү Татарстан Республикасы вице-президентына, ә бу мөмкин булмаса, Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисенә күчә.
Татарстан Республикасы Президенты, вәкаләт срогы чыккач, яңа сайланган Татарстан Республикасы Президенты ант иткәнче, үз бурычларын үтәүне дәвам иттерә. Татарстан Республикасының яңа Президентын сайлау закон нигезендә үткәрелә.
Конституцияне бозган өчен Президент Татарстан Республикасы Югары Советының Татарстан Республикасы Конституция суды бәяләмәсен исәпкә алып кабул иткән карары белән эшеннән азат ителә ала. Президентка каршы гаепләү эшен кузгату турындагы тәкъдим ачык тавыш бирү юлы белән Югары Советның билгеләнгән санлы составының кимендә өчтән бере тарафыннан кертелә, ә аны эшеннән азат итү турындагы карар кимендә өчтән икесенең тавышы белән кабул ителә.

## 12 БҮЛЕК.
## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**116 статья.** Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте – Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкару һәм боеру органы. Ул Татарстан Республикасы Президентына буйсына.

**117 статья.** Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Премьер-министрдан, аның беренче урынбасарларыннан, урынбасарларыннан, министрлардан, дәүләт комитетлары рәисләреннән һәм Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең башка органнары җитәкчеләреннән тора.

**118 статья.** Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Югары Советы алдында җаваплы.
Татарстан Республикасының яңа оештырылган Министрлар Кабинеты үз вәкаләтләре срогында башкарасы эшләренең программасын Татарстан Республикасы Югары Советы каравына кертә.
Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үз эше турында Татарстан Республикасы Югары Советы алдында кимендә елга бер тапкыр хисап тота.
Татарстан Республикасы Югары Советы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына ышанмау белдерә ала, бу исә аның отставкасына китерә. Бу мәсьәлә буенча карар Татарстан Республикасы Югары Советының билгеләнгән санлы составының кимендә өчтән икесе тавышы белән кабул ителә.





**119 статья.** Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты дәүләт идарәсенең барлык мәсьәләләрен хәл итәргә хокуклы, чөнки Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә алар Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтенә керми.
Үз вәкаләтләре чикләрендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты:

1) Татарстан Республикасының агымдагы һәм киләчәктәге икътисади һәм социаль үсешенең дәүләт программаларын, Татарстан Республикасының берләштерелгән дәүләт бюджеты проектын, республиканың керем чыганакларын һәм валюта фондлары чыгымнарының юнәлешен эшли; дәүләт программаларын һәм бюджетын гамәлгә ашыру чараларын күрә; программаларның башкарылышы һәм бюджетның үтәлеше турында Татарстан Республикасы Югары Советына хисап бирә;
2) халыкның тормыш дәрәҗәсен һәм мәдәниятен күтәрүне, хезмәтне һәм халык сәламәтлеген саклауны, фән һәм техниканы үстерүне, табигатьне саклау һәм табигый байлыклардан дөрес файдалануны тәэмин итү чараларын билгели һәм гамәлгә ашыра; банк, акча һәм кредит системаларын ныгыту, дәүләт страхованиесен, хисап һәм статистиканың бердәм системасын оештыру чараларын тормышка ашыруга ярдәм итә; бәяләр билгеләүнең, хезмәткә түләүнең, социаль тәэминатның гомумдәүләт сәясәтен тормышка ашыра; промышленность, төзелеш, авыл хуҗалыгы предприятиеләре һәм берләшмәләрен, транспорт һәм элемтә предприятиеләрен, шулай ук Татарстан Республикасының дәүләт милкендәге башка объектларын идарә итүне оештыра;
3) республиканың, район һәм шәһәрләрнең бөтенлекле икътисади һәм социаль үсешен тәэмин итә;
4) тышкы икътисади эшчәнлекне гамәлгә ашыра;
5) дәүләт мәнфәгатьләрен яклау, милекнең барлык төрләрен һәм җәмәгать тәртибен саклау, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын гамәлгә ашыра;
6) дәүләт иминлеген тәэмин итү чараларын күрә;
7) министрлыклар, дәүләт комитетлары һәм ведомстволар турындагы кагыйдәләрне раслый;
8) кирәк очракта Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршында хуҗалык һәм социаль-мәдәни төзелеш эшләре буенча комитетлар, идарә һәм башка ведомстволар оештыра;
9) җирле администрация эшчәнлегенә юнәлеш бирә.

**120 статья.** Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Югары Советы карарлары һәм Татарстан Республикасы Президенты указлары нигезендә һәм аларны үтәү максатында карарлар һәм боерыклар чыгара, аларның үтәлешен тикшерә. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын һәм боерыкларын Татарстан Республикасының бөтен территориясендә үтәү мәҗбүри.

**121 статья.** Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты районнар һәм республика буйсынуындагы шәһәрләр администрациясе башлыклары карарларын һәм боерыкларын туктатып торырга хокуклы.
Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы министрлыкларының, дәүләт комитетларының, үз буйсынуындагы башка органнарның актларын гамәлдән чыгарырга хокуклы.

**122 статья.** Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы министрлыкларының, дәүләт комитетлары һәм үз буйсынуындагы башка органнарның эшен берләштерә һәм аларның эшенә юнәлеш бирә.
Татарстан Республикасы министрлыклары, дәүләт комитетлары һәм дәүләт идарәсенең башка органнары идарә итүнең тиешле тармаклары белән җитәкчелек итә яки, Татарстан Республикасы Президентына һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына буйсынып, тармакара идарәне гамәлгә ашыра.

**123 статья.** Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының вәкаләте, эш тәртибе, Татарстан Республикасы дәүләт органнары белән мөнәсәбәте Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты турында закон белән билгеләнә.

## 13 БҮЛЕК.
## ДӘҮЛӘТ ХАКИМИЯТЕ ҺӘМ ИДАРӘСЕНЕҢ ҖИРЛЕ ОРГАННАРЫ. ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ

**124 статья.** Җирле үзидарә, халык мәнфәгатьләрен һәм территория үзенчәлекләрен истә тотып, Татарстан Республикасы Конституциясе һәм законнары нигезендә район, шәһәр һәм башка административ-территория берәмлекләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.
Гражданнарның үзидарәгә үзоешу максаты – территорияне икътисади һәм социаль үстерү, гражданнарның хокукларын, иреген, законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү.

**125 статья.** Җирле үзидарәнең төп буыннары – халык депутатларының җирле Советлары. Җирле үзидарәгә шулай ук җирле администрация, территориянең үзидарә органнары, җирле референдумнар, гражданнар җыеннары, турыдан-туры демократиянең башка төрләре керә.

**126 статья.** Халык депутатларының җирле Советлары һәм җирле үзидарәнең башка органнары җирле әһәмияткә ия булган барлык мәсьәләләрне хәл иткәндә, гражданнарның, үз карамакларындагы территориянең социаль һәм икътисади үсеше мәнфәгатьләрен истә тотып, гомумдәүләт мәнфәгатьләрен исәпкә алып, үзара бәйләнештә эшлиләр.
Җирле үзидарә халык депутатлары Советларының, җирле администрация, шулай ук территория үзидарәсе органнарының вәкаләтләрен бүлешү нигезендә гамәлгә ашырыла.
Халык депутатлары җирле Советларының, җирле администрация һәм җирле үзидарәнең төрле дәрәҗәдәге башка органнарының вәкаләте, оешу, үзара мөнәсәбәт һәм буйсыну тәртибе закон белән билгеләнә.

**127 статья.** Халык депутатларының җирле Советлары һәм җирле үзидарәнең башка органнары үз вәкаләтләре чикләрендә үз территорияләрендәге икътисади һәм социаль-мәдәни үсеш, халык сәламәтлеген саклау, экология һәм башка мәсьәләләрне мөстәкыйль хәл итә.
Халык депутатлары җирле Советларының хуҗалык эшчәнлегенең икътисади нигезен коммуналь милек тәшкил итә.
Халык депутатларының җирле Советлары һәм җирле үзидарәнең башка органнары үз гамәлләре һәм актлары өчен тулысынча җаваплы.

**128 статья.** Халык депутатларының җирле Советлары – үз административ-территория





берәмлекләрендә дәүләт хакимиятенең вәкиллекле органнары. Җирле Советларның санлы составы закон белән билгеләнә.
Җирле Советлар җирле бюджетны раслый, җирле салым һәм җыемнарны билгели.
Халык депутатларының җирле Советлары үз органнарын оештыра, аларның вәкаләтләрен, структура һәм штатларын мөстәкыйль билгели, Татарстан Республикасы Конституциясе һәм законнары нигезендә карарлар кабул итә.

**129 статья.** Халык депутатларының җирле Советлары карарларын үтәү халык депутатларының түбәнге Советларына һәм җирле үзидарәнең башка органнарына, алар территориясендәге барлык предприятие, учреждение, оешмаларга, урындагы кешеләргә һәм гражданнарга мәҗбүри. Халык депутатларының түбәнге Советының законнарны боза торган карарлары югарыгы Советлар тарафыннан юкка чыгарыла.
Халык депутатларының җирле Советлары һәм җирле үзидарәнең башка органнары арасындагы каршылыклар закон билгеләгән тәртиптә хәл ителә.

**130 статья.** Халык депутатларының җирле Советлары җирле Советлар карамагына керә торган мәсьәләләрне алдан карау һәм әзерләү, шулай ук Советларның карарларын гамәлгә ашыруга булышлык итү, Советка буйсынган органнарның, предприятие, учреждение һәм оешмаларның эшчәнлегенә контрольлек итү өчен депутатлардан даими комиссияләр сайлый.

**131 статья.** Халык депутатлары җирле Советларының эшен депутатлардан сайлаган һәм Совет рәисләре җитәкчелек иткән президиумнар, ә президиум сайланмаган урыннарда Совет рәисләре оештыра.

**132 статья.** Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Югары Советы, Президенты һәм Министрлар Кабинеты актлары, җирле Советлар карарлары нигезендә һәм аларны үтәү максатында, районда, шәһәрдә, шәһәр районында, поселокта, авыл Советында идарә итү бурычын җирле администрация башкара.
Советның башкару-боеру органы буларак, җирле администрация гражданнарның хокукларын, иреген һәм законлы мәнфәгатьләрен саклауны тәэмин итә; үз карамагындагы территорияне бөтенлекле икътисади һәм социаль үстерү чараларын күрә; үз буйсынуындагы предприятие, учреждение һәм оешмаларга җитәкчелек итә; үз вәкаләтләре чикләрендә шул территориядә урнашкан дәүләт органнары, җәмәгать берләшмәләре, предприятие, учреждение һәм оешмаларның эшчәнлеген яраштыра һәм аңа контрольлек итә; законда каралган башка эшләрне гамәлгә ашыра.

**133 статья.** Җирле администрация халык депутатларының шул җирле Советына һәм югарыгы башкару һәм боеру органнарына хисап бирә.

**134 статья.** Җирле администрациянең эшчәнлегенә администрация башлыгы җитәкчелек итә. Районның, республика буйсынуындагы шәһәрнең администрация башлыгы, халык депутатларының шул Советы ризалыгы белән, Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә.
Шәһәр районы, район буйсынуындагы шәһәр, поселок, авыл Советы администрация башлыгы, халык депутатларының шул Советы ризалыгы белән, югарыгы администрация башлыгы тарафыннан билгеләнә.
Җирле администрация башлыгы үз вәкаләтләре чикләрендә карар һәм боерыклар чыгара.

Җирле администрация башлыгының законнарга туры килми торган актларын халык депутатлары Советлары, тиешле административ-территория берәмлегенең югарыгы башкарубоеру органы яки суд гамәлдән чыгара.

# V. СУД ХАКИМИЯТЕ, ЗАКОНЛЫЛЫКНЫ ҺӘМ ХОКУК ТӘРТИБЕН САКЛАУ

## 14 БҮЛЕК. СУДЛАР

**135 статья.** Татарстан Республикасында суд хакимиятенә бары судлар гына ия.
Суд хакимияте Татарстан Республикасының конституциячел төзелешен, гражданнарның хокукларын һәм ирекен яклау, закон чыгару һәм башкару хакимияте актларының Татарстан Республикасы Конституциясенә, законнарны үтәгәндә һәм кулланганда аларның законлылыкка һәм социаль гаделлеккә туры килүләрен тәэмин итү максатларында гамәлгә ашырыла.
Судлар закон чыгару һәм башкару органнарына, шулай ук җәмәгать берләшмәләренә бәйле түгел. Татарстан Республикасы Конституциясендә каралган суд органнарыннан башка, беркемнең дә суд вазифаларын һәм вәкаләтләрен үзенә алырга хокукы юк.

**136 статья.** Татарстан Республикасында суд хакимиятен Конституция суды, гомуми судлар һәм Югары арбитраж суды гамәлгә ашыра.
Суд органнарының закон көченә кергән актлары барлык дәүләт һәм җәмәгать органнары, урындагы кешеләр һәм гражданнар өчен мәҗбүри һәм Татарстан Республикасының бөтен территориясендә үтәлергә тиеш.
Суд органнарының закон көченә кергән актларын үтәмәгән, суд эшчәнлегенә тыкшынган, судка ихтирамсызлык күрсәткән өчен законда җаваплылыкка тарту каралган.

**137 статья.** Барлык судларда эшләр ачык утырышларда карала. Эшләрне ябык тыңлау, бары тик суд эшләрен алып баруның барлык кагыйдәләрен саклап, законда билгеләнгән очракларда гына рөхсәт ителә.

**138 статья.** Судья депутат була алмый, башка дәүләт, хуҗалык, җәмәгать органнарында һәм оешмаларында хезмәт хакы алып эшли алмый, эшмәкәрлек белән шөгыльләнә алмый.
Судьяга фәнни һәм укыту эшчәнлеге рөхсәт ителә.
Судьялар алыштырылмый, аларның кагылгысызлыгы закон белән гарантияләнә. Законда каралган яшькә җиткәч, алар отставкага чыгарыла.

**139 статья.** Татарстан Республикасы Конституция суды Конституция судының рәисеннән, рәис урынбасарыннан һәм әгъзаларыннан тора, алар Татарстан Республикасының 30 дан яшьрәк, 65 яшьтән өлкәнрәк булмаган, сайлау хокукына, Конституция суды судьясы вазифаларын башкару өчен кирәкле югары юридик квалификациягә һәм әхлак сыйфатларына, югары юридик белемгә, шулай ук гыйльми дәрәҗәгә ия булган яисә юридик белгечлек буенча кимендә ун ел эшләгән гражданнарыннан сайлана.





Конституция суды судьяларына кандидатларны Татарстан Югары Советына Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисе тигез санда күрсәтәләр.
Конституция суды рәисе һәм рәис урынбасары, Конституция суды судьялары тәкъдиме белән, Татарстан Республикасы Югары Советы тарафыннан раслана.
Конституция суды судьялары бәйсез һәм бары Татарстан Республикасы Конституциясенә буйсыналар.

**140 статья.** Татарстан Республикасы Конституция суды, Татарстан Республикасының Конституция төзелешен, кешенең төп хокукларын һәм ирекен яклау, Татарстан Республикасының бөтен территориясендә Татарстан Республикасы Конституциясенең өстенлеген һәм турыдан-туры гамәлдә булуын тәэмин итү максатында:

1) Татарстан Республикасы законнарының һәм Татарстан Республикасы Югары Советы норматив карарларының;
2) Татарстан Республикасы Президенты һәм Министрлар Кабинеты норматив актларының;
3) Татарстан Республикасының халыкара килешүләренең Конституциягә туры килүкилмәве турындагы эшләрне тикшерә.

Конституция суды Татарстан Республикасының югары дәүләт органнары арасындагы, шулай ук районнарның һәм республика буйсынуындагы шәһәрләрнең хакимият органнары арасындагы вәкаләтләр турындагы бәхәсләрне карый.
Татарстан Республикасы Конституция суды, Татарстан Республикасы Югары Советы, аның даими комиссияләре һәм Парламент контроле комитеты таләпләре нигезендә, шулай ук үз инициативасы белән, Татарстан Республикасы Президенты эшләренең һәм карарларының Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве турында бәяләмә бирә.
Конституция суды тарафыннан Конституциягә туры килми дип табылган актлар яки аларның аерым өлешләре, законда каралган очракларда, суд карары игълан ителгән көннән көчен югалта. Конституция суды карарлары катгый, аларга дәгъва яки шикаять белдерелми.

**141 статья.** Конституция судының вәкаләтләре, оешу һәм эшләү тәртибе, судьяларның статусы Татарстан Республикасы Конституция суды турында Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнә.

**142 статья.** Татарстан Республикасы Югары суды, район (шәһәр) судлары Татарстан Республикасының гомуми вәкаләтле судлары була. Татарстан Республикасы законнары тарафыннан аерым төр эшләрне (балигъ булмаганнар, гаилә һәм башкалар турындагы эшләрне) карау өчен махсус суд составлары оештыру да күздә тотылуы мөмкин.
Татарстан Республикасында аерым вәкаләтле судлар оештырыла алмый.
Гомуми вәкаләтле судларны оештыру һәм аларның эш тәртибе Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнә.

**143 статья.** Татарстан Республикасында барлык судлар судьяларны һәм халык утырышчыларын сайлау нигезендә оештырыла.
Татарстан Республикасының район (шәһәр) судлары, Югары суды судьяларын Татарстан Республикасы Югары Советы сайлый.
Район (шәһәр) судларының халык утырышчылары гражданнарның тору яки эш урыннарындагы җыелышларда – ачык тавыш биреп, ә Татарстан Республикасы Югары суды халык

утырышчылары Татарстан Республикасы Югары Советы тарафыннан 5 елга сайлана. Халык утырышчылары хезмәтенә дәүләт исәбеннән түләнә.
Судьялар һәм халык утырышчылары законда билгеләнгән тәртиптә һәм нигездә чакыртып алынырга мөмкин.

**144 статья.** Татарстан Республикасы Югары суды – Татарстан Республикасында суд эшләрен алып баручы һәм Татарстан Республикасы законнары тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гомуми вәкаләтле судлар эшчәнлегенә күзәтчелек итүче иң югары суд органы. Татарстан Республикасы Югары суды рәистән, рәис урынбасарларыннан, судьялардан һәм халык утырышчыларыннан тора.

**145 статья.** Барлык судларда гражданлык һәм җинаять эшләре, законда билгеләнгән очраклардан тыш, коллегиаль рәвештә карала.
Суд эшләрен гамәлгә ашырганда халык утырышчылары судьяларга бирелгән барлык хокуклардан файдалана.
Законда үлем җәзасы күздә тотылган җинаятьләр турындагы эшләр буенча хөкем ителүче кешенең гаеплелеге хакындагы мәсьәлә халык утырышчыларының киңәйтелгән коллегиясендә (присяжныйлар судында) хәл ителергә мөмкин.

**146 статья.** Судьялар һәм халык утырышчылары бәйсез һәм бары законга буйсына.
Судьяларга һәм халык утырышчыларына үз хокукларын һәм вазифаларын каршылыксыз һәм нәтиҗәле башкару өчен шартлар тәэмин ителә. Дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының, җәмәгать берләшмәләре, урындагы кешеләр һәм гражданнарның судьялар һәм халык утырышчыларының суд эшләрен башкару эшчәнлегенә тыкшынуы тыела, моның өчен законда билгеләнгән тәртиптә җавапка тарту карала.
Судьяларның һәм халык утырышчыларының кагылгысызлыгы, шулай ук аларның бәйсезлегенең башка гарантияләре закон белән билгеләнә.

**147 статья.** Гомуми вәкаләтле судларда эшләр гражданнарның чыгышына, хезмәт урынына, социаль һәм милек хәленә, нинди расадан һәм милләттән булуына, җенесенә, белеменә, теленә, дингә мөнәсәбәтенә, шөгыленең төренә һәм үзенчәлегенә, яшәү урынына һәм башкаларга бәйсез рәвештә аларның закон каршында тигезлекләренә карап хәл ителә.

**148 статья.** Гаеп кылуда шикле кеше, гаепләнүче һәм хөкем ителүче яклану хокукына ия.
Сорау алучы, тикшерүче, прокурор һәм суд гаеп кылуда шикле кешегә, гаепләнүчегә һәм хөкем ителүчегә законда билгеләнгән чаралар һәм ысуллар белән үзен яклау мөмкинлеген, шулай ук аларның шәхес һәм милек хокукларын саклауны тәэмин итәргә бурычлы.

**149 статья.** Татарстан Республикасында суд эшләре татар һәм рус телләрендә яки шул урында яшәүче күпчелек халык телендә алып барыла. Суд эшендә катнашкан һәм суд эше бара торган телне белмәгән кешеләргә тәрҗемәче ярдәмендә эшнең барлык материаллары белән танышу, судта катнашу һәм анда туган телендә чыгыш ясау хокукы тәэмин ителә.

**150 статья.** Татарстан Республикасы прокуроры һәм аңа буйсынган прокурорлар судларда эшләрне карауда Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән нигездә һәм тәртиптә катнаша.





**151 статья.** Судта гражданлык һәм җинаять эшләре каралганда җәмәгать берләшмәләре һәм хезмәт коллективлары вәкилләренең катнашуы рөхсәт ителә.

**152 статья.** Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды – идарә өлкәсендәге, предприятие, учреждение һәм оешмалар, шулай ук закон белән билгеләнгән тәртиптә эшмәкәрлек белән шөгыльләнүче гражданнар арасындагы икътисади бәхәсләрне караучы иң югары суд органы.
Татарстан Республикасы Югары арбитраж судының вәкаләте, оешу һәм эш тәртибе Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды турында Закон белән билгеләнә.

## 15 БҮЛЕК.
## ЗАКОНЛЫЛЫКНЫ ҺӘМ ХОКУК ТӘРТИБЕН САКЛАУ

**153 статья.** Татарстан Республикасындагы барлык министрлыклар, дәүләт комитетлары һәм ведомстволарның, предприятие, учреждение һәм оешмаларның депутатлары җирле Советларының, җирле администрация һәм җирле үзидарәнең башка органнарының, колхоз, кооператив һәм җәмәгать берләшмәләренең, урындагы кешеләрнең, шулай ук гражданнарның законнарны төгәл һәм бертөрле үтәвен күзәтүне Татарстан Республикасы прокуроры һәм аңа буйсынган прокурорлар гамәлгә ашыра.
Татарстан Республикасы прокурорының һәм аңа буйсынган прокурорларның эшчәнлеге Татарстан Республикасы законнарын катгый үтәүгә корыла, һәм ул законның өстенлеген тәэмин итүгә, закончылыкны ныгытуга юнәлтелә.

**154 статья.** Татарстан Республикасы прокуроры, Татарстан Республикасы Президенты тәкъдиме белән, Татарстан Республикасы Югары Советы тарафыннан билгеләнә, ул аның алдында җаваплы һәм хисап бирә.
Татарстан Республикасы прокуроры урынбасарлары, район, шәһәр прокурорлары һәм башка прокурорлар Татарстан Республикасы прокуроры тарафыннан билгеләнә.

**155 статья.** Татарстан Республикасы прокурорының һәм түбәнге прокурорларның вәкаләт срогы – биш ел.

**156 статья.** Татарстан Республикасы прокуратурасы органнары үз вәкаләтләрен кайсы да булса җирле органга бәйсез рәвештә гамәлгә ашыра һәм бары Татарстан Республикасы прокурорына буйсына.
Татарстан Республикасы прокуратурасының вәкаләте, оешу һәм эш тәртибе Татарстан Республикасы прокуратурасы турында закон белән билгеләнә.

**157 статья.** Судка кадәр тикшерү үткәрү өчен Татарстан Республикасының Тикшерү комитеты оештырыла.
Тикшерү комитеты рәисе, Татарстан Республикасы Президенты тәкъдиме белән, Татарстан Республикасы Югары Советы тарафыннан биш елга билгеләнә, ул Татарстан Республикасы Югары Советына буйсына һәм аның алдында җаваплы.
Татарстан Республикасы Тикшерү комитетының вәкаләте, оешу һәм эш тәртибе Татарстан Республикасы Тикшерү комитеты турында закон белән билгеләнә.

Судка кадәр тикшерүне алып баруның законлылыгына күзәтчелекне Татарстан Республикасы прокуроры гамәлгә ашыра.

**158 статья.** Судларның, прокуратура һәм тикшерү органнарының хокук саклау эшчәнлегенә тыкшынырга беркемнең дә хакы юк. Бу органнарның хезмәткәрләре закон таләпләренә таянып эш итә һәм үзләренең хезмәт вазифаларын башкарганда җәмәгать берләшмәләре карарларына бәйле булмыйлар.
Татарстан Республикасы территориясендә җинаятьчелеккә каршы көрәш буенча тикшерү һәм башка махсус эшләрне мөстәкыйль башкаручы хосусый, кооператив берләшмәләр һәм аларның бүлекчәләренең оешуы һәм эшчәнлеге тыела.
Татарстан Республикасында хосусый детектив һәм сак эшчәнлеге закон нигезендә рөхсәт ителә.

**159 статья.** Гражданнарга һәм оешмаларга юридик ярдәмне адвокатлар коллегияләре, ә законда каралган очракларда башка юридик оешмалар һәм аерым гражданнар күрсәтә.
Татарстан Республикасында адвокатураның оешу һәм эш тәртибе закон белән билгеләнә.

## VI.
## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ СИМВОЛЛАРЫ ҺӘМ БАШКАЛАСЫ

**160 статья.** Татарстан Республикасының үзенең суверенитетын, Татарстан халкының үзенчәлеген һәм традицияләрен чагылдырган рәсми эмблемалары, символлары – Дәүләт гербы, Дәүләт флагы һәм Дәүләт гимны бар.

**161 статья.** Татарстан Республикасының Дәүләт гербы кояш җирлегендә алгы уң аягын бераз күтәргән, янтавында түгәрәк калканы булган канатлы барс сурәтеннән гыйбарәт. Кояш түгәрәге татар милли бизәге төшерелгән, аскы өлешенә «Татарстан» дип язылган кайма белән уратып алынган.

**162 статья.** Татарстан Республикасының Дәүләт флагы яшел, ак һәм кызыл төстәге аркылы буйлардан торган туры почмаклы тукымадан гыйбарәт. Ак буй флаг киңлегенең 1/15 өлешен тәшкил итә һәм тигез киңлектәге яшел һәм кызыл төстәге буйлар уртасында урнашкан. Яшел буй – өстә.
Флагның киңлеге озынлыгына карата 1:2 нисбәтендә.

**163 статья.** Татарстан Республикасы Дәүләт гимнын Татарстан Республикасы Югары Советы раслый.

**164 статья.** Татарстан Республикасының башкаласы – Казан шәһәре.





## VII.
## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯСЕНЕҢ ГАМӘЛДӘ БУЛУЫ ҺӘМ АНЫ ҮЗГӘРТҮ ТӘРТИБЕ

**165 статья.** Татарстан Республикасы Конституциясе – республиканың Төп Законы, ул турыдан-туры гамәли иң югары юридик көчкә ия акт. Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасының дәүләт органнары актлары Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә һәм аңа туры китереп чыгарыла.
166 статья. Татарстан Республикасының дәүләт органнары, җәмәгать берләшмәләре, урындагы кешеләре һәм гражданнары Татарстан Республикасы Конституциясен ихтирам итәргә һәм үтәргә бурычлы.

**167 статья.** Татарстан Республикасы Конституциясе Татарстан Республикасы Югары Советының билгеләнгән санлы составының кимендә өчтән икесеннән күбрәгенең тавышы белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Югары Советы карары нигезендә үзгәртелә.

Татарстан Республикасы
Президенты М. ШӘЙМИЕВ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯСЕ • КОНСТИТУЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН •

20

# КОНСТИТУЦИЯ

## РЕСПУБЛИКИ
## ТАТАРСТАН

**Принята 6 ноября 1992 года**
**на XII сессии Верховного Совета Республики Татарстан**
**двенадцатого созыва**

**1992 г.**

# КОНСТИТУЦИЯ
# Республики Татарстан

**Настоящая Конституция принимается и провозглашается в соответствии с результатами народного голосования (референдума) о государственном статусе Республики Татарстан.**

## I.
## ОСНОВЫ ГОСУДАРСТВЕННОГО И ОБЩЕСТВЕННОГО СТРОЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

### ГЛАВА 1.
### ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА

**Статья 1.** Республика Татарстан – суверенное демократическое государство, выражающее волю и интересы всего многонационального народа республики.
Суверенитет и полномочия государства исходят от народа.
Государственный суверенитет есть неотъемлемое качественное состояние Республики Татарстан.

**Статья 2.** Вся власть в Республике Татарстан принадлежит народу. Народ осуществляет государственную власть непосредственно, в том числе путем референдума, и через систему государственных органов в соответствии с настоящей Конституцией. Конституция Республики Татарстан принимается Верховным Советом Республики Татарстан или путем референдума.
Советы народных депутатов как представительные органы народа составляют политическую основу государства.
Отдельное лицо или группа лиц не может присвоить себе право на осуществление государственной власти в Республике Татарстан.

**Статья 3.** Отношения гражданина и государства основываются на приоритете прав человека – высшей социальной ценности, участии граждан в управлении делами государства. В своих отношениях гражданин и государство взаимно ответственны.
Республика Татарстан гарантирует равноправие граждан во всех областях политической, экономической, социальной и культурной жизни.
Взаимное уважение, добровольное и равноправное сотрудничество всех слоев населения, граждан всех национальностей составляют социальную основу Республики Татарстан.

**Статья 4.** Государственными языками в Республике Татарстан являются равноправные татарский и русский языки.

**Статья 5.** Деятельность государственных органов в Республике Татарстан осуществляется на принципах правового государства: верховенства законов, их неуклонного соблюдения, разделения законодательной, исполнительной и судебной властей.





**Статья 6.** Политические партии, профессиональные союзы, массовые движения и другие общественные объединения вправе участвовать в управлении государственными делами через своих представителей в выборных органах государственной власти. Выполняя функции, предусмотренные их программами и уставами, они действуют в рамках Конституции и законов Республики Татарстан.
Не допускаются создание и деятельность партий, организаций и движений, имеющих целью насильственное изменение конституционного строя и целостности Республики Татарстан, подрыв ее безопасности, разжигание социальной, расовой, национальной и религиозной розни, запрещается использование в этих целях средств массовой информации, а также иных средств.

**Статья 7.** Государство строит свою деятельность на основе принципа социальной справедливости, создает необходимые условия для обеспечения достойного уровня жизни всех слоев населения, социально-экономического и культурного прогресса общества, обеспечивает экологическую безопасность и рациональное природопользование.

**Статья 8.** Республика Татарстан отвергает насилие и войну как средство разрешения споров между государствами и народами.
Территория Республики Татарстан является зоной, свободной от оружия массового поражения.
В Республике Татарстан пропаганда войны запрещается.

### ГЛАВА 2.
### ЭКОНОМИЧЕСКАЯ СИСТЕМА

**Статья 9.** Земля, ее недра, водные, лесные и другие природные ресурсы, животный и растительный мир, средства государственного бюджета, активы государственных банков, культурные и исторические ценности народов Татарстана и другое имущество, обеспечивающее хозяйственную самостоятельность республики, сохранение материальной и духовной культуры являются общенародным достоянием.

**Статья 10.** Основу экономики Республики Татарстан составляет социальное рыночное хозяйство, в котором в соответствии с законом обеспечиваются свобода хозяйственной деятельности и разнообразие форм собственности, равные условия их правовой защиты.
Экономические отношения строятся на социальном партнерстве между гражданином и государством, потребителем и производителем, работником и работодателем.
Государство регулирует хозяйственную деятельность в интересах общества и в пределах, установленных законом.

**Статья 11.** Хозяйственная деятельность в Республике Татарстан осуществляется на основе частной, государственной, коммунальной собственности и собственности общественных объединений.
В частной собственности могут находиться земельные участки и другие объекты, используемые в любой не запрещенной законом сфере деятельности.
В Республике Татарстан допускаются собственность других государств, международных организаций, иностранных юридических лиц и граждан, лиц без гражданства, а также объединение имущества, находящегося в собственности граждан, юридических лиц и государства.

**Статья 12.** Собственность неприкосновенна. Ограничение прав собственника при владении законно приобретенным имуществом не допускается.
Собственность не должна использоваться во вред государственным и общественным интересам, правам, свободе и достоинству человека.
Принудительное отчуждение объектов собственности допускается в порядке реквизиции или конфискации в соответствии с законом.

**Статья 13.** Собственность Республики Татарстан и ее граждан, находящаяся за пределами территории Республики Татарстан, защищается государством.

**Статья 14.** Правовой режим имущества, являющегося собственностью других государств, юридических, физических лиц, а также международных организаций, определяется законами и международными договорами Республики Татарстан.

**Статья 15.** Экономика Республики Татарстан функционирует на основе принципов рыночного хозяйствования. Государство регулирует развитие экономики республики посредством программ экономического и социального развития, налоговой, кредитной, инвестиционной и амортизационной политики, политики ценообразования по товарам и услугам, определяющим жизненный уровень населения, а также по продукции предприятий-монополистов, не вмешиваясь в хозяйственную деятельность предприятий и организаций. Административное ограничение деятельности экономически самостоятельных предприятий не допускается, за исключением случаев нарушения ими законодательства и международных обязательств Республики Татарстан.
Запрещается монополистическая деятельность, направленная на ограничение или устранение конкуренции.

**Статья 16.** Торгово-экономические отношения Республики Татарстан с другими государствами строятся на договорной основе.

**Статья 17.** Республика Татарстан защищает интересы потребителя и поддерживает общественную деятельность по защите его прав. Потребители имеют право на возмещение ущерба, причиненного производителями товаров и услуг, в установленном законом порядке.

**Статья 18.** Республика Татарстан обеспечивает сохранность земли, недр, вод, лесов, растительного и животного мира, принимает меры по восстановлению и воспроизводству природных ресурсов и улучшению состояния окружающей среды на основе платного природопользования.
Собственники земельных участков, землевладельцы и землепользователи, другие природопользователи обязаны сохранять плодородие земли.
Вред, нанесенный хозяйственной деятельностью окружающей среде, здоровью и имуществу граждан, подлежит возмещению в соответствии с законодательством Республики Татарстан. Деятельность землевладельцев и землепользователей, других природопользователей, нарушающих законодательство Республики Татарстан, приостанавливается ее государственными органами. Физические и юридические лица, виновные в нарушении законодательства об охране окружающей среды, привлекаются к ответственности в соответствии с законом.





# II.
# ЛИЧНОСТЬ И ГОСУДАРСТВО

## ГЛАВА 3.
## ГРАЖДАНСТВО РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН. РАВНОПРАВИЕ ГРАЖДАН

**Статья 19.** Республика Татарстан имеет свое гражданство. Основания, порядок приобретения и прекращения гражданства Республики Татарстан определяются Законом о гражданстве Республики Татарстан.
Граждане Республики Татарстан обладают гражданством Российской Федерации – России.
Граждане Республики Татарстан могут иметь гражданство иных государств, условия осуществления которого определяются договорами и соглашениями Республики Татарстан с другими государствами. Граждане Республики Татарстан могут сохранить двойное гражданство или отказаться от него.
Каждое лицо имеет право выбора гражданства и право изменять его. Лишение гражданства или права на изменение гражданства запрещается.

**Статья 20.** Все граждане Республики Татарстан имеют равные права и равные обязанности. Они имеют равное право на защиту со стороны государства, независимо от происхождения, социального и имущественного положения, расовой и национальной принадлежности, пола, образования, языка, политических взглядов, религиозных убеждений, рода и характера занятий, места жительства и иных обстоятельств.
Гражданам гарантируется пользование родным языком.
Права, свободы и обязанности граждан, предусмотренные Конституцией, осуществляются непосредственно на ее основе.
Порядок осуществления, охраны и защиты конституционных прав, свобод и обязанностей устанавливается законами.

**Статья 21.** Всем гражданам Республики Татарстан гарантируются права и свободы, предусмотренные Конституцией Республики Татарстан, в соответствии с общепризнанными нормами международного права, а также международными договорами Республики Татарстан.
Каждому гражданину Республики Татарстан, находящемуся за ее пределами, гарантируется правовая защита и помощь Республики Татарстан.
Права и свободы гражданина могут быть ограничены или приостановлены только в соответствии с законом и по решению суда.

**Статья 22.** Прямое или косвенное ограничение прав либо установление преимуществ граждан по расовым, национальным и другим признакам наказывается по закону.

**Статья 23.** Иностранные граждане и лица без гражданства пользуются всеми конституционными правами и свободами наравне с гражданами Республики Татарстан, если иное не предусмотрено законом.
Правовое положение иностранных граждан и лиц без гражданства регулируется законами и международными договорами Республики Татарстан.
Находящиеся на территории Республики Татарстан иностранные граждане и лица без гражданства обязаны уважать и соблюдать Конституцию и законы Республики Татарстан.

## ГЛАВА 4.
## ПРАВА, СВОБОДЫ И ОБЯЗАННОСТИ ЧЕЛОВЕКА И ГРАЖДАНИНА

**Статья 24.** Граждане Республики Татарстан обладают всей полнотой личных, политических, социально-экономических и культурных прав и свобод, предусмотренных настоящей Конституцией.

**Статья 25.** Жизнь человека, его здоровье, личная свобода и безопасность находятся под защитой государства.

**Статья 26.** Гражданам Республики Татарстан гарантируется неприкосновенность личности. Никто не может быть подвергнут аресту и лишен свободы, иначе как на основаниях, установленных законом. В случае ареста или задержания гражданин имеет право на немедленное судебное обжалование этих действий. Каждый гражданин, привлекаемый к ответственности за правонарушение, считается невиновным, пока виновность его не будет доказана согласно закону и в рамках надлежащей правовой процедуры.
Гражданам Республики Татарстан гарантируется право на защиту.

**Статья 27.** Гражданам Республики Татарстан гарантируется неприкосновенность жилища. Никто не имеет права без законного основания войти в жилище, а также производить обыск против воли проживающих в нем лиц.

**Статья 28.** Гражданам Республики Татарстан обеспечивается тайна переписки, телефонных переговоров, телеграфных и других форм сообщений.

**Статья 29.** Граждане Республики Татарстан в соответствии со своими убеждениями имеют право свободно исповедовать любую религию или не исповедовать никакой, заниматься религиозной или атеистической деятельностью. Каждый человек свободен в отправлении религиозных обрядов.
Возбуждение вражды, ненависти и национальной розни в связи с религиозными верованиями запрещается.
Религии и религиозные объединения в Республике Татарстан отделены от государства.

**Статья 30.** Семья, материнство, отцовство и детство находятся под защитой государства. Брак основывается на свободном согласии женщины и мужчины; супруги равноправны в семейных отношениях. Семейная жизнь граждан охраняется законом.
Государство проявляет заботу о семье, уделяет особое внимание обеспечению здоровья матери и ребенка и воспитанию детей.
Граждане Республики Татарстан несут ответственность за воспитание своих детей. Совершеннолетние дети обязаны заботиться о родителях и оказывать им помощь.

**Статья 31.** Каждый гражданин в пределах территории Республики Татарстан имеет право на свободное передвижение, выбор местожительства и местопребывания. Ограничения этого права могут устанавливаться только законом.

**Статья 32.** Каждый человек имеет право свободно покидать территорию Республики Татарстан и возвращаться в республику.





**Статья 33.** Уважение личности, охрана прав и свобод граждан – обязанность всех государственных органов, общественных объединений и должностных лиц.
Граждане Республики Татарстан имеют право на судебную защиту от посягательств на честь и достоинство, жизнь и здоровье, личную свободу и имущество.

**Статья 34.** Каждый гражданин имеет право судебного обжалования действий должностных лиц, государственных органов и общественных организаций, а также право на возмещение морального и материального вреда.

**Статья 35.** В Республике Татарстан каждому гарантируется право на свободу слова, печати, мнений и убеждений, их беспрепятственное выражение и распространение.

**Статья 36.** Граждане Республики Татарстан имеют право на организацию в мирной форме и без оружия митингов, уличных шествий, демонстраций и пикетирования в установленном законом порядке.

**Статья 37.** В соответствии с интересами народа и в целях развития общественной активности граждане Республики Татарстан имеют право объединяться в политические партии, профессиональные союзы, массовые движения и другие общественные объединения, участвовать в мероприятиях в порядке гражданской инициативы в рамках действующего законодательства. Государство оказывает им содействие в выполнении уставных задач.
Права, свободы и достоинство лиц, составляющих оппозиционное меньшинство в представительных органах власти, гарантируются законом.
Политические партии, профессиональные союзы, массовые движения и другие общественные объединения могут быть распущены на основе судебного решения, если их деятельность противоречит Конституции.

**Статья 38.** Граждане Республики Татарстан имеют право участвовать в политической жизни, в управлении государственными и общественными делами, в обсуждении проектов законов и решений общереспубликанского и местного значения, в референдумах.

**Статья 39.** Каждому гражданину в соответствии с законом гарантируется равное право доступа к государственной службе.

**Статья 40.** Каждый гражданин Республики Татарстан вправе свободно получать и распространять достоверную информацию о всех сферах внутригосударственной и международной жизни, включая вопросы правового статуса личности.
Государственные органы, общественные объединения и должностные лица обязаны обеспечить гражданину возможность ознакомления с их решениями и иными материалами, затрагивающими его права и законные интересы.

**Статья 41.** Граждане Республики Татарстан имеют право на собственность и ее наследование.

**Статья 42.** Граждане Республики Татарстан имеют право на труд, то есть свободу выбирать профессию и место работы, распоряжаться своими способностями к труду. Свобода трудового договора гарантируется.
Каждый имеет право на условия труда, отвечающие требованиям безопасности и гигиены,

и на вознаграждение за труд не ниже установленного законом минимального размера.
Государство гарантирует справедливые условия найма, увольнения и охраны труда, защиту трудовых прав и свободу представительства интересов работников на всех предприятиях, в учреждениях и организациях, независимо от форм собственности.
Государство создает условия для осуществления права на труд несовершеннолетними, лицами с физическими и психическими недостатками, гарантирует социальную защиту инвалидов, малообеспеченных и не имеющих постоянной работы граждан, в необходимых случаях организует их обучение и переквалификацию.
Принудительный труд допускается только по решению суда, а также в случаях, установленных международными договорами Республики Татарстан.

**Статья 43.** Гражданам Республики Татарстан гарантируется право на отдых и досуг. Это право обеспечивается установлением рабочей недели не более 40 часов, предоставлением трудящимся ежегодных оплачиваемых отпусков, дней еженедельного отдыха, созданием условий для рационального использования свободного времени.

**Статья 44.** Каждый гражданин Республики Татарстан имеет право на охрану здоровья, включая медицинскую помощь, которая оказывается государственными и иными учреждениями здравоохранения в установленном законом порядке.
Государство поощряет деятельность, способствующую укреплению здоровья граждан, развития физической культуры и спорта.

**Статья 45.** Граждане Республики Татарстан имеют право на здоровую окружающую природную среду.

**Статья 46.** Граждане Республики Татарстан имеют право на материальное обеспечение в старости, в случае болезни, полной или частичной утраты трудоспособности, при рождении ребенка и достижения им установленного законом возраста, в случае потери кормильца, а также по другим основаниям и в размерах, предусмотренных законами.

**Статья 47.** Граждане Республики Татарстан имеют право на жилище. Это право обеспечивается развитием государственного и общественного жилищного фонда, содействием кооперативному и индивидуальному жилищному строительству. Никто не может быть лишен жилища, иначе как на основаниях, установленных законом.

**Статья 48.** Граждане Республики Татарстан имеют право на получение бесплатного среднего общего и среднего специального образования в государственных учебных заведениях, а также на обучение в школе на родном языке.
Граждане Республики Татарстан вправе на конкурсной основе бесплатно получить высшее образование в государственном учебном заведении.

**Статья 49.** Граждане Республики Татарстан имеют право пользоваться достижениями культуры. Каждому человеку гарантируется свобода научного, технического и художественного творчества. Права авторов, изобретателей и рационализаторов охраняются государством.

**Статья 50.** Граждане Республики Татарстан в целях защиты своих экономических и социальных интересов имеют право на забастовку как крайнюю меру разрешения коллективного трудового спора, предусмотренную законом.





Никто не может быть принужден к участию в забастовке.
Забастовка не допускается, если она может создать угрозу жизни и здоровью людей.

**Статья 51.** Использование гражданами провозглашенных Конституцией прав и свобод не должно наносить ущерба государственной и общественной безопасности, общественному порядку, здоровью и нравственности населения, правам и свободам других лиц.

**Статья 52.** Граждане Республики Татарстан обязаны соблюдать Конституцию и законы Республики Татарстан.

**Статья 53.** Граждане Республики Татарстан обязаны уважать права и законные интересы других лиц.
Долг каждого гражданина Республики Татарстан – уважать честь и национальное достоинство других граждан.

**Статья 54.** Граждане Республики Татарстан обязаны участвовать в государственных расходах посредством уплаты налогов в порядке, установленном законом.

**Статья 55.** Бережное отношение к природе – долг каждого гражданина Республики Татарстан.

**Статья 56.** Сохранение культурных ценностей, исторических памятников – долг граждан Республики Татарстан.
Порча и уничтожение памятников культуры наказываются по закону.

**Статья 57.** Долг граждан Республики Татарстан – содействовать развитию дружбы и сотрудничества с народами других стран, поддерживать и укреплять всеобщий мир на основе общепризнанных норм международного права.

**Статья 58.** Граждане Республики Татарстан обязаны нести воинскую службу в соответствии с законом. Воинская обязанность исполняется на территории Республики Татарстан или вне ее на основе договорных обязательств Республики Татарстан.
Возможность замены воинской службы выполнением альтернативных обязанностей, а также освобождение от воинской службы устанавливается законом.

# III. ГОСУДАРСТВЕННОЕ УСТРОЙСТВО РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## ГЛАВА 5. РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН – СУВЕРЕННОЕ ГОСУДАРСТВО

**Статья 59.** Республика Татарстан самостоятельно определяет свой государственно-правовой статус, решает вопросы политического, экономического, социально-культурного строительства. Законы Республики Татарстан обладают верховенством на всей ее территории, если они не противоречат международным обязательствам Республики Татарстан.

**Статья 60.** Территория Республики Татарстан неприкосновенна. Границы между Республикой Татарстан и другими государствами устанавливаются и изменяются по соглашению сторон.

**Статья 61.** Республика Татарстан – суверенное государство, субъект международного права, ассоциированное с Российской Федерацией – Россией на основе Договора о взаимном делегировании полномочий и предметов ведения.

**Статья 62.** Республика Татарстан вступает в отношения с другими государствами, заключает международные договоры, обменивается дипломатическими, консульскими, торговыми и иными представительствами, участвует в деятельности международных организаций, руководствуясь принципами международного права.
Общепризнанные принципы и нормы международного права имеют приоритет над законами Республики Татарстан.

## ГЛАВА 6.
## АДМИНИСТРАТИВНО-ТЕРРИТОРИАЛЬНОЕ ДЕЛЕНИЕ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**Статья 63.** Территория Республики Татарстан делится на районы и города республиканского подчинения, районы – на города, поселки и сельсоветы, крупные города – на районы.

# IV.
# ОРГАНИЗАЦИЯ ГОСУДАРСТВЕННОЙ ВЛАСТИ В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН

## ГЛАВА 7.
## ОСНОВЫ ОРГАНИЗАЦИИ И ДЕЯТЕЛЬНОСТИ СОВЕТОВ НАРОДНЫХ ДЕПУТАТОВ

**Статья 64.** Верховный Совет Республики Татарстан, местные Советы – городские, районные, районные в городах, поселковые и сельские – составляют единую систему представительных органов государственной власти Республики Татарстан.
Советы народных депутатов самостоятельно решают все вопросы, относящиеся к их компетенции.
В поселках, сельсоветах по решению, принятому соответствующим Советом или местным референдумом, Совет может не избираться или упраздняться. Полномочия поселкового, сельского Совета в этом случае осуществляются другими органами местного самоуправления.

**Статья 65.** Основные вопросы республиканского и местного значения решаются на сессиях Верховного Совета Республики Татарстан и местных Советов народных депутатов. Они могут выноситься также на республиканский и местные референдумы.

**Статья 66.** Верховный Совет Республики Татарстан, районные, городские, районные в городах Советы народных депутатов избирают свои президиумы и председателей Советов, а





Советы городов районного подчинения; поселковые и сельские – председателей Советов.
